ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№2 (373)
ФЕВРАЛЬ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ЭЗЛИ ҺӘМ ТАБА

КАЗАНДА ЯСАЛГАН МИНА ЭЗЛӘГЕЧЛӘР МХО ЗОНАСЫНДА КУЛЛАНЫЛА

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫРГА...

Кайчак язмыш кешегә бик зур сынаулар әзерләп куя, бик куркыныч югалтуларга юлыктыра. Мондый мизгелләрдә дөнья җимерелә һәм тирә-юнебез караңгылана кебек. Без көчсезрәк, рәхимсезрәккә яисә, киресенчә, көчлерәккә әйләнеп, бөтенләй үзгәрәбез...

«Ачы югалтуларга, өметсезлек һәм газапларга карамастан, иң мөһиме – Кеше булып кала алу», – ди безнең басмабыз геройлары. Андый көчле рухлы кешеләр безнең янәшәбездә, күршебездә генә яши.

Язмаларыбыз җиңүчеләр, сынмаган-сыгылмаган, явызланмыйча, көчле, шәфкатьле, чын Кеше булып кала алганнар турында.

Сезнең кешелекле редакциягез

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Рамил Гали
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: «Метаскан» компаниясенең баш конструкторы Алексей Фоминых. Рамил Гали фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С–0280
Басарга кул куелды: 03.02.2023
Басмадан чыкты: 08.02.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

ФЕДОР ИВАНОВИЧТАН – 430 КИЛОГРАММ АЛТЫН

«Бушка кошлар гына сайрасын!» дигән гыйбарәне атаклы рус җырчысы Федор Шаляпин әйткән, дип сөйлиләр. Җырчы опера импресариолары белән сөйләшүләр алып барганда еш кына шулай дип әйтә торган була. Хәерчелекнең нәрсә икәнен яхшы белгән Шаляпин акчаны тиененә кадәр саный, әмма аны саран дип әйтеп булмый. 1905 елда ул хәйрия сәфәре оештыра һәм җыелган 16500 сум акчаны Уфа, Сембер, Саратов, Самара, Казан һәм Нократ губерналарына ярдәмгә тапшыра. Заманы өчен гаять зур акчалар була бу! Ә үзенең туган шәһәре Казанга соңгы килүендә Шаляпин 3 нче ирләр гимназиясенә 2 мең сум акча (трактирда яхшы төшке аш 30 тиен торганда!) бүлеп бирә. Бу акча шәһәр башлангыч училищесы гимназисты өчен еллык стипендия буларак тәгаенләнә. Замандашлары раславынча, җырчы үз гомерендә иганәчелеккә 430 килограмм алтынга тәңгәл акча сарыф иткән.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Авыл хуҗалыгындагы рекордлар турында
Яңа сезонда нинди уңыш күтәргә

8. Татарстан: авыл хуҗалыгы
Ел йомгаклары саннарда

10. Чал тарихлы «Актаныш таңнары»
Каләмдәшләребез ничек яши

игелекле эшләр

22. Язмыш сынавы
Ничек Кеше булып калырга

30. Көчле рухлылар
Закир Шаһбанның нинди хыялы бар

36. Зарланмыйча эшләгән буын
Константин Карпов ничек итеп сугышчан очкычлар җыйган

40. Бер гимнның ике юбилее
Татарстан гимны ничек туган

44. Курайчыга сүз әйтмәгез...
Курай ясау авырмы

52. «Инженерлар республикасы»ның 7 кануны
Яшьләр арасында инженер һөнәрләрен ничек популярлаштырырга

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

мәңгелек кыйммәтләр

62. Исеменә күрә җисеме
Балага нинди исем кушарга

66. Тарих сәхифәләре
Тәкъва галим һәм мәгърифәтче Хөсәен Фәезханов

70. Халисә Ширмәндә кунакта
Китап киштәсендә нинди китаплар бар

72. Галәм эчендәге галәм, яки
Без кайчан чынбарлык белән уйдырманы бутадык

76. Татар авыллары
Кече Кайбыч, ни хәлең бар?

84. Ай кәефе
«Казан» фотостудиясенә ничә яшь

Борис Кустодиев иллюстрациясе. Ф. И. Шаляпин портреты. 1922 ел.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

18.01

Талия Миңнуллина, ТР Инвестицияле үсеш агентлыгы җитәкчесе, – ИҮАның йомгаклау коллегиясендә:

– 2022 елның 9 ае өчен Татарстан Республикасының төп капиталына инвестицияләр, барлык дәрәҗәләрдәге бюджет акчаларын исәпкә алмаганда, 451 млрд сум тәшкил итте. Фаразланган еллык күрсәткеч – 700 млрд сумнан артык бюджеттан тыш инвестицияләр. 2022 елда Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектларында инвестицияле климат торышының Милли рейтингында 2 нче урынны саклап калды. Шул ук вакытта 2022 елның 9 ае өчен кергән инвестицияләр күләме буенча без 6 нчы урында торабыз.

31.01

Мария Львова-Белова, Бала хокуклары буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкил, – урам социаль хезмәтен оештыруның зарурлыгы турында:

– Сезнең Татарстанда яшүсмерләр өчен яхшы инфраструктура булдырылган. Спорт клублары, яшьләр клублары бар – ләкин бу нигездә талантлы, аерылып торучы яшүсмерләр өчен. Әмма катлаулы тормыш хәлләренә тарыган яшүсмерләр дә бар, еш кына бу аларның ихтыярыннан тормый. Нәкъ менә шундый авыр яшүсмерләрне ачыклау өчен урам социаль хезмәте кирәк тә. Әлеге хезмәт вәкилләре алар белән элемтәгә керә, төбәктә булган барлык ресурсларны кулланып, яшүсмернең киләчәк тормышы өчен дөрес алгоритмны билгели ала.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР



31.01

Елена Ямпольская, Россия Федерациясе Дәүләт Думасының Мәдәният буенча комитеты рәисе, – Казанда ТР Мәдәният министрлыгы коллегиясе утырышында:

– Авыл мәдәният йорты яисә китапханәсе – чынлыкта «уты дөрләгән учак» ул, уты сүнсә, учак суына, әкренләп йорт та бушый. Татарстанда учакның сүнүенә һәм йортның бушавына юл куймыйлар.

Фотолар business-gazeta.ru, tatar-inform.ru, mstrok.ru сайтларыннан

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Яңа сезонда **нинди** уңыш көтәргә

Аграрийлар **күпме** икмәк җыеп алды

Актаныштагы каләмдәшләребез **ничек** яши

МАРАТ ҖӘББАРОВ: «БЕЗ МАКСИМАЛИСТЛАР, ҺӘРВАКЫТ КҮБРӘККӘ ИРЕШЕРГӘ ТЕЛИБЕЗ»

Татарстан нәрсә хисабына ил күләмендә сөт җитештерү буенча беренче урынга чыкты? Корылыклы елда ни рәвешле биш миллион тонна уңыш җыюга ирешә алды? Дөньядагы вазгыять авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренә комачаулый аламы? «Татарстан» журналы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаровтан әлеге һәм башка сорауларга җавап бирүен үтенде.

БӨРТЕКЛЕЛӘР УҢЫШЫ ҺӘМ КОРЫЛЫКНЫ ҖИҢҮ ТУРЫНДА

– Марат Азатович, 2022 ел икмәкле булды: бер ел элек җыелган 2,4 миллион тонна уңыш фонында биш миллион тоннадан артык иген җыеп алынды – нәтиҗә күз алдында. Ләкин шулай да сез бервакыт, җыелганга караганда күбрәкне алырга планлаштырган идек, дидегез.

– Без максималистлар, һәрвакыт күбрәккә ирешергә телибез. Узган елда аграрийларга

Фото: tatar-inform.ru, tatarstan.ru

бераз яңгыр һәм салкынлык җитеп бетмәде. Әмма һава шартлары әллә ни уңай булмаса да, чыннан да яхшы уңыш җыеп алынды. Һәм гомумән алганда тармак нәтиҗәләре уңай. Барлык категорияләрдәге хуҗалыкларны исәпкә алганда, продукциянең тулай күләме беренче мәртәбә 300 млрд сумнан артып китте һәм 334,1 млрд сум тәшкил итте, бу узган елга караганда 85,3 млрд сумга күбрәк, үсеш индексы – 26%. Авыл хезмәтчәннәре 1,1 миллион тонна бәрәңге һәм яшелчә, 1,8 миллион тонна шикәр чөгендере үстерде. Укучыларны саннар белән ялыктырмас өчен аңлатып китәм: бәрәңге дә, яшелчә дә республика халкын тәэмин итү өчен кирәк булган ихтыяҗдан шактый күбрәк әзерләнде. Шикәр чөгендере татарстанлыларга ел әйләнәсе кулланырга таләп ителгән шикәрне өч тапкырдан күбрәк итеп җитештерергә мөмкинлек бирә.

– Июльдәге эссене һәм августтагы корылыкны җиңәргә нинди могҗиза ярдәм итте?

– Авыл хуҗалыгында могҗизалар көтмибез. Хәтта фидакарь, тырыш хезмәт белән дә барысына да ирешеп булмый. Бүген барлык агротехнологияләр җентекләп сакланган очракта гына яхшы нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Туфракны вакытында җиренә җиткереп эшкәртү, тиешле күләмдә минераль ашламалар кертү, сыйфатлы орлык куллану, әче туфракны известьләү юлы белән сөрүлекләрнең уңдырышлылыгын саклау... – әлеге мәҗбүри гамәлләрнең берсе генә дә яхшылап үтәлмәгәндә, һава шартлары идеальга якын булган очракта да, югалтуларсыз булмаячак. Узган ел чираттагы мәртәбә әлеге аксиоманы раслады да. Якынча бер үк шартлардагы районнарның кайберләре җитди күрсәткечләргә иреште, икенчеләре, үсеш өчен җитәрлек резервларга ия булсалар да, үзләрен күрсәтә алмады. Мәсәлән, Саба районы үз сөрүлекләренең чагыштырма авырлыгыннан 2,5 тапкырга диярлек күбрәк акча кереме алды. Әтнә, Кукмара районнары – бер ярым тапкырдан артыграк. Шул ук вакытта Апас, Лениногорск, Әгерҗе, Югары Ослан, Баулы, Спас, Балык Бистәсе муниципаль районнары үз сөрүлекләренә карата сатылган продукция күләме буенча ике һәм аннан да күбрәккә ким керем алды. Күрсәткечләр арасындагы шактый зур аерма күп кенә территорияләрнең потенциалы тулысынча тормышка ашырылмаганын аңлата. Җыелганга караганда күбрәкне алырга планлаштырган идек дигәндә, мин беренче чиратта нәкъ менә ахырына кадәр гамәлгә ашырылмаган шул потенциалны күздә тоткан идем.

БӘЯЛӘР ҺӘМ ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ ТУРЫНДА

– Зур уңыш – ул әле зур кайгыртучанлык та. Авыл хуҗалыгы продукцияләренә базар бәяләре аграрийларның көткәннәрен акладымы?

– Әйдәгез саныйк. Тармак буенча көтелгән табыш, дәүләт ярдәмен исәпкә алганда, – 17,8 миллиард сум тирәсе. Табышлы хуҗалыкларның өлеше алты процентка артты, алар хәзер гомуми санның 95 процентын тәшкил итә. Дөрес, дәүләт ярдәменнән башка авыл хуҗалыгы предприятиеләренең өчтән бере зыянга, табышсыз эшләр иде. Бәяләрнең артуы, ни дисәк тә, эзсез үтми. Мәсәлән, һава торышы һәм финанс нәтиҗәләре буенча чагыштырмача имин 2020 ел белән чагыштырганда, аммиак селитрасының бәясе – 38 процентка, запас частьлар – ике тапкырга якын, дизель ягулыгының бәясе, хәтта ташламалы күләмнәрне исәпкә алганда да, 41 процентка артты. Шул ук 2020 елда үсемлекчелек продукциясе җитештерүгә без 53 миллиард сум акча тоттык, ә узган елда кырчылыкны ресурслар белән тәэмин итүне саклап калу өчен – 69 миллиард сум. Конкрет бөртекләрне җитештерүгә – гектарына 34 мең сум.

> БАРЛЫК КАТЕГОРИЯЛӘРДӘГЕ ХУҖАЛЫКЛАРНЫ ИСӘПКӘ АЛГАНДА, ПРОДУКЦИЯНЕҢ ТУЛАЙ КҮЛӘМЕ **БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ 300 МЛРД СУМНАН АРТЫП КИТТЕ**.

Җитештерелгән продукциянең үзкыйммәте тоннасына 9,6 мең сум дип исәпләгәндә, аңлашыла ки, бөртеклеләргә базар бәясе аграрийларны шатландырмагандыр. Беркем дә югарырак сатып алу бәясенә каршы түгел, әмма нәрсә бар, шуның белән эшләргә, үз резервларыбызга исәп тотарга туры килә. Һәм дәүләт ярдәменә. Аерым алганда, сатылган бөртеклеләр өчен субсидияләргә 1,3 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Әлеге акчалар 1 миллион тоннага якын ашлыкны субсидияләү өчен җитте – ставка уртача алганда тоннасына 1300 сум булганда. Моннан тыш, министрлык тарафыннан республика товар җитештерүчеләрен сатып алу интервенцияләрендә катнаштыру максатында зур эш башкарылды. Интервенцион фондка нәтиҗәдә 226 мең тонна Татарстан ашлыгы (РФндә өлеш – 7,5%) сатып алынды. Бер тонна 3 нче класслы бодай сатуның уртача бәясе – 14,4 мең сум (ӨКСнан башка), 4 нче класслысының – 13,3 мең, арышның бер тоннасы 10,1 мең сумнан булды.

– Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме күпме?

– Үсемлекчелеккә генә дә бюджет ярдәме 5,1 миллиард сумга якын. Гомумән алганда, 2022 елда агросәнәгать комплексын үстерүгә 18,3 миллиард сум акча тотылды. Шуларның 7,1 миллиард сумы – федераль бюджет акчасы, ә 11,2 миллиарды – республика бюджетыннан. Барлык аграрийлар исеменнән Рөстәм Нургали улы Миңнехановка тармакка ярдәм итүнең нәтиҗәле ысуллары

өчен рәхмәтемне белдерәсем килә. Шуның нәтиҗәсендә безнең предприятиеләр алга таба үсү һәм яңа офыкларга җитү мөмкинлеге бирә торган модернизация ресурсларына ия булды. Быел, дәүләт программасына ярашлы рәвештә, үсемлекчелектә үсешне – 2,3 процент, терлекчелектә 1,5 процент күләмендә тәэмин итү бурычы куелды.

КИЛӘСЕ КӨЗГӘ ФАРАЗЛАР ТУРЫНДА

– Быел уңыш буенча нинди ниятләрегез бар? Дөньядагы катлаулы вазгыять аграр секторда чагылыш тапмасмы?

– Аграрийларның планнарында – быел дүрт миллион ярым-биш миллион тонна уңыш җыеп алу. Борчылыр өчен нигез күрмим. Көздән үк киләсе уңыш өчен яхшы нигез салынды, чәчүлек мәйданнарын узган ел дәрәҗәсендә саклап калырга, бөртекләрнең һәм бөртекле-кузаклы культураларның орлык белән тәэмин ителешен ихтыяҗдан 125 процентка җиткерергә уйлыйбыз. 472 гектар чәчүлек мәйданын биләгән уҗым культуралары кышка әйбәт керде, аларның торышын даими карап торабыз. Төп бурыч – кыр эшләренә техниканы әзерләү, ремонт эшләре өчен 5,2 миллиард сум акча таләп ителә. Хәер, монда да эш оешкан төстә алып барыла: кирәкле запас частьларның якынча яртысы инде сатып алынган, бу эштә өзеклекләр күренми. Чәчү кампаниясен оптималь срокларда – ике атна дәвамында үткәрербез, чәчүлекнең һәр гектарына тәэсир итү матдәсе 80 кг нан да ким булмаган күләмдә минераль ашлама кертербез дип ышанам. Бу эшләр тиешенчә башкарылганда нәтиҗәләр яхшы булырга тиеш. Бу ирешмәслек бурыч түгел – узган ел уңышы өчен гектарына тәэсир итү матдәсе 100 кг күләмендә минераль ашлама керткән районнар бар, һәм алар, әлбәттә, мул уңыш җыеп алды. Дөрес, әле һаман ашыкмаган районнар да бар. Ашламаларга бәяләр җәйдән бирле тотрыклы тора, аларны яз җиткәнче сатып алу бик мөһим, чөнки ул вакытта ихтыяҗ бик зур булачак.

ГОМУМӘН АЛГАНДА, 2022 ЕЛДА АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮГӘ **18,3 МИЛЛИАРД СУМ АКЧА БҮЛЕП БИРЕЛДЕ.**

ТЕРЛЕКЧЕЛЕКТӘГЕ РЕКОРДЛАР ТУРЫНДА

– Быел Татарстанда беренче мәртәбә ике миллион тонна сөт савып алынды. Үсеш нәрсә хисабына башкарылды?

– Республика традицион рәвештә терлекчелекне үстерү белән шөгыльләнә, авыл хуҗалыгы продукциясен сатканнан кергән акча кеременең 67 проценты терлекчелек тармагына туры килә. Ә тарихи ике миллион утыз өч мең тонна сөт – төрле факторлар комплексы һәм тормышка ашырылган үзгәрешләр нәтиҗәсе. Әгәр игътибар итсәгез, 2022 елда бер сыерның продуктлылыгы 7 125 килограмм булды – бер ел алдагы нәтиҗә белән чагыштырганда 524 килограммга күбрәк. Саву күләменең җитди артуы мөгезле эре терлекнең иң яхшыларын сайлау нәтиҗәсендә савым көтүенең кимүен дә артыгы белән капларга мөмкинлек бирде.

Аңлаганыбызча, терлекчелекнең нәтиҗәле үсеше күз алдында. Узган елда республикада берьюлы 24 сөт комплексы сафка басты, 18 мең башка исәпләнгән комплекслар иң заманча техника белән җиһазландырылды. Бракка чыгарылган түбән продуктлы терлекләр урынына яхшы нәселле МЭТ сатып алына, массакүләм рәвештә яңа азык үзәкләре төзелә. Бүген республикада 38 азык үзәге бар, алар 18 райондагы 139 мең баштан артык мөгезле эре терлеккә хезмәт күрсәтә. Шуңа күрә Татарстанның сөт җитештерү күләме буенча Россиядә лидерлыгы очраклы түгел.

– Ит, кош ите, йомырка җитештерү дә артамы?

– 2022 елда 527 мең тонна терлек һәм кош ите сатылды. Бу бер ел элек булганнан беразга кимрәк. Нәтиҗәләргә 2021 елда мөгезле эре терлекне күпләп бракка чыгару йогынты ясады. Йомырка җитештерү динамикасына күз салсак, узган ел дәрәҗәсенә карата 25 миллион данәгә үсеш күрәбез.

ЯРМИНКӘЛӘРНЕҢ СТИМУЛЛАРЫ ҺӘМ ФАЙДАСЫ ТУРЫНДА

– Киләчәктә ит, сөт, башка терлекчелек продукциясен җитештерүне арттыру өчен нинди чаралар каралган?

– Узган ел ахырында районнар терлекчелек тармагын үстерү буенча юл карталарын яклады. Тулаем республика буенча сөт җитештерү – 1,5 процентка, ит һәм йомырка җитештерү 1 процентка артыр, дип көтелә. План буенча авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә мөгезле эре терлекләрнең баш саны – 643 меңгә (булганга плюс 6370 баш), сыерныкы 228 меңгә җитәчәк. Сөт җитештерүне стимуллаштыру өчен субсидияләр күләме 1,3 миллиард сум тәшкил итәчәк – узган ел белән чагыштырганда 112 миллион сумга күбрәк. Яңа ярдәм чарасы да каралган. Ул терлекчеләргә мөгезле эре терлек җитештерү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләүне күздә тота. Бу максатларга 83,3 миллион сум акча бүлеп бирелә. 18 мең баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән 22 объект төзелеше дәвам итәчәк, ике мең башка исәпләнгән биш яңа проект гамәлгә ашырыла башлый. Азык үзәкләре саны да артачак – 16 районда 22 яңа үзәк өстәләчәк.

– Ярминкәләр инде берничә ел рәттән Татарстан аграрийларының үзенчәлекле визит карточкасы булып тора, анда сыйфатлы авыл хуҗалыгы продукциясен түбән бәядән сатып алырга мөмкин. Алар никадәр уңышлы оештырылды?

– Узган ел ярминкәләр Казанда – 15 мәйданчыкта, Түбән Камада – өч, Яр Чаллыда һәм Яшел Үзән муниципаль районында икешәр урында оештырылган иде. Егерме ике ярминкә көнендә 2,1 миллиард сумлык продукция сатылды. Шәһәр халкына, аерым алганда, арзан бәядән 18,8 мең тонна яшелчә, 2 625 тонна ит, 360 тонна сөт, 3,5 миллион данә йомырка, 1 265 тонна шикәр комы, 880 тонна он тәкъдим ителде. Мәсәлән, ярминкәләрдә яшелчәләрне уртача базар бәясеннән 25–47 процентка арзанрак, онны – 35 процентка, сөтне 20 процентка арзанрак бәягә сатып алырга мөмкин иде. Ярминкәләрне оештыруга бюджеттан 38 миллион сум акча бүлеп бирелде.

> **ТАРИХИ ИКЕ МИЛЛИОН УТЫЗ ӨЧ МЕҢ ТОННА СӨТ САВЫМЫ АЛУ** – ТӨРЛЕ ФАКТОРЛАР КОМПЛЕКСЫ ҺӘМ ТОРМЫШКА АШЫРЫЛГАН ҮЗГӘРЕШЛӘР НӘТИҖӘСЕ.

Ярминкәләрдә катнашучыларга транспорт чыгымнарын компенсацияләү авыл хуҗалыгы продукциясен халык өчен кулай бәядән сату мөмкинлеге бирә. Быел да ярминкәләр татарстанлыларны төбәгебез авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең арзан бәядәге сыйфатлы продукциясе белән сөендерәчәк. Беренчеләре язын оештырылырга тиеш.

Әңгәмәдәш: Әскәр Сабиров

ТАТАРСТАН: АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ. ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР

тулай продукция күләме (хуҗалыкларның барлык категорияләре буенча)

300 000 000 000 сумнан артык

Татарстан тарихында **БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР**

2 000 000 тоннадан артык сөт җитештерелде

17 800 000 000 сум

12 500 000 000 сум – 2021 елда

тармак буенча дәүләт ярдәме исәпкә алынган табыш

БӨРТЕКЛЕ КУЛЬТУРАЛАР ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ

1 300 000 000 сум – сатылган бөртекләләр өчен субсидия

990 000 тонна – субсидияләнгән бөртекләләрнең күләме

226 000 тонна – интервенцион фондка сатып алынган

ҖЫЕП АЛЫНГАН:

920 000 тонна – бәрәңге

266 000 тонна – яшелчә

1 800 000 тонна – шикәр чөгендере

620 000 тонна – майлы культуралар

5 160 000 тонна

бөртекләләр уңышы (эшкәртелгәннән соң)

527 000 тонна

терлек һәм кош ите сатылган

18 300 000 000 сум

агросәнәгать комплексын үстерүгә бүленгән

7 100 000 000 сум

федераль бюджеттан

11 200 000 000 сум

республика бюджетыннан

95 %

89% - 2021 елда

табышлы хуҗалыклар

Тоннасы **9 500** сум

Тоннасы 13 500 сум - 2021 елда

бөртекләрнең үзкыйммәте

18 000 башка исәпләнгән

24 сөт комплексы

куллануга тапшырылган

2021 ел белән чагыштырганда

йомырка **25 000 000**

данәгә күбрәк җитештерелгән

Тулай төбәк продукты күләмендә тармакның чагыштырма авырлыгы

8 % тәшкил итә

270 000 000 сумлык

азык-төлек продукциясе төяп-озатылачак

2023 ЕЛДА ҖЫЕП АЛУ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА:

4 500 000 – 5 000 000 тонна – бөртекләр

900 000 тонна – бәрәңге

1 800 000 тонна – шикәр чөгендере

600 000 тонна – майлы культуралар

250 000 тонна – яшелчә

ФАРАЗЛАР БУЕНЧА ҖИТЕШТЕРҮ ҮСЕШЕ

1,5 % – ит

1 % – йомырка

Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә МЭТнең баш саны

643 000 баш

тәшкил итәчәк

AGRATOR

КИҢ КОЛАЧЛЫ КАМЫЛГА ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

- Колач киңлеге 6,6 м дан 16 м га кадәр.
- Кыр буйлап бер ураганда ук, туфрак эшкәртү дә, чәчү дә, ашлама кертү дә, тырмалау да.
- Эшкәртелмәгән һәм эшкәртелгән туфракта җир яргыч астына чәчү, сабан һәм уҗым ашлыкларын камыллы басудан бер урауда чәчү.
- Культиватор сыйфатында кулланганда, эшкәртү тирәнлеге 15 см га кадәр.
- Пространстволы киң рам, югары җитештерүчәнлеккә ия төягеч шнек, 8 яки 12 куб. м лы сыйдырышлы бункер.

AGRATOR DISK

- Бер төягәндә 35 гектарга кадәр мәйдан чәчү (ашламасыз орлыклар гына чәчкәндә).
- Колач киңлеге 9 м дан 18 м га кадәр, 8 яки 12 куб. м сыйдырышлы бункер.
- Күчереп йөртү кулайлыгы. Чәчүче дә, йөк төяүче дә таләп ителми.
- Трактор гидросистемасына тоташкан үзенең төягеч шнегы.
- Югары җитештерүчәнлек — сәгатенә 24 гектарга кадәр.
- Күчереп йөртү өчен бик тиз үзгәртеп корылуы.
- Минераль ашламаның старт дозасын 1 гектарга 100 кг га кадәр бирүле кертү мөмкинлеге.

ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

TILLERDISK

БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

- Чәчү алды культивацияләү һәм ике катлы тыгызлау эшен чәчү белән бергә башкару.
- Бер ураганда ук, уксыман яргычлар белән орлык яки ашлама кертү тирәнлегенә туфракны эшкәртү, торбалы каток белән тыгызлау һәм тигезләү, дисклы төрәннәр белән чәчү, ашламаның старт дозасын кертү, чәчү тасмаларын тыгызлап кую.
- Конструкция ике өлештән — туфрак эшкәртү һәм чәчү модуленнән тора.
- «Барысы да бергә» системасындагы, энергияне саклый, югары сыйфатта туфрак эшкәртә торган һәм чәчү модуленә ия комбайн.

AGRATOR КЗС

- Бер ураганда ук, уксыман яргычлар белән орлык яки ашлама кертү тирәнлегенә туфракны эшкәртү, торбалы каток белән тыгызлау һәм тигезләү, дисклы төрәннәр белән чәчү, ашламаның старт дозасын кертү, чәчү тасмаларын тыгызлап кую.
- Бөртекле культураларны, рәт араларын 15 см итеп, гадәти һәм минималь эшкәртү технологиясе белән утырту.
- Ике дисклы төрәннәр төгәл тирәнлек белән рельефка карап күчеп баруны тәэмин итә.
- Тирәнлекне көйләү механизмына ия индивидуаль эшкәртү системасы сөрү катламының өске өлешен төгәл һәм сыйфатлы итеп тыгызларга һәм орлыкның туфрак белән бәйләнешен яхшыртырга мөмкинлек бирә.
- Яңа дүрт контурлы орлык салып бару аппараты белән җиһазландырылган.
- Дүрт торбалы чәчү системасы үзәк бүлгечтән баш тартырга мөмкинлек бирә, бу исә орлыкны изелү-сытылудан саклый, төрәннәр арасында чәчү материалын тигез бүлә.

БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

AGROMASTER

www.pk-agromaster.ru

тел.: 8(85556) 2-39-08
тел.: 8-939-396-83-44
e-mail: agromaster@mail.ru

Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы,
Тукай урамы, 33а

Европача сыйфат — Россия бәясеннән!

Фотолар «Агромастер» җитештерү компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ӨЧЕН КАДРЛАР.
ЯҢА СЫНАУЛАР – ЯҢА БУРЫЧЛАР

Бүген Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексында нинди кадрларга ихтыяҗ аеруча зур? Алар һәрвакыт заман таләпләренә туры килсен өчен нәрсә эшләргә кирәк? Хәбәрчебез сорауларына Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты (ТИПКА) ректоры Николай Титов җавап бирә.

– Николай Леонидович, ТИПКАның төп миссиясе – республиканың һәм тулаем илнең агросәнәгать секторы өчен һөнәри белемле кадрларны яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү. Бу эш никадәр уңышлы башкарыла?

– Үзегез уйлап карагыз. Бүген Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирү институтларын тәмамлаган һәр җиденче кеше Татарстанның агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институтында гыйлем арттырган. 2022 елда гына да ТИПКАны өч меңнән артык кеше тәмамлады. Шуларның 301 е яңадан әзерлек узып, яңа белгечлек алды, 2700 дән артык кеше 43 юнәлештә, шул исәптән коммерция нигезендә һөнәри квалификациясен күтәрде. Агросәнәгать тармагындагы хезмәт базарында безнең укучыларга ихтыяҗ зур – бу исә институт коллективы эшчәнлегенә иң яхшы бәя дип уйлыйм.

– Бүген авылда нинди кадрларга ихтыяҗ аеруча зур?

– Кызганыч, авылда кадрлар кытлыгы саклана, киң таралган һөнәр ияләре дә, тар белгечләр дә кирәк – демографик вазгыять үзен сиздерә. Соңгы биш елда республикада авыл хуҗалыгы оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләре саны 20 процентка кимеде. Ә югары уку йортларын тәмамлап, аграр секторда хезмәт куярга ниятләгән бакалаврларның күп очракта эш бирүчеләрнең таләпләренә туры килерлек белем-тәҗрибәсе юк.

Шуңа күрә безнең төп бурыч инде эшләүче белгечләрне сыйфатлы дәрәҗәдә яңадан әзерләүдән, аларны заман шартларына, бигрәк тә алдынгы технологияләр, хезмәтне оештыру, тармакны цифрлаштыру өлкәсендәге яңалыкларга өйрәтү, җайлаштырудан гыйбарәт. Бөтен милек төрендәге авыл хуҗалыгы оешмаларында хезмәт итүче белгечләрнең барысын да колачларга тырышабыз, норматив-хокукый актларда киңәш ителгән 5 елга бер тапкыр түгел, ә 2-3 ел саен яңадан әзерлек укулары уздырабыз.

– Югары уку йорты эшендә игътибарыгызны нәрсәгә юнәлтәсез?

– Беренче чиратта, хезмәт базарында иң кирәкле белгечлекләрне исәпкә алып, эш бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләренә нигезләнәбез. Аграр тармактагы проблемалы хуҗалык белгечләрен уңышлы оешмаларның эш тәҗрибәләре мисалында өйрәтәбез. Без һәр тыңлаучыга шәхси якын килү каралган – аның белем дәрәҗәсе, эш урыны һәм хуҗалыгының эш юнәлеше исәпкә алына. Уку-укыту барышында иң нәтиҗәле схема кулланыла: 70%ны 25 стажировка мәйданчыгында күчмә дәресләр уздырудан гыйбарәт практик өлеш тәшкил итә, 30% вакыт абруйлы галимнәр, практик белгечләрне чакырып, тыңлаучыларны теоретик әзерләүгә бирелә.

Әлбәттә, уку процессы камилләшә бара. Заман таләпләрен исәпкә алып, яңа юнәлешләр һәм уку-укыту программалары кертелә. Бүген бездә алар 70 тән артык – проектлар, бизнес процесслары, персонал белән идарә итү программаларыннан башлап, ресурсларны саклау, цифрлы технологияләрне киңкүләм гамәлгә кертү, коррупциягә каршы тору, органик җитештерү нигезләренә кадәр. Нәтиҗәлелеге исбатланган көндезге уку формалары онлайн формат белән уңышлы берләштереп алып барыла. Россиянең башка төбәкләре һәм чит илләр белән тыгыз хезмәттәшлектә эшлибез – бу исә әлеге тармакта пәйда булган яңалыкларны тизрәк үзләштерергә һәм кулланышка кертергә ярдәм итә.

– ТИПКАны гамәлгә куючы – Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы. Ә Татарстан министрлыгы белән ничек хезмәттәшлек итәсез?

– Безнең югары уку йорты Татарстанда эшли һәм, әлбәттә, яңадан әзерлек уза торган кадрлар, беренче чиратта, республиканыкы. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән дә, табигый ки, бик якын һәм нәтиҗәле бәйләнештә эшлибез. Татарстанның Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры безне һәрвакыт аңлый һәм ярдәм күрсәтә, агросәнәгать комплексы белгечләренә контракт нигезендә белем бирү программаларын һәм уку-укыту планнарын ул шәхсән үзе раслый. Марат Азат улы Җәббаров белән даими киңәшеп-сөйләшеп торабыз, бу процесста министр урынбасарлары, җаваплы хезмәткәрләр дә актив катнаша.

– 2023 елга нинди бурычлар куелды?

– Институт 2023 елга уку-укыту буенча юл картасы әзерләп, аны гамәлгә ашыра. Программада хезмәт мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу мәсьәләләре, авыл хуҗалыгы культураларын сугару, үсемлекләрне биологик саклауда, бал кортлары өчен зарарсыз технологияләрдә, бухгалтерлык исәп-хисабы һәм салым эшләрендә иң яхшы үрнәкләр һ.б. исәпкә алынган һәм яңартылган. Тулаем алганда, институт Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән хезмәттәшлектә өч меңнән артык белгечне укытырга планлаштыра, шуларның өчтән ике өлеше укуны коммерция нигезендә үтәчәк.

www.tipkadpo.ru
420059 Татарстан Республикасы,
Казан ш., Оренбург тракты, 8б
E-mail: tipkia@mail.ru
+7 (843) 277-51-86

Фото ТИПКА матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

«ЙОЛДЫЗ» – ИМИНЛЕК НИГЕЗЕ

Казанның «Метаскан» компаниясе теге яки бу куркынычны 100 процент очракта ачыклый торган детекторлар чыгара. Һәм аларны гына да түгел.

Саперлар әкрен генә бистә артындагы зур басу буйлап бара. Төркемнең бурычы – күптән түгел тыныч халык кире кайтып урнашкан торак пункт тирәсендәге территориянең куркынычсызлыгына инану. Хәрби инженерлар кулында – Казанда чыгарылган ALFAMARINE 5000 («Альфамарин 5000») мина эзләгечләре.

Компания Россия Федерациясе Оборона министрлыгы карамагындагы Халыкара миналарга каршы үзәкнең техник йөкләмәсе нигезендә эшли. Әлеге Үзәк территорияләрне шартлау куркынычы булган предметлардан арындыру эше белән җитәкчелек итә һәм саперларны өйрәтү белән шөгыльләнә. Шуңа күрә һәр «Альфамарин 5000» мина эзләгече шартлау куркынычы булган предметларны ачыклаганда рәсми техник шартларга ярашлы рәвештә озак вакыт төгәл эшли алуына сынаулар һәм тикшерү уза. «Альфамарин 5000» пехотага һәм танкка каршы миналарны һәм шартлаткыч предметларны табарга яраклы мина эзләгеч буларак сертификацияләнгән.

ҖИР АСТЫННАН ҺӘМ СУДАН

– Мондый технологияне булдыруга 5–6 ел вакыт китә. Ләкин мин инде 2000 нче еллар башыннан ук тикшеренүләр алып барып, грунтта металлны ачыклауга бәйле үз принцибымны эшләү белән шөгыльләнәм, – ди **«Метаскан»ның баш конструкторы, Идел буе дәүләт технология университеты (Мари Эл) доценты Алексей Фоминых.** – Әлеге принцип нигезенә детектор кәтүгендәге индукцион үткәрүчәнлекнең гомуми кабул ителгән параметры гына түгел, ә аның электр үткәрүчәнлеген дә күздә тотып үзем эшләгән анализлау ысулы да салынды.

«Альфамарин 5000» Сүрия, Грузия һәм башка урыннардагы коралллы конфликтлар вакытында территорияләрне чистарту өчен кулланылган модельләргә нигезләнеп җитештерелгән.

Июнь аеннан компания, махсус хәрби операция зонасында куллану өчен, РФ Оборона министрлыгына 500 дән артык прибор җибәргән. «Альфамарин 5000» мина эзләгеченең төп сыйфаты – статик эш режимы, ул металл объектның авырлык үзәген төгәл билгеләргә, ягъни миналы ачыкларга мөмкинлек бирә. Җиһазны 6 айлык эксплуатацияләү чорында саперлар бер тапкыр да шартлауга эләкмәгән яки җәрәхәтләнмәгән.

Оборона сәнәгате таләпләренә туры килгән технология дәрәҗәсенә ирешкәнгә, «Метаскан» тыныч тормыштагы күп мәсьәләләрне дә бик җиңел чишә.

Мисырның Шарм-әл-Шәех курорт шәһәреннән Piramyd* төркеме дайверлары туристлар белән чумудан туктаган буш вакытларында Кызыл диңгез сулары астында калган пирамидалардан хәзинәләр эзли. «Альфамарин 5000» модификациясе («альфа» – йолдызлыкның иң якты йолдызы; «марин» – диңгезгә кагылышлы дигәнне белдерә – ред. иск.) водолазларга 30 метр-

* «Пирамид»

Фотолар «Метаскан» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

га кадәр тирәнлектә эшләргә мөмкинлек бирә, ә су асты өчен махсус эшләнгән AQUAmarine** металл эзләгече су төбенә 200 метрга кадәр төшеп, алтын таба ала.

КЫРДА – АЛТЫН

– Тирәнлектә приборга су басымы тәэсир итә, шуңа күрә мондый җиһазларны житештерү озаграк вакыт ала, өстәвенә, ул техник контроль бүлеге экспертизасын узарга тиеш. Металл һәм мина эзләгечләрне сынау өчен, шартлау куркынычы булган объектларның стендлары һәм имитаторлары көйләнгән үз лабораториябез бар, экспертизаны шунда үткәрәбез дә, – ди Алексей Фоминых. Сүз уңаеннан, «Метаскан» бөтен продукциясен үз шоурумында тәкъдим итә.

Су асты эшләре белән бәйле технологияләр Мисырда гына түгел, Татарстанда һәм Мари Элда да популяр. «Метаскан» металл эзләгечләре ярдәмендә җирле дайверлар соңгы елларда бу ике республика елга һәм күлләрендә батып калган җиһазларны табып, өскә тартып чыгарды. Февраль башында «Метаскан» су асты белән бәйле «эшләнмә»ләренең суперсәләтләрен Мәскәүдәге Moscow Dive Show*** дайвинг-күргәзмәсендә күрсәтәчәк.

«Альфамарин 5000» мина эзләгеченә заказлар күләме арта барса да, компания даими ихтыяҗ сакланган җиһазлар – кеше йөзен тану функциясе булган, алып керелә торган металлның төрен һәм зурлыгын сизәргә сәләтле аркалы заманча металл детекторлар, шулай ук гадәти металл детекторлар чыгаруны дәвам итә.

12 модификациядән гыйбарәт продукция арасында төрле хәзинәләр эзләргә яки металл калдыкларын җыярга яратучылар өчен тәгаенләнгәннәре дә, торбаүткәргечләр һәм җир астындагы башка коммуникацияләрне тикшерү белән мәшгуль оешмалар өчен чыгарыла торганнары да бар. Алексей Фоминых әйтүенчә, феррозондлы магнитометр һәм георадарлар компаниянең перспективалы фәнни-тикшеренү эшләреннән санала. Алар төзелеш һәм реконструкцияләр вакытында, шул исәптән нефть һәм газүткәргечләр сузганда, зур тирәнлектә металл объектлар эзләү өчен кулланыла, шулай ук хәрби хәрәкәтләр барган территорияләрдә куркынычсызлыкны тәэмин итү максатында файдаланыла.

2023 елда «Метаскан» «алтын» премьера планлаштыра. Үзенең 180 металл тибын ачыкларга сәләтле металл эзләгече нигезендә компания магнит-индуктив ысул белән эретмәнең составын билгели ала торган металл детектор моделен эшләгән.

– Бу – алтын тәңкәләрнең һәм зәркән әйберләренең составын билгеләү өчен эшләнгән җыйнак җайланма. Төсле металл, кыйммәтле металл, алтын тәңкәләр белән эш итә торган банклар аларның сыйфатын тикшерә алачак, – ди Алексей Фоминых. – Беренчел модель Саклык банкында һәм Татарстандагы шәхси компанияләрнең берсендә сынау уза. Әлеге приборның инновациясе тәңкәләргә дә, бизәнү әйберләренә дә зыян салмый торган электр магниты кырын куллanудан гыйбарәт.

ALFAMARINE 5000 ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ

Сизгерлек – чит илдә эшләнгән аналогларыннан 6 тапкыр югарырак.

Бәясе – модификациягә карап, 145–250 мең сум тәшкил итә (чит ил аналоглары якынча 1 миллион сум тора).

Су үткәрмәүчәнлек (база комплектациясендә чуму тирәнлеге – 3 метрга кадәр), бәрелү-сугуга, югары һәм түбән температураларга чыдамлык (-40 тан +80 гә кадәр).

Җиңеллек – җайланманың авырлыгы 1,3 килограмм гына тәшкил итә. Прибор җыйнак, аны салып йөртү өчен сумка комплектациягә керә.

Энергия сарыф итүдә нәтиҗәлелеге – бер комплект аккумулятор белән – 9–10 сәгать, югары сыйдырышлы аккумуляторлар белән 20 сәгатькә кадәр (чит ил аналоглары – максимум 4 сәгать) эшли ала.

2022 ЕЛДА «МЕТАСКАН» КОМПАНИЯСЕНЕҢ КАЗАНЫШЛАРЫ:

Алексей Фоминых бүләкләре:

Илнең оборона сәләтен тәэмин итү өлкәсендәге казанышлары һәм хезмәтләре өчен медаль.

«Сыйфат отличнигы» мактау билгесе.

«Метаскан» компаниясе бүләкләре:

Санкт-Петербург халыкара сәнәгать форумының «Оборона сәнәгате» номинациясендә «Хәрби максатлардагы продукция житештерүгә зур өлеше һәм илнең оборона сәләтен ныгытуга технологияләрне һәм инновацияле алымнарны гамәлгә кертүе өчен» диплом.

«Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсы лауреаты дипломы – «Ел яңалыгы» номинациясендә йөзләрне тану функциясе булган ARENA-5000PR**** аркалы металл эзләгече белән җиңү.

«Татарстанның иң яхшы 100 товары һәм хезмәте» конкурсы лауреаты дипломы.

Компания Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасына һәм Россия Федерациясе Сәүдә-сәнәгать палатасына керә.

БУ МӨҺИМ

Мина эзләгеч металл эзләгечтән чыдамлылыгы һәм озак вакыт эшли алуы (бер тапкыр корылган батареяда эшләү вакытының озынлыгы), ялгыш сигнал бирү мөмкинлеге булмавы, барлык төр металл һәм эретмәләрне күрергә сәләтлелеге белән аерылып тора.

Күпләр ярдәм сыйфатында металл эзләгечләр сатып алырга һәм алгы сызыкка җибәрергә омтыла, өстәвенә, чит илнекен. Шуны истә тотарга кирәк: мондый җайланмалар төгәллеккә тикшерелми, мина эзләгечләр өчен каралган техник шартларга туры килми, алар һәвәскәрләр өчен чыгарыла, металлга сигнал бирүе дә гарантияләнми, бу шартлауның сәбәбе булырга мөмкин.

Гаскәрләргә ярдәм итү өчен, теләсә нинди климат шартларында эшләргә тәгаенләнгән «Метаскан» җитештерүендәге металл эзләгечләрне **алырга киңәш итәбез.** РФ Оборона министрлыгының Халыкара миналарга каршы үзәге нәкъ менә «Альфамарин 5000» мина эзләгечләре белән эшләргә өйрәтә.

METASCAN
metascan-md.com
тел. 8 800 444-00-27
info@metascan-md.com
grunt. metascan-md.com

** «Аквамарин»
*** «Москоу дайв шоу»
**** «Арена»

«АКТАНЫШ ТАҢНАРЫ» – ЧАЛ ТАРИХЛЫ БАСМА

Филиза Гомәрова

Узган 2022 ел мөхәрриятебез өчен истәлекле вакыйгаларга бай булды. Иң әһәмиятлеләреннән берсе – «Актаныш таңнары» дип аталган район газетасының 90 еллык юбилее.

Газетабызның беренче саны 1932 елның августында дөнья күрә. Шуннан бирле ул төбәгебезнең тормыш-көнкүрешен яктырта. Газетаның бай тарихы «Җирлегебез көзгесе» дигән җыентыкта чагылыш тапкан. Китапны язуда үткен каләм ияләре Әмирҗан Моталлапов, Йосыф Хуҗинның өлеше зур. Җыентыкта төрле елларда газета чыгаруда катнашкан бик күп шәхесләр турында кызыклы мәгълүмат тупланган.

Бүгенге көндә газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Актаныш-информ» эшчәнлегенең бер юнәлеше булып тора. «Актаныш-информ» коллективы, газета чыгарудан тыш, җирле радио, телевидение һәм сайт эшчәнлеген дә алып бара. Зур командада иҗади атмосфера хөкем сөрә. Иң мөһиме - кәгазь вариантта нәшер ителә торган газета үзенең абруен саклап калырга тырыша. Аны тугры укучылары яшәтә.

Фотолар «Актаныш таңнары» газетасы мөхәрриятеннән алынды. РЕКЛАМА 12+

Безнең өчен тагын бер зур вакыйга – мөхәррият бинасына капиталь ремонт ясалды, 10 февральдә аны тантаналы төстә файдалануга тапшыру көтелә.

ЯРАТАЛАР, УКЫЙЛАР

«Актаныш таңнары» газетасы һәр атнаның җомга көнендә 12 битле булып чыга, шуның 4есе – төсле. Газета башкалабызның «Идел-Пресс» нәшриятында басыла. Альтернатив язылуны өстен күрүчеләр шактый. Күпләп алдыручы оешмаларга, авылларга газетаны мөхәррият үзе илтеп бирә.

Газетага язылучылар арасында даими төстә бүләкләр уйнатыла. Соңгысы 20 гыйнвар көнне үтте. 13 кешегә кыйммәтле бүләк тапшырылды. Алар – газетабызны яратып укучылар, ел саен язылучылар.

Актив хәбәрчеләр белән онлайн-элемтә ныгый бара. Хатлар электрон почта аша килә. Интернетта аралашу авылда яшәүче каләм ияләренә дә, үзебезгә дә уңайлы.

МАХСУС БҮЛӘК – БЕЗНЕКЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Актаныш-информ» коллективы «Бәллүр каләм-2022» республика бәйгесендә диплом һәм кыйммәтле бүләккә ия булды.

«Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын иң яхшы мәгълүмати яктырту» номинациясендә яуланган әлеге җиңү газетаның 90 еллык юбилеена зур бүләк булып килеп ирешәте.

Татарстанда XXIV «Бәллүр каләм-2022» журналистика һәм масса-медиа өлкәсендәге республика бәйгесе лауреатларын бүләкләү тантанасында «Актаныш-информ» җитәкчесе Айнур Гыймадиев һәм конкурсның номинанты Әлфия Мөхәммәтова катнашты.

Бүләккә бирелгән кесә телефоны «Актаныш-информ»ның интернет челтәрләрендә яңаданяңа видеолар, фотолар урнаштыру мөмкинлеген арттырды.

Мөхәррияттә эш гөрли.

«Актаныш-информ» коллективы Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов белән. 2022 елның җәе.

«Китап» радиосы һәм «Актаныш-информ» коллективлары «Мин матурлык эзлим йөрим...» проекты белән Актаныштa.

Һәрвакыт бергә булыйк, актив тормыш мизгелләре тарихка теркәлсен, дип, канатланып эшлибез хәзер.

КҮРШЕЛӘРДӘ КУНАКТА

Дус-тату коллективыбыз бергәләп ял итү чараларын да бик теләп оештыра. Узган ел бергә җыелып Минзәлә шәһәренә әдәби-мәдәни экскурсиягә бардык.

Максатыбыз Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театрында Федор Достоевский романы буенча сәхнәләштерелгән «Җинаять һәм җәза» спектаклен карау иде. Әлеге сәфәргә «ТАТМЕДИА» АҖ һәм ТР Мәдәният министрлыгы арасында төзелгән килешү сәбәпче булды. Күрше район журналистлары – хезмәттәшләребез белән иҗади элемтәләрне барлау, ныгыту, аралашу, фикер алышу да мөһим бит.

Тамаша башланыр алдыннан музей белән танышу да күңелле сәфәрнең бер өлеше булды. «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Минзәлә-информ» коллективы белән бергә музейда булдык, театр карадык. Коллегаларыбыз белән истәлекле бу очрашу җылы, иҗади атмосферада үтте.

АКТАНЫШТА МАТУРЛЫК КҮП

«Китап» радиосы «Мин матурлык эзләп йөрим...» автомарафоны белән Актаныш якларына да килде. «Актаныш таңнары» газетасының 90 еллыгына бәйләп үткәрелгән кичке чарага балалар, яшьләр һәм өлкәннәр җыелды.

Чара башкала кунаклары һәм Актаныш сәнгатькәрләре чыгышы белән үрелеп барды. Нәни дусларыбыз өчен төрле кызыклы уеннар үткәрелде. Очрашуда иң кызыклы уеннар «Актаныш-информ» коллективы тарафыннан оештырылды, бүләкләр тапшырылды. Мәдәният паркына ял итәргә килүчеләр бик канәгать калды.

– Район тормышының кабатланмас елъязмасы – «Актаныш таңнары» газетасы 90 еллык юбилеен каршылый. Бу истәлекле дата басманың иҗади тарихында гына түгел, төбәгебезнең иҗтимагый тормышында да гаять әһәмиятле вакыйга. Яше аксакалныкы булса да, газета һәрвакыт яшь күңелле, төрле буын кешеләре өчен кызыклы һәм бай эчтәлекле булып кала, – диде мәдәни ял чарасын алып баручылар.

Чыннан да район газетасы – Актанышыбыз тарихын теркәп бара торган елъязма ул. Барлык мөһим вакыйгалар, халык тормышы һәм фикере журналистлар, актив хәбәрчеләр тарафыннан район тарихына теркәлеп бара.

«Актаныш-информ» җитәкчесе Айнур Гыймадиев халыкны бәйрәм кичәсе белән котлады һәм газетага язылучылар арасында оештырылган уенда җиңүчеләргә бүләккә сертификатлар, телевизор тапшырды.

Әлфия Авзалова исемендәге Мәдәният йорты каршындагы мәйданны гөрләткән концертта татар эстрадасы артистлары Фәрит Низамиев, Зәринә Хәсәншина, шагыйрә Сәйлән, алып баручылар Ильяс Шәрипов һәм Лилия Кадыйрова чыгыш ясады. Бәйрәм истә калырлык булды.

«Игенче даны», 1972 елның икенче саны.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕН ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

Игенче даны

КПССның АКТАНЫШ РАЙОН КОМИТЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ | ОРГАН АКТАНЫШСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА ДЕПУТАТОВ ТРУДЯЩИХСЯ

№ 2 (3542) сишәмбе, 4 январь, 1972 ел ■ 38 ел чыга. ■ Бәясе 2 тиен.

Шәйхелгыйлем Галимов—Шәймәрданов исемендәге колхозның алдынгы тракторчысы. Ул бишьеллыкның беренче елында йомшакка күчереп 1040 гектар җир эшкәртте.

Хәзер алдынгы механизатор бишьеллыкның икенче елы үрләрен штурмлау өчен әзерләнә.

Рәсемдә: Ш. Галимов.

КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумының, СССР Министрлар Советының совет халкына

ЯҢА ЕЛ КОТЛАВЫ

Иптәш Н. В. ПОДГОРНЫЙНЫҢ телевидение һәм радио аша чыгышы

УДАР АЙЛЫК БАРА

Ашламаны—кырга!

ПЛАННЫ ҮТӘҮ ӨЧЕН

Т. ЯЛАЛОВ.

Молдавиянең басу культуралары селекциясе, орлыкчылыгы һәм агротехникасы фәнни-тикшеренү институтында бөртекле культуралар орлыкларын чәчү алдыннан эшкәртүдә „Стебель-3" гамма-установкасы файдаланыла. Радиоактив нурланыш үсемлекләрнең үсешен тизләтүгә һәм уңышны арттыруга йогынты ясый.

РӘСЕМДӘ: гамма-установканың тышкы күренеше.

ТАСС фотохроникасы.

«АКТАНЫШ ТАҢНАРЫ» ГАЗЕТАСЫ 1932 елның август аеннан бирле чыгып килә. Аның нәшер ителүенә 2022 елда 90 ел тулды. Башта – «Колхоз ударнигы», 1965–1997 елда «Игенче даны» исеме астында дөнья күрә. 1998 ел башыннан алып бүгенгә кадәр – «Актаныш таңнары». Исеме үзгәреп торса да, газетаның асылы сакланып кала: Актанышның төп матбугат чарасы. Район тормышын халыкка җиткереп тора, вакыйгаларны тарихлаштыра. Районның социаль-икътисадый үсешенә үз өлешен кертә. Газета – ул халык белән хакимият арасындагы күперне тоташтырып торучы басма. Аның игътибар үзәгендә – сәяси вакыйгалар, сәнәгать үсеше, социаль мәсьәләләр, иҗтимагый тормышка, бигрәк тә авыл проблемалары һәм кешеләрнең яшәешенә кагылышлы сораулар. Илдә, республикада, районда барган яңалыкларны даими яктырта, социаль мөһим темаларга еш мөрәҗәгать итә. Дәүләт программалары һәм проектларының төбәгебездә ничек тормышка ашырылуын объектив чагылдыра. Газетада басылган язмаларның Президент программаларының үз вакытында үтәлешенә, сыйфатлы башкарылышына йогынтысы зур.

Журналистлар һәм хәбәрчеләр. 1960 нчы еллар.

«Колхоз ударнигы», 1938 елның 47 нче саны.

BARLЬQ ILLƏRNEN PROLETARILARЬ, BERLƏŞEGEZ!

Kolxoz udarnigь

7 NCE JЬL СЬQA

VKP (в) NЬŅ AQTANЬŞ RAJKOMЬ HƏM RAJBAŞQARMA ORGANЬ

Орган Актанышского РК ВКП (б) и РИКа

„КОЛХОЗ УДАРНИГЕ" шестидневная районная татарская газета

JAZЬLU BƏJƏSE
1 jьlqa . . . 3 s. 60 tien
6 ajqa . . . 1 . 80 .

Redaksia adresь: Татрес. с. Актаныш, Центральная ул. д. № 51.

№ 47 (495) 1938 nce jьl, 24 nce ijyl № 47 (495)

RSFSR NЬŅ BERENCE CAQRЬLЬŞ VERXOVNЬJ SOVETЬNЬŅ BERENCE SESSIƏSE

BØJEK FEDERATSIƏ XØKYMƏTE

Politik agitatsiəne taqьn da juqarьraq

INFORMATSION BELDERY

RSFSR NЬŅ BERENCE CAQRЬLЬŞ VERXOVNЬJ SOVETЬNЬŅ BERENCE SESSIƏSENEŅ 1938 NCE JЬL. 20 NCE IJYLDƏ BULQAN UTЬRЬŞЬ TURЬNDA

PARTIƏ TORMЬŞЬ

Partiə eşendə sezoncьlьqqa jul qujmasqa

Şumatof.

БӘЙГЕЛӘР ИЛҺАМ ӨСТИ

«Актаныш таңнары» газетасы – республикада мактаулы бүләкләр алучы, иҗади сулышын камилләштереп торучы басма.

Беренче саны чыгуның 50 еллыгы уңаеннан **1982 елда** «Игенче даны» газетасы ТАССР Югары Советы Президиумы тарафыннан Мактау кәгазе белән бүләкләнде.

2005 елда Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыгы реформасын һәм модернизацияле яктырту буенча үткәрелгән республика конкурсында 1 нче урынны яулады. **2006 елда** авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлекле һәм аның барышын яхшы яктырткан өчен район газетасы Дәүләт статистика федераль хезмәте территориаль органының Рәхмәт хатына лаек булды.

2007 ел – газета өчен аеруча уңышларга бай ел. Коллективка ТР Президентының Рәхмәт хаты тапшырылды. «Бәллүр каләм» республика фестивалендә «Район, шәһәр газетасы» номинациясендә җиңеп, ТР Журналистлар берлеге һәм «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең дипломы белән бүләкләнде. Журналистларның «Аграр көч – каләм көче» республика бәйгесендә диплом белән бүләкләнде.

«Татэнерго» АҖнең Журналистлар союзы белән берлектә республикадагы массакүләм-мәгълүмат чаралары арасында үткәрелгән «Күпкырлы энергетика» конкурсында бернинчә ел рәттән җиңү яулады.

2008 елда ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан уздырылган «Кеше һәм закон» конкурсында мөхәррият – 2 нче, 2010 елда – 1 нче, 2011 елда 2 нче урынны яулады.

ТР Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан уздырылган «Щит и перо» конкурсында **2010 елда** «Актаныш таңнары» газетасы, җиңү яулап, диплом белән белән бүләкләнде.

2011 елда коллектив Актаныш муниципаль район башлыгының Мактау кәгазенә, **2012 елда** «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директорының Рәхмәт хатына лаек булды.

2023 елда берьюлы 4 журналистыбыз ТР ЮХИДИ тарафыннан уздырылган иҗади бәйгедә җиңүче булды.

ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов хезмәттәшләребез Айсылу Мөхәммәтдинова һәм Таңсылу Фәрдиевага Рәхмәт хаты тапшырды.

22 ЕЛЛЫК ТЫРЫШ ХЕЗМӘТ

Коллективыбызда хезмәт сөючән кешеләр эшли. Аларның тырыш хезмәте республика, район җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнә. Күптән түгел генә матбугат өлкәсендә нәтиҗәле хезмәтләре өчен, игезәк туганнар – газетабызның верстка операторы Айсылу Мөхәммәтдинова һәм корректор Таңсылу Фәрдиева Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин имзалаган әлеге җылы эчтәлекле текстта: «Актаныш-информ»да ике дистә елдан артык эшләү дәверендә район халкын ышанычлы һәм сыйфатлы мәгълүмат белән тәэмин итүгә керткән өлешегезне югары бәялибез. Үзегезгә таләпчән, башкалар хезмәтенә игътибарлы булуыгыз белән хезмәттәшләрегез арасында хөрмәт казандыгыз. Киләчәктә дә уңышлар, сәламәтлек, иминлек телим», – дигән сүзләр бар.

Хөрмәтле коллегаларыбызга алга таба да иҗади уңышлар телибез!

90 ЕЛЛЫККА – 90 ЧАКРЫМ

«Актаныш таңнары» газетасының 90 еллыгы уңаеннан велосипед йөреше үткәрелде. «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Актаныш-информ» җитәкчесе Айнур Гыймадиев идеясе иде ул.

90 чакрымлы сәяхәтне районыбыз яшьләре хуплап каршы алды. Әлеге велойөреш бездә инде өченче ел рәттән үткәрелә. Быелгысы ГТОның 90 еллыгы кысаларына да кертелде.

Мондый чаралар халкыбыз арасында сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруда да мөһим роль уйный. Алар «Актаныш-информ» коллективы һәм район башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге теләктәшлеге белән юлга кузгалды. Катнашучыларны ЮХИДИнең патруль командасы озата барды. Актаныш, Чишмә, Киров, Татар Суыксуы авыллары аша үтеп, кичкә таба Татар Ямалысына килеп җиттеләр.

Велосәяхәтчеләр арасында район башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесе Ленис Вәлиев, «Актаныш-информ» җитәкчесе Айнур Гыймадиев, Актаныш сәнгать мәктәбе директоры Айгиз Мәрдәнов та бар иде. Һәм, әлбәттә, «Актаныш-информ» хезмәткәрләре үзләре дә бик теләп катнашты.

Газетаның 90 еллыгы уңаеннан, юлда очраган авылларда тукталыш ясап, язылучылар белән очрашырга да вакыт табылды. Велосипедта йөрергә яратучы газета укучылар да әлеге сәяхәткә кушылды.

Велойөрешне ике көнгә планлаштырып, төнне Татар Ямалысы табигатендә үткәргән спортчылар иртәгесен тагын юлга кузгалды. Такталачык, Уразай авыллары аша узып, Актанышка күтәренке рухта, көч-дәрт туплап кайттылар.

«90 еллыкка - 90 чакрым» велосәяхәтендә катнашучы каләмдәшләр.


www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Татар авыллары
Яңалыклар
Реклама 16+

акыллы гамәлләр
игелекле эшләр
мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ничек кеше булып калырга

Закир Шаһбанның **нинди** хыялы бар

Татарстан гимны **ничек** туган

Курайны **ничек** ясыйлар

Инженер һөнәрләрен **ничек** популярлаштырырга?

ВСЕРОССИЙСКАЯ ТЕЛЕВИЗИОННАЯ
ОБЩЕСТВЕННАЯ ПРЕМИЯ



РОЖДЕННЫЙ В
СССР

«Татарстан» журналының махсус проекты

КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫРГА...

Кайвакыт язмыш кешегә бик зур сынаулар әзерләп куя. Бик куркыныч югалтуларга юлыктыра.
Ирегеңне югалту.
Сәламәтлегеңне югалту.
Хәрәкәт итү сәләтеңне югалту.
Өеңне югалту.
Мәхәббәтеңне югалту.
Бик якын кешеләреңне югалту.
Кешеләргә, тормышка ышанычыңны югалту...
Мондый кайгы-хәсрәт бездән эчкече дә, хыянәтче дә, үч алучы да, үтерүче дә, хәтта үз-үзеңә кул салучы да ясарга сәләтле. Мондый мизгелләрдә дөнья җимерелә һәм тирә-юнебез караңгылана. Без көчсезрәк, рәхимсезрәккә яисә, киресенчә, көчлерәккә әйләнеп, бөтенләй үзгәрәбез...
«Ачы югалтуларга, өметсезлек һәм газапларга карамастан, иң мөһиме – Кеше булып кала алу», – диләр геройларыбыз.

Татарстан тарихында да мондый катлаулы язмыш кичергән кешеләр күп.
Академик Лихачевны Татарстанда яхшы беләләр һәм хәтерлиләр – ул Казанга камалышта калган Ленинградтан «тормыш юлы» буенча эвакуацияләнә.
Блокадага кадәр Дмитрий Сергеевич, сәяси тоткын буларак, Соловец лагерьларының бөтен «тәмен» татый. Әмма авырлыклар аны сындырмый, тоткынлык һәм ачлык аның ихтыяр көчен чыныктыра. Ул озын, авыр гомер юлын үтә, үзеннән соң китаплар, хикәяләр, цитаталар рәвешендәге зур мирас калдыра. Әлеге мирас Лихачевның исемен мәңгеләштерә. Ата-бабалар мәдәнияте тудырган мохитне саклап калуны күздә тоткан «мәдәният экологиясе» дигән төшенчәне дә нәкъ менә ул кертә.
Татар шагыйре, прозаик, драматург Фәнис Яруллин исемен кем генә белми икән. Армиядә спорт белән шөгыльләнгәндә умыртка сөяген имгәтеп, гомере буе йөрмәслек булып калган япь-яшь егет бөтен тырышлыгын, рухи көчен үзенең белем дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби иҗат серләренә төшенүгә юнәлтә. Сюжет нигезенә үзе кичергән вакыйгалар салынган «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте халык күңелен бик тиз яулап ала. Фәнис Яруллин – 46 китап авторы, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе һәм Г. Тукай исемендәге ТР Дәүләт премиясе лауреаты. Язмыш сынауларын җиңеп, үзендә ихтыяр көчен туплап, Кеше булып кала алган шәхес.

Андый кешеләр хәзер дә бар. Алар безнең янәшәбездә, күршебездә генә яши.
Язмаларыбыз җиңүчеләр,
сынмаган-сыгылмаган,
явызланмыйча,
көчле, шәфкатьле,
чын Кеше булып кала алганнар турында.

Фото: tatar-inform.ru, «Татарстан» журналы, геройларның шәхси архивларыннан

ВЛАДИМИР ВАВИЛОВ
ҺӘМ УЛ ТӨЗЕГӘН ЙОРТ

Балаңның үлеменә күнегеп буламы? Берничек тә булмый...

Әмма яраткан балаңның соңгы минутларында аның янәшәсендә булмау, күзләреннән үбеп саубуллашырга өлгермәү, иң авыр мизгелләрен җиңеләйтә алмау – үзәк өзгече шул...

Владимир Вавилов мондый балалар өчен (соңрак өлкәннәр бүлеге дә ачыла) паллиатив ярдәм күрсәтелә торган хоспис төзи, «Дом без боли» дип атала ул. Ләкин иң элек, лейкемия белән авырып, әтисе белән хушлашу мөмкинлеге ала алмыйча үлеп киткән кызы – Анжела Вавилова исемендәге фонд оештыра.

Йолдызлы күк картасында – йолдызлар. Аларның һәрберсе инде арабыздан киткән бала исеме белән аталган. Иң беренче йолдызның исеме Анжела. Башка йолдызчыкларның соңгы көннәре Фәрештәләр йортында үткән. Ата-ананың мәхәббәтен, игелекле мөнәсәбәтне тоеп, авыртуларсыз үткән ул көннәр.

Бу йортта баланың ата-анасына дару, рецепт алу һәм башка ярдәм сорау өчен вакыт үткәрергә кирәкми. Монда назлы елмаюлар, күңел җылысы, яхшы мөгамәлә хөкем сөргән матур бүлмәләрдә һәркем үлемне җиңеп булмау белән килешә, хәтта үлем түшәгендә яткан кешене өзелеп сөйсәгез дә, ул сезнең балагыз, бердәнбер балагыз булса да.

Владимир Вавилов «Татарстан» журналы белән еш аралаша. Без хоспис ачу планнары, аның ничек төзелүе һәм анда пациентларның ничек яшәве турында сөйләштек. Һәм хәзер әлеге әңгәмәләрне яңадан бер карап, Татарстанда Анжела Вавилова исемендәге паллиатив ярдәмнең барлыкка килү хронологиясен торгыза алабыз.

ҮЗ-ҮЗЕҢӘ ЫШАН!

– Ниндидер эшне башлаганда үз-үзеңә ышанырга кирәк, – дип саный Владимир Вавилов. – Кызыбызны югалтканнан соң, без моңа ирешү өчен ничә ел тырыштык! Түрәләр безне тыңларга теләмәде. Сәламәтлек саклау министрлыгында хоспис төзергә вакыт җитте дип карар кылынгач, хоспис төзү проекты буенча шәхси-дәүләт партнерлыгы турында килешү имзаладык. Мин башка илләрнең тәҗрибәсен өйрәнә башладым... Хоспис өчен бинаны реконструкцияләүгә ул вакытта Санкт-Петербург губернаторы булган Валентина Ивановна Матвиенко 300 миллион сум акча бүлеп бирде. Беренче тапкыр без хәйрия акчалары хисабына хоспис төзедек. Бу елларда миңа янәшәмдәге командам ярдәм итте.

ИҢ МӨҺИМЕ АВЫРТУ ҺӘМ ГАЗАПЛАРНЫ ҖИҢЕЛӘЙТҮ

– Могҗизалар була. Һәм менә моны ата-аналарга җиткерергә кирәк. Радикаль дәвалану вакытында барысы да сыналып, дәва ярдәм итми башлагач, баланы паллиатив ярдәмгә күчерәләр. Шуңа күрә монда иң мөһиме – авыртуны, газапны җиңеләйтү һәм мөмкин булганча гомерне озайту. Чөнки бала диагноздан түгел, ә дәваланудан үләргә мөмкин. Чөнки организмның хәле калмый. Баланы җәфаларга кирәк түгел. Без аның гомерен булдыра алган кадәр озайтабыз. Хоспис – мәхәббәт, кайгыртучанлык, симптоматик дәвалау һәм иң мөһиме – авыртуны басу ул.

КАБУЛ ИТЕГЕЗ ҺӘМ КУРЫКМАГЫЗ

– Хоспис үлем йорты түгел, ул – язмыш язган гомерне лаеклы яшәп бетерү мөмкинлеге. Хастаханә һәм онкоүзәкләрдә пациенттан диагнозны яшерәләр. Туганнарына әйтәләр, ә пациентка – юк. Без бу турыда сөйләшәбез. Чөнки кеше моны аңларга, кабул итәргә һәм курыкмаска тиеш. Әйе, без үлем турында сөйләшәбез. Хәзер бер кыз белән аны ничек кумәргә икәнлеге турында сөйләшәбез. Чөнки кеше фани дөнья эшләрен тәмамларга тиеш. Моннан куркырга кирәкми. Үлем иртәме-соңмы һәрберебезгә киләчәк.

ДӨРЕС ЮЛДАН БАРАБЫЗ

– Хосписта кунаклар күп була, еш кына укучылар да килә. Хосписта булганнан соң балалар инде үзләрен башкача тота башлый. Күзлек кигән сыйныфташларын, мәсәлән, алар инде «ботаник» яисә «очкарик» дип үртәми. Элегрәк, без әле яңа гына эшли башлаганда, үз адресыма нәрсәләр генә ишетмәдем. «Без хосписка, үлүчеләргә карап торырга дип, монда фатир алмадык!» Хәзер минем телефоным рәхмәтләрдән тынып тормый. Монда булганнар, якыннарын, балаларын югалтканнар... Аларның тормышлары дәвам итә бит. Аларның дуслары, туганнары бар. Алар инде безнең турында беркайчан да начар әйтмәс. Димәк, без дөрес юлдан барабыз.

ТӨРЛЕ ДИН – БЕР ГАИЛӘ

– Миннән еш кына олылар хосписын төзү өчен ничек акча җыя алдыгыз, дип сорыйлар? Балаларга әле җыярга була, әмма өлкәннәргә беркем дә бирми диярлек. Һәм барысы да Татарстанда, мөселман республикасында, кешеләрнең мондый кертемнәр ясавына гаҗәпләнә. Безгә мөселманнар да, православие динен тотучылар да килә, дим. Төрле диндә булуыбызга карамастан, без барыбыз да бердәм, бер гаилә булып яшибез.

«ТАНК» ХЫЯЛЫ

– Иң мөһиме, хоспис төзелгән. Бу хыял, беләсезме, ирешә алмастай булып тоелган иде. Ә без аны тормышка ашыра алдык. Мине юкка гына танк дип йөртмиләр инде. Ә игелек – ул кире әйләнеп кайта. Мин моңа ышанам.

Ната Смирнова фотосы

СВЕТЛАНА ИЗАМБАЕВА
ҺӘМ ВИЧ-ИНФЕКЦИЯЛЕ КЕШЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ

– Мин туган көнемдә үк үләргә тиеш булганмын, – дип сөйли Светлана Изамбаева үзенең туган көне турында. – Дөньяга килгәч, миңа үз гомерем өчен көрәшергә туры килгән – дүрт ай дәвамында инкубаторда мөстәкыйль суларга һәм ашарга өйрәнгәнмен.

22 елдан соң тарих кабатланды. Мин үземнең ВИЧ-инфекция йоктырганымны белдем, һәм миңа кабат тулыканлы тормыш өчен көрәшергә туры килде. Берничә ел дәвамында көн саен куелган диагнозны кабул итәргә, шушы хәлемдә дә лаеклы тормыш алып барырлык кеше икәнемне аңларга өйрәндем.

Светлана җиңә – диагнозы белән килешә. Әле тагын «Миссис Позитив среди женщин, живущих с ВИЧ-инфекцией» бәйгесендә дә җиңүгә ирешә. Бу инде күптән булган хәл. Бүген ул үз гаиләсендә – «Миссис Позитив», аны ире, балалары, эте-песие генә түгел, аның ярдәменә мохтаҗ бөтен кеше дә ярата. Ул башкаларга киңәшләре, эшләре һәм шәхси үрнәге белән булыша. Ә алты ел элек Светлана командасы ВИЧ-инфекцияле бер яшүсмернең хыялын тормышка ашыра – илнең төрле шәһәрләреннән килгән башка балалар белән очрашу оештыра.

«СИН ЯЛГЫЗ ТҮГЕЛ!»

– Без ВИЧ-инфекцияле яшүсмерләр өчен слет оештырдык, – ди Светлана. – Диагнозга җайлашу өчен зур ярдәм программасы барлыкка килде. Төп нәтиҗә дуслар табу, «Син ялгыз түгел!» икәнлекне аңлау булды.

ХЫЯЛЛАР...

– Минем һәрвакыт зур гаиләле буласым килде, – дип сөйли Светлана. – Бу турыда балачактан ук хыялландым. Үземнең ишле гаиләмә ничек итеп ашарга әзерләвемне, бергәләшеп урманда йөрүебезне, чаңгы шууыбызны, зур табын тирәли кичке ашка җыелуыбызны күз алдына китерергә ярата идем... Бәлки үзем үскән гаиләдә моны күрмәгәнгәдер – без биш бала булсак та, эти эчкәч, бу турында хыялланырга гына кала иде...

ЯРДӘМ ИТЕП ҮЗЕҢӘ БУЛЫШАСЫҢ

– Минем өчен гаилә – һәрвакыт беренче урында. Ләкин инде ВИЧ диагнозы куелганга, миңа үземне үзем аңлау да мөһим иде. Мин хатын-кызлар ярдәм төркемен оештырдым, чөнки башкаларга булышканда син үзеңә дә ярдәм итәсең. Мондый төркемнәрне өемдә җыя башлаганда беренче балама өч ай иде. Икенче балам белән йөкле булганда, әнием үлеп китте. Балигъ булмаган ике энекәшем калды, кечкенәсе ятып кына тора, аңарда ДЦП. Аларны балалар йортына җибәрделәр. Әнине күмгәндә мин иремне балаларны тәрбиягә алырга күндердем. Әмма ВИЧ-инфекцияле булу сәбәпле, РФ законы буенча балаларны алырга рөхсәт итмәделәр. Судлар аша опекага ирештем.

ҺӘРВАКЫТ ӨЙРӘНҮДӘ

– Мин, әлбәттә, хуҗабикә, ләкин ВИЧ-инфекцияле кешеләргә киңәшләр бирүне дәвам итәм, шәхси үрнәгем аша аларны төшенкелектән коткарырга тырышам. ВИЧ-инфекцияле хатын-кызларны вирус күчмәслек итеп балага узарга өйрәтәм. Йөклелек вакытында таблеткаларны ничек эчәргә кирәклеген аңлатам. Мин – клиник психолог, травмо-терапевт һәм гештальд-терапевт, һәрвакыт өйрәнүдә.

УРМАН ҺӘМ БАЛАЛАР ЯРДӘМ ИТӘ

– Балалар, энекәшләремне карарга, авыруларга каршы көрәшергә миңа урман, чаңгы ярдәм итә – без һәрвакыт табигатькә чыгарга тырышабыз. Балаларның ни өчен үсештә артта калуын аңлау һәм аларга булышу өчен, нейропсихологияне өйрәндем. Балалар миннән яхшы логопед ясады. Алар начар сөйләшкәнгә, белгечләргә йөрдек, бөтен биремнәрне бергә башкардык, һәм үзем дә бу һөнәрне үзләштердем.

ГАИЛӘ БӘХЕТЕНЕҢ СЕРЕ

– Гаилә бәхетенең сере – үзеңнең бөтен барлыгыңны һәр адымда тою ул. Арыйм икән – ятып йоклыйм. Баллы ризык ашыйсым килсә – ашыйм. Үзеңне һич онытырга ярамый. Гел юуу-үтүкләү турында гына уйлау гаилә бәхете түгел ул. Иреңне балалар белән аралашуга тартырга, бергәләп әкиятләр укырга, сөйләшергә, рәсем ясарга кирәк. Ирең эштән арып кайткан икән, башта аңа ял итү мөмкинлеге бир. Аның белән бер дулкында булу мөһим. Ирнең кәефсез чагында җитди сөйләшү башламау хәерле. Тән, караш, эчке халәттәге билгеләрне танып, аңларга өйрәнү яхшы. Бер-береңне аңлау, ярату мөһим.

МИН КӘТТӘ ӘБИ БУЛЫРМЫН!

– Минем әби алдынгы сыер савучы иде. Тырыш хезмәте өчен медальләре күп булды. «Менә, иртүк килеп, сыерларны ашаткач, алар күп итеп сөт бирә», – дип сөйли иде. Аның киңәшләрен истә тотам, үтәргә тырышам. Кайчак үземне әби итеп күз алдына китерәм. Менә мин – әби. Инде балаларым да гаиләле. Минем зур йортым бар. Урман янында, күл буенда. Зур мунча. Мин биергә йөрим, бик шәп биим. Мин – бик кәттә әби. Ял көннәрендә балаларым һәм оныкларым җыела. Ирем белән барысын да каршы алабыз, мунча ягабыз, мин бик тәмле бәлешләр пешерәм. Без әле тагын бергәләп сәяхәт итәргә яратабыз, һәм мин аларга әбиемнең сыерлары һәм медальләре турында сөйлим...

Фото Светлана Изамбаеваның гаилә архивыннан алынды

РӘШИТ ЗЫЯТДИНОВ
ҺӘМ ЯШЬ КАРАТИСТЛАР

Олеся Бондаревская

Әгәр Сэлинджерның «Над пропастью во ржи» романы герое Холден Колфилд балаларны упкын кырыенда туктатып калу, аларга егылырга ирек бирмәү турында хыялланып кына калса, Рәшит Зыятдинов моны эшли инде. Карате серләрен өйрәтү аша. Рәшит Зәйнетдин улы каратист малайлар сафы алдыннан чын командирларча уза, көрәшкә әзерләүдә аңа бернәрсә дә киртә була алмый – култык таягы да, бер аягының киселгән булуы да...

Аның тормышы сериалга охшаган. Анда нәрсә генә булмаган: чик буенда хезмәт итү дә, ДОСААФта автоинструктор булып эшләү дә, Себергә китү дә, гомерен өзә язган яралану да.

ЙӘ АЯК, ЙӘ ГОМЕР

– 90 нчы еллар, нинди заманалар икәнен үзегез аңлыйсыз инде, – дип искә ала Рәшит Зәйнетдин улы. – Бер кичне Северный бистәсендәге йортыбызга караклар керергә маташты. Мин аларны куркыттым. Берсе атты һәм ядрә аяктагы артериягә тиде. Мине ашыгыч ярдәм машинасында алып киттеләр, күп кан югалттым. Операциядән соң табиб мине уятып, йә аягың, йә гомерең, диде. Сайларга туры килмәде, – дип искә ала Рәшит Зыятдинов. – Аннары хастаханәдә яттым, алга таба нишләргә дип уйландым, чөнки тормышым элеккечә бара алмый иде инде. Дуслар һәм хезмәттәшләр минем өчен борчылдылар, бик күп кан тапшырдылар, ярдәм итеп, булышып торырга вәгъдә иттеләр. Тиздән шуны аңладым: минем өйдә утырасым, кемгәдер йөк буласым килми. Шуңа күрә бер нәрсә калды – үзем белгән эшне дәвам итү. Килеп чыгармы-юкмы – күз күрер.

КАРА БИЛБАУ

– Култык таягы белән йөрү баштарак авыррак булса да, армия әзерлеге ярдәм итте. Армиядә мин чик буенда хезмәт иттем, шуңа күрә ике ел дәвамында тәүлегенә 30–40 км чик юлын үтә идек. Кулларым да, аякларым да көчле. Култык таягында йөрергә дә бик тиз ияләштем. Өйдә икенче каттан беренчесенә төшү-менү генә куркынычрак булды. Яралангачы мин берничә ел заводтагы карате секциясенә йөргән идем. Дәвалангач бергә шөгыльләнгән дуслар килеп йөрде. Хастаханәдән соң яңадан спортка кайтырга үгетләделәр. Мин кайттым. 2011 елда кара билбауга ия булдым.

БЕЛЕП СУГЫШЫРГА КИРӘК

– Иң яхшы сугыш – ул булмый калган сугыш, диләр. Ләкин инде була кала икән, әмәлен белеп сугышырга кирәк.

Хәзер Болгар балалар сәламәтләндерү үзәгендә карате кекусинкай секциясендә якынча 50 малай һәм кыз шөгыльләнә, 6 яшьтән 16 яшькә кадәр. Зурракларның күбесе ачылганнан ук, инде алты ел йөри, район һәм республика ярышларына баралар. Бөтенроссия җыеннарына да йөриләр – атна буе палаткаларда яшәп, теләсә кайсы һава шартларында шөгыльләнәләр, яшьтәшләре, остазлар белән аралашалар

КАРАТЕ ҺӘРКЕМГӘ ЯРДӘМГӘ

– Менә Саша, хәзер ул Тәтештә физкультура укытучысы булырга укый, – дип күрсәтә ул укучыларның фотосурәтләрен. – Менә Сергей десант гаскәрләрендә хезмәт итә, әзерлеге шәп булганга шунда алдылар. Менә Олег – 11 яшь, шактый аксый, җитди диагноз, ә ике ел эчендә – оста көрәшче һәм өч медаль.

– Мин үзем – карате кешене ничек көчле итә алуына тере дәлил. Ләкин балалар бүген икенче, ымсындыргычлар, буш вакытлары күп. Моннан тыш, үзәктә бушлай шөгыльләнәләр. Бер тиен дә түләмиләр икән, спортны ташлавы да кызганыч түгел, дип саныйлар. Сарыф ителгән вакытның да бик зур кыйммәткә ия булуын алар әле аңламый.

КУЛДАН КИЛГӘНЧӘ ЯРДӘМ ИТӘМ

– Мин, әлбәттә, аларның берәрсе чемпион булуын телим. Ләкин төп бурычым – балаларны үз көчен һәм җаваплылыгын аңлаган, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер булган яхшы кеше итеп тәрбияләү. Спортчы булырлармы-юкмы – монысын үзләре хәл итсен. Кулдан килгәнчә ярдәм итәргә әзер.

ҺӘМ ТАГЫН ВЕЛОМОБИЛЬ

– Әтием тракторчы иде, безне – дүрт улын да – техниканы яратырга өйрәтте. Бала чакта, яшүсмер чакта Кама Тамагы буйлап велосипед һәм мотоциклда элдерә идек. Ләкин бер аяклы кешеләр өчен мин андый конструкцияләрне таба алмадым, шуңа күрә үзем өчен бер аяк белән хәрәкәткә китерелә торган веломобиль җыйдым. Башта аны өч тәгәрмәчле итеп ясарга ниятләдем, ләкин машина йөртүче буларак, дүрт тәгәрмәчлесен уңайлырак дип таптым.

Социаль челтәрдәге видеода мин, башкалар да шундыйны җыя алсын өчен, веломобилемнең төзелешен җентекләп аңлаттым.

Фото Рәшит Зиятдиновның шәхси архивыннан

Фотолар Закир Шаһбанның гаилә архивыннан

ЗАКИР ШАҺБАН: КӨЧ НИДӘ СЫНАЛА?

Руфия Фазылова

Моннан берничә ел элек Татарстанның атказанган артисты Закир Шаһбан белән бер бәйрәмдә якыннан аралашырга туры килде. Шулвакыт аның эчке культурасына, зыялылыгына шаккаттым. Тагын бер нәрсә гаҗәпкә калдырды: тумыштан күрмәүче Закир абый бик мөстәкыйль икән. Өйдә ул сау ирләрнең дә күбесе эшләмәгән хезмәтләрне үти: үз-үзен караудан башлап, коммуналь хезмәтләр өчен интернет аша акча күчерүгә кадәр, ә кызы кечкенә чагында аңа дәрес әзерләшкән. Закир абый – гаиләнең төп туендыручысы да.

«АК ТӨСЛӘР КҮБРӘК...»

Тумыштан күрмәүче кеше төсләрне аермый. Шулай да Закир абый тормышын ак төсләрдә күрә, караңгылык яратмый. Холкы буенча да оптимист ул.

Закир абый тумышы белән Новосибирск өлкәсенең Чан районы Тармакүл авылыннан. Биш балалы гаиләдә иң өлкән бала ул. Әти-әнисе гади эшчеләр. Ләкин гаиләдә әдәбиятка, сәнгатькә урын гел түрдән булган. Моңа бер генә дәлил – күрмәүче биш яшьлек улына әнисе гармун алып бирә. Шул бәхетле көнен Закир абый бүген дә хәтерли:

– 1971 ел иде ул. Яңа гармунымны кулга алдым да бармакларым белән телләренә басып карадым. Әһә, мин әйтәм, монда баскач тавыш калынрак чыга икән, монда – нечкәрәк. Тора-бара көйләр чыгара башладым. Үзем уйныйм, үзем шатланам! Әти белән әни эштән кайткан төшкә яңа көй өйрәнеп куям. И, алар сөенә инде. Менә бәхет нәрсә икән ул!

Малайны Новосибирск шәһәрендәге күрмәүче балалар өчен махсус интернат-мәктәпкә укырга бирәләр. Өйдән аерылу бик авыр булмасын дип, ата-ана улларына радиоалгыч бүләк итә. Җиде яшьлек Закир шуның ярдәмендә сагыну әчесен онытып тора. Бу яшьтә туган авылың, якыннарыңнан аерылып кара әле!

– Интернатта укыганда радио иң якын дустыма әйләнде, – дип искә ала ул көннәрне Закир абый. – Шуннан татар җырлары, татар спектакльләре тыңлап, кич узганын тоймый да кала идем. Нәтиҗәдә, шул дулкында татлы йокыга да таласың...

Закир интернат-мәктәптә яхшы укый. Тырышлык, үҗәтлек – әлеге сыйфатлар кечкенәдән сеңә аңа. (Шулай булмаса биш яшеннән үзлегеннән гармунда уйнарга өйрәнә дә алмас иде!) Малайның музыкаль талантын мәктәптә дә күрәләр, төрле кичәләрдә чыгыш ясый. Һәм интернат-мәктәпне тәмамлагач, ике дә уйламыйча, документларын Курск музыка училищесына бирә. Гармунда, баянда оста уйнаучы егетне монда да тиз күреп алалар.

ИСӘНМЕ, КАЗАН!

Училищены тәмамлагач, егет Новосибирск шәһәренең милли-мәдәни үзәгендә эшли башлый. Шунда «Тургай» исемле төркем оештыра. Егет-кызлар белән Себернең төрле шәһәрләренә гастрольләргә йөриләр. Озакламый Закир Шаһбан исемле җырчы егетнең барлыгын Себернең татарлар яшәгән күп төбәкләрендә беләләр. Бер конкурста Закир легендар җырчы Илһам Шакиров белән таныша. Тиз генә аралашып, Казанда очрашырга сүз куешалар. Бер елдан соң Закир Илһам абыйның өендә кунакта була, танышалар, сөйләшәләр.

Озак та үтми, егет иң зур хыялын тормышка ашыра – Казанга күченә. Һәм КДПИның музыка факультетына, ТРның халык артисты Мингол Галиев классына укырга керә:

– Халыкара «Татар җыры-1995» кә бик рәхмәтлемен, әлеге бәйге мине татар дөньясына танытты, – диде Закир абый. – Конкурска мине укытучым Мингол абый әзерләде, зур рәхмәт аңа! «Татар җыры-1995» минем өчен зур баскыч булды. Ул чагында бу бәйгенең абруе бик зур, анда Россиядән генә түгел, бөтен дөньядан җырчылар катнаша иде. Конкурста мин «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленнән «Ала карга» һәм Салих Сәйдәшевнең «Җырларым» әсәрен башкардым. «Татар җыры»ның жюри рәисе Илһам абый Шакиров иде. Ул минем башкаруда «Ала карга»ны нык яратты. «Бик үзенчәлекле башкардың», – дип, соңыннан да килеп әйтте. Нәтиҗәдә, шул җырым белән гала-концертка да эләктем, җиңүче дә булдым.

ЗАМАНЧА «ЗАМАН»

Закир Шаһбанны бик күпләр «Заман» төркеменең солисты буларак хәтерлидер. Сигез ел шунда хезмәт куя җырчы. Композитор Ганс Сәйфуллин чакыруы буенча килеп, тиз арада төркем егетләре белән дуслашып, бик күп гастрольләрдә йөрергә, җырлар яздырырга туры килә.

– Ганс Сәйфуллинны чын мәгънәсендә остазым дип кабул итәм, – ди Закир абый. – Җырчылар арасыннан аның җырларын иң күбе мин башкарам. Егерме ике ел

буе без аның белән хезмәттәшлек иттек. Кызганыч ки, 2017 елда Ганс абый бакыйлыкка күчте. Юкса тагын күпме матур җырлар туган булыр иде әле...

Эстраданы карасаң, күп кенә музыкаль төркемнәр таркала. Татарда, руста да шулай ул. «Заман» да әнә шундыйлар рәтендә. Ничек кенә уңышлы эшләсәләр дә, Закир Шаһбан бер көн мөстәкыйль «йөзәргә» карар кыла.

– Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе каршында эшләүче «Заман» төркемендә дүрт егет идек, – ди ул көннәргә бәя биреп җырчы. – Бик тату эшләдек. Үз җырларыбызны да яздырып, башка җырчылар белән дә хезмәттәшлек иттек. Шуның аркасында үзебезнең иҗатка урын калмый башлады кебек. 2002 елда коллективтан китәргә булдым. Монда берәүне дә гаепләмим. Коллектив ул тере организм, шулай килеп чыкты. Егерме елдан артык үзем генә иҗат итәм. Әлбәттә, нәрсәнедер югалтканмындыр да. Ләкин артка юл юк, бары тик алга карап яшәргә кирәк.

«ТОРМЫШЫМНЫҢ ТӨП МӘГЪНӘСЕ – ГАИЛӘМ...»

Алда әйтелгәнчә, Закир Шаһбан КДПИга укырга керә. Ләкин ике елдан ул югары уку йортын ташлый. Моның сәбәпләре берничә: уку эшкә комачаулык итә, факультетның деканы гастрольләргә йөргән студентларны бик өнәп тә бетерми. «Без җырчылар түгел, ә укытучылар әзерлибез», – дип еш кабатлый торган була. Аннары, ул бит инде «картаеп» укырга кергән егет – курсташларыннан, ким дигәндә, җиде-сигез яшькә зуррак. Һәм төп сәбәп – Закир абыйның әнисе вафат була. Бу кайгы утыз яше дә тулмаган егетне аяктан екмаса да, шактый кешелектән чыгара.

– Тормыш сынаулардан тора, – ди Закир абый. – Аларны җиңү зур батырлык. Кемнедер югалтасың, кемнедер табасың, бу шулай килә. Соңгы егерме елда тормышымның төп мәгънәсе – гаиләм. Алар өчен дип яшим.

Күпләр беләдер, Закир Шаһбанның җәмәгате Гөлүсә – шагыйрә, дипломлы педагог, логопед. Хәләл җефетенең администраторы да. Бүген алар бергә гастрольләргә йөри. Ә бит аңа кадәр Закир Шаһбан өч тапкыр гаилә корып караган, өчесе дә уңышсыз...

– Гаилә корганда берәү дә аерылам дип уйламый, – ди Закир абый. – Ә минем белән шулай килеп чыкты. Илле яшькә кадәр яшәп тә бер тапкыр хатын-кыз кулы тотып карамаган ир-атлар бар. Ә миңа менә дүрт тапкыр өйләнергә туры килде. Әлбәттә, яшәгән саен гаилә кыйммәтләре үзгәрә. Хатын-кыз белән ир-ат мөнәсәбәтләре бик катлаулы өлкә. Гаилә коруга зур җаваплылык белән карарга кирәк. Үз башымнан кичкәнгә әйтәм – бер генә хатын белән яшәүгә ни җитә!

– Закир абый, ә сез нинди эти? – дим.

– Яхшы эти булырга тырышам. Тик төрле чак булгандыр: юаш та, таләпчән дә. Бөтен тормышымны кызыма багышларга тырыштым. Мәктәптә укыганда барлык фәннәрдән

ярдәм иттем. Кызыбыз Алисәгә бүген унтугыз яшь. Югары уку йортында, менеджмент һәм идарә итү белгечлеге юнәлешендә белем ала. Заказга искиткеч тортлар пешерә, махсус укып чыкты.

«МӘСКӘҮДӘ ИЛҺАМ ШАКИРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ!»

Закир абый белән әңгәмә барышында, гел аның күңел кылларын тартырга тырышам: үзе белән бәйле берәр елата торган вакыйга сөйләмәсме? Тегеләй дә тартып карыйм, болай да... Ә ул үзеннән бигрәк, тормыш, мәдәният, сәнгать турында фикер йөртә, фәлсәфә кора. «Иң зур хыялыгыз нинди?» – дип тә сорап карадым. Сәламәтлеге турында әйтер дип фаразлаган идем, тагын ялгыштым...

– Иң зур хыялым – Илһам Шакиров исемен мәңгеләштерү максатыннан, Мәскәүдә бик зур концерт бинасы төзелсен иде. Башкалабызда бер миллионга якын татар яши. Гомумән, Россиядә татарлар сан ягыннан, руслардан кала, икенче урында. Илебез башкаласында татарны данлый торган шундый бина һичшиксез булырга тиеш. Аны татар концертлары өчен генә түгел, башка чараларга да кулланыла торган мәртәбәле урын итәргә мөмкин. Гомумән, милләт буларак саклану чараларын ныгытасы иде. Бөтендөнья татар конгрессына караган эшләрне тагын да көчәйтергә кирәк. Милли факторны үстерү, саклау чараларын күрергә кирәк. Мисал өчен, безнең Новосибирск якларында татар концертлары бөтенләй юк диярлек. Артистлар акча эшләп булмый дип бармый, ә җирле җитәкчеләргә ул бик кирәкми. Хәтта барган артистларны да кире бору очраклары булды.

«ТАТАРЧАМ, РУСЧАМ КАМИЛ»

Себер якларында туып үскән егетнең татарчасы ничек шулай камил? Закир Шаһбанга бу сорауны еш бирәләр. Моның сере бик гади – күп уку, аудиокитаплар тыңлау, татар җырлары, спектакльләр тыңлау... Популяр җырчы ук булырга хыялланмаса да, Новосибирскида яшәгәндә Закир Казанга килү теләге белән яна. Шуның өчен дә әдәби татар телен өйрәнә.

– Татар эстрадасына килгәч, татар телем камил булырга тиеш дигән максат куйдым. Аңламаган сүзләрнең мәгънәсен сорый идем. Нәтиҗәдә, татар телем бүгенге көндә камил һәм шуның белән горурланам. Ике дәүләт телендә дә иркенләп фикер йөртәм. Сәхнәдә дә сөйләргә бик яратам. Концертым җыр дәресе кебек бара: композиторларның биографиясенә басым ясыйм, җырның тарихын сөйлим. Һәм һәр концертта җырның авторларын әйтәм. Бу минем өчен бик мөһим.

...Тырышкан таба, ташка кадак кага, ди халык. Закир Шаһбан гомере буе әнә шуны раслап бара: теләк, максат булганда, бернигә дә карамыйча, үз дигәнеңә ирешә аласың. Даими рәвештә үзеңне камилләштерү, гел нәрсәгәдер өйрәнү – Закир абыйның тормыш девизы. Көчле затларның девизы!

ГӨЛҮСӘ ШАҺБАН:

– Янәшәңдә терәк булу кирәк. Үзеңдә ышаныч тоясың. Хатын-кыз янында һәрвакытта ир булырга тиештер, дип уйлыйм. Ул аягында нык басып торырга ниндидер көч бирә. Шуңа күрә мин Закирның ышыгындадыр... Мин аның киңәшләренә таянам.

Закирны Татарстанда белеп бетермиләр әле. Җырчы буларак түгел, ә нинди кеше икәнен диюем. Ул – шуның хәтле мөстәкыйль кеше. Тик аны һәрбер кешегә дәлилләп йөри алмыйм бит. Мәсәлән, аның минеке шикелле телефоны бар. Шуннан фатир өчен онлайн түли, акчаларны күчерә, Ютубка керә, тыңлый, хатлар яза, хатлар ала. Мөстәкыйль инде. Хәзерге заманда гади кешегә яшәү өчен нәрсә кирәк булса, ул барысыннан да файдалана. Хәзер бездә тышкы кыяфәтенә карыйлар да: «Мескен!» – диләр. Ә мескенлек бит ул түгел. Кешенең тышкы кыяфәтенә карап кына бәя биреп булмый. Мескенлек – кешенең эчке халәте ул.

Завод бүлекчәләре җитәкчеләре космонавт Евгений Леонов белән. 1981 ел.



чальникам т. Голунков. В последних двух цехах ухитрились растерять чертежи на детали.

приводимые ими мотивы необоснованы.

Технолог **Гуревич.**

В юнгородке беспорядки

Начальник юнгородка т. Свиридов совершенно не заботится о бытовых нуждах живущих в юнгородке.

В комнатах бараков №№ 4 и 5 в углах сырость, некоторые углы даже подгнили. В большой комнате 3 печи, а топится одна,—говорят, что на улице тепло, зачем топить все печи? Лампочек не дают, надеются на цеха, а цеха забыли дорогу в юнгородки. Где лампочки есть, там неисправна электропроводка, нет выключателей.

Квартплату берут за месяц вперед. А если не уплатишь, то угрожают, что не заверят стандартные справки на продкарточки и не будут их отоваривать. Тазов и ведер нет. В санпропускник посылают, а мыла дают только 10 граммов. Белье меняют часто, но после стирки оно становится грязнее, чем было.

Мы просим тов. Ефук и завком обратить внимание на все эти беспорядки и заставить т. Свиридова работать лучше.

Молодые рабочие.

Литературный уголок

Н. ГИЛЬЦЕБАХ

Подарок дочке

Сугыш чорындагы «Вперёд» газетасы.


Сугыш елларында Казан авиация заводының термик эшкәртү цехы.

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп, әлеге буын кешеләре алга атлаган, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылган. Алар юллар төзегән, күперләр сузган, электростанцияләр, заводлар салган, яу кырларында ватанны саклаган, самолётлар җыйган, сугыштан соңгы хәрабәләрне, җимереклекләрне күтәргән.

«Татарстан», үзенең каһарман якташлары белән очрашып, сезне әлеге фидакарь буынның маҗаралар тулы тормыш юлы белән таныштыруны дәвам итә.

Моннан алдагы тарихларны басмабызның 2022 елның - 10–12 нче, 2023 елның 1 нче саннарында укый аласыз.

11 НЧЕ ТАРИХ

Константин Карпов ничек итеп сугышчан самолётлар җыйган

Фотолар К.Карповның шәхси архивыннан; Юлия Кузнецова

11 НЧЕ ТАРИХ

КОНСТАНТИН КАРПОВНЫҢ «АЕРУЧА МӨҺИМ» ЭШЛӘРЕ

Наталья Урейская

Фото: Азат Яһүдин

Константин Карповка 98 яшь. Бөек Ватан сугышы елларында ул Казан авиация заводында, Пе-2 очкычы җыелган 50 нче цехта эшли.

Очкычны җыюга үзе дә зур өлеш керткәнгә, легендар Пе-2 турында һәр язма аңарда бүген дә зур кызыксыну уята. Шуңа күрә, «Татарстан» журналында Пе-2 бомбардировщикларында очкан «көндезге пәриләр» турында укыгач, Константин Владимирович фактларны шәхсән үзе тикшерергә карар кыла. Чөнки хатын-кызның мондый авыр машина белән идарә итә алуына ышанып бетми ул. Интернетта актарынгач, Константин Владимирович редакциягә шалтыратты – һәм без менә проектыбызның яңа герое, 57 ел Казан авиация заводында эшләгән шәхес янына кунакка киттек.

ТАБЕЛЬ НОМЕРЫ – 1731

– Безнең цех бик зур иде, биш участоктан тора: әзерлек бүлеге, слесарьлык-эретеп ябыштыру, детальләр җыю, стапельле җыю һәм стапельсез җыю участоклары, – дип санап китте Константин Владимирович. 80 елдан соң да ул үзенең табель номерын – 1731 санын хәтерли.

Ул эшләгән бүлек җыеп бетерү цехы янында урнашкан була. Ул чакта әле бик яшь эшче Константин Карпов цехка «свечка»лар* озатуында Сергей Королев (заводта аны Сергеев фамилиясе белән беләләр) килгәнен дә, конструкторның тизләтелгән очып китү системасын ничек эшләткәнен дә күрә. Пе-2 самолетының җиргә төшеп утырганда очучыдан бик югары квалификация таләп итүе дә һәркемгә мәгълүм була. Завод «шарашка»сында** эшләгән Королев һәм конструкторлар командасы «пешка»ны «ферзь»гә әйләндерүгә ирешкәч, ягъни Пе-2 очкычына ракета тизләткече көйләгәч, аның белән идарә итү тагын да кыенлаша.

* «Свечка» – кубесенчә винтовкалы әбиләрдән гыйбарәт хатын-кызлар конвоен заводта әнә шулай атаганнар, өлкән яшьтәге апалар, арып, кайчак берәр аулак почмакта йоклап та киткаләгән.
** «Шарашка» – ябык типтагы конструкторлык бюросы.

ӘТИСЕЗ КАЛДЫРГАННАР

Константин Владимирович бүлмәсендәге иң хөрмәтле урында полковник, Ленинград хәрби академиясе укытучысы булган әтисенең портреты эленеп тора. 1937 елда аны кулга алалар. Ә 1938 елның гыйнварында Владимир Николаевич Карпов атып үтерелә һәм «Кресты» дип йөртелгән төрмәдә җирләнә. Бу хакта туганнарына аклanганнан соң гына хәбәр итәләр.

– Гафу үтенгән хат кына җибәрделәр, – дип ачынып искә ала Константин Владимирович.

Әтисен төрмәгә ябуга, Ленинградтагы фатирларын тартып алалар. Карповлар Одессадагы туганнарына күченә. Бөек Ватан сугышы башлангач, аларны Краснодар краена эвакуацияләләр. Халык төялгән эшелонны юлда бомбага тоталар, аналы-уллы Карповлар документсыз да кала.

1942 елның җәендә алар яшәгән Белая Глина станицасына Казан авиация заводы вербовщиклары килә. Медицина комиссиясе чама белән Константинның «яшен билгели»***, туу турында яңа таныклык биреп, аны заводка эшкә алалар.

– Әти турында графада, аның турында күптән бернәрсә дә билгеле түгел, әти-әни 1930 елда аерылышты, дип язарга туры килде, – дип хатирәләрен барлый Константин Владимирович. – Аның чын язмышы турында әле озак вакыт яшереп йөрергә туры килде.

Шул рәвешле алар әнисе белән Казанга килеп эләгә. Константин – заводта слесарь, ә әнисе «Вперёд» газетасында корректор булып эшли.

СУЫК АРКТИКАДАН КАЙНАР СӘЛАМ

Константин Юнгородокта яши. Хәзерге Казан моторлар төзү заводы янында урнашкан бараклар бистәсе әнә шулай дип аталган. Аларның бүлмәсендә 50 нче цехтан 50 егет яши. Тормыш-көнкүреш хәрби казармадагы кебек, әмма кырыс кагыйдәләр яшьләргә Социалистик шәһәргә барып йөрергә комачауламый.

Гел ач үсмерләр кеше бәрәңгесен казып ашарга да мәҗбүр була. Ул чакта бәрәңгене микрорайонның бөтен буш территориясенә, «Крылья Советов» паркына һәм хәзерге Төньяк вокзалга илтә торган тимер юл буендагы җирләргә утырталар.

«Бу шөкәтсез фото 1941–1945 елгы сугыш вакытындагы яланаяклы сукбайлык тормышыбызны, эштә һәм маҗаралар кылгандагы дустыңны искә төшереп торсын», – Константин Владимировичның дусты Василий Голохвастов фотосурәтнең арткы ягына әнә шулай язып куйган. Бу фотоны дусты Ленинградтагы Арктика диңгез училищесына укырга киткән көнне бүләк итә. Соңыннан Василий «Арктика» атом бозваткычы капитаны була. Төньяк полюска фәнни-эксперименталь рейста катнаша, ике тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнә. Бозваткыч бортыннан Василий Голохвастов Казандагы дустына заводның 50 еллыгын бәйрәм итү турында хатының килеп ирешүен хәбәр


Заявление-анкета

Шәхси документлар.


Для разных отметок

ПОДПИСКА

Сер саклау турында язу кәгазе.


1731

Подписка

Я, гр. Карпов Константин Влад.

даю настоящую подписку заводоуправлению в том, что, находясь на заводе № 22, а также после ухода обязуюсь известные мне сведения, относящиеся к роду и характеру производства, количеству и качеству продукции, ее конструктивных свойств, условий внутреннего распорядка и прочее сохранять в строжайшей тайне, никому и ни при каких обстоятельствах не разглашать их.

Я предупрежден, что в случае нарушения данного обязательства буду привлечен к судебной ответственности, как за разглашение сугубо государственной тайны оборонного значения.

22 мая 1947 г. Подпись

62 862

*** «Яшен билгели» – Бөек Ватан сугышы елларында документсыз калучыларның яшен медкомиссия билгеләгән, чөнки фронтка бармас өчен кайберәүләр яшен яшерә торган булган.


Пусть этот безобразный снимок напоминает тебе нашу беспокойную и скитальческую жизнь в годы войны 1941–45 г. и твоего друга по работе и „похождениям".
Казань 25.07.47 г.
День отъезда из Казани.

«Бу шөкәтсез фото... яланаяклы сукбайлык тормышыбызны искә төшереп торсын», – Константин Владимировичның дусты Василий Голохвастов фотосурәтнең арткы ягына әнә шулай дип язып куйган.

итә. «Йөрәгем сыкрап куйды. Тормыш авыр иде, әмма шуңа да карамастан бик күп матур сәхифәләр, шул тормыш кыенлыкларын бизәпйомшартып җибәргән элекке тугры дусларның йөзләре хәтергә уелып калды. Ә безнең Юнгородок!.. Беләсеңме, шундый данлыклы заводта эшләргә насыйп булганга, мин горурлык хисе кичерәм», – дип яза капитан дусты. Хатта Василий Александрович завод эшчеләренә «зәмһәрир суык Арктикадан кайнар сәлам» тапшыра.

КАЙНАР ЦЕХНЫҢ ҖЫЛЫ ТАРИХЫ

Константин Владимирович әле дә сугыш чорындагы кышларның кырыслыгын яхшы хәтерли. Җыеп бетерү цехы янында эшләгән кешеләрнең салкыннан интегүләре дә исендә. Өч катлы йорт биеклегендәге һәм бөтен цех киңлегендәге зур капка һәр 2-3 сәгать саен ачыла – чираттагы Пе-2 чыгарыла. Бер көндә завод хезмәткәрләре фронтка 10-12 шәр самолёт озата! Чираттагы самолётны тәгәрәтеп чыгару шатлык та, шул ук вакытта үзәккә үтә торган суык та була.

Салкыннан бер генә нәрсә коткара. 50 нче цехтан ерак түгел җылылык белән эшкәртү цехы урнашкан. Ул бүген дә шул ук урында, һәм анда хәзер дә Бөек Ватан сугышы елларында башкарылган эшне эшлиләр. Температурасы 1000 градуска җитә торган тоз ванна-мичләрендә цех термистлары очкыч детальләренә аерым бер ныклык бирә. Цехка инде яңа мәйданчык бирелгән, тиздән ул тарихи урыныннан күчеп китәчәк. Ләкин бүген дә, монда килеп кергәч, авиатөзүчеләрнең туры мәгънәсендә иң җылы истәлекләре, аларның тормыш китабындагы онытылмас сәхифәләре калганын тоясың.

– Мөмкинлек чыгу белән, без шул кайнар мичләр янына җылынырга йөгерә идек, – ди Константин Владимирович. – Кайчак, Юнгородокка кайтырга хәлебез беткәндә, шунда кунарга да калгаладык. Термистлар беркайчан да берәүне дә кумады. Монда да башкалар кебек баш күтәрми көн-төн эшләделәр. Әмма салкыннан интеккәннәргә җылынырга кирәклеген аңлыйлар иде.

ҮТӘ ЯШЕРЕН

Василий Арктиканы яулап йөргәндә, аның дусты Константин белем ала, заводта яңа һөнәрләр үзләштерә. 1973 елның октябрендә авиация сәнәгате министры Петр Дементьев завод эшчеләренә яңа директор – Виталий Копыловны тәкъдим иткәндә, Константин инде җитештерү эшенең мәгълүмати куркынычсызлыгы өлкәсендә эшли.

Завод хезмәткәрләре яңа директорны шунда ук «Уссури юлбарысы» дип атый, чөнки Виталий Копылов үзе белән таныштырганда аларга бик гади генә: «Мин – тайга егете. Сезгә эшләргә килдем», – дип белдерә. Башта ул завод белән таныша, бөтен нәрсәгә төшенеп йөри. Аннары үз командасын формалаштыра башлый. Константин Владимировичны 1 нче бүлек җитәкчесе итеп билгели. Катгый серлелек режимында Ту-160 стратегик бомбардировщигын күпләп җитештерә башлау планлаштырыла. Ә аңарчы заводның яңа корпусын төзергә, аны җиһазлар белән тәэмин итәргә, персонал җыярга һәм аларны өйрәтергә кирәк.

– Виталий Егорович фотографка көн саен билгеле бер урыннан яңа корпус төзелешен фотога төшереп барырга кушты, – дип искә ала ветеран.

Дәүләт серен саклау өчен җитди чаралар күрелә. Ту-160 турындагы мәгълүмат чит илдәге гаммәви мәгълүмат чараларында беренче тапкыр иярченнәр самолётның Казан тирәсендә очканын күреп алгач кына пәйда була.

Завод ветераннары искә алганча, ашханәдә чират торганда кемдер: «Беренче бүлек килә, беренче бүлек!» – диюгә, кешеләр тынып кала. Һәм шундагы «Тел бистәсе – шпион өчен табыш» плакатына карап куя.

– «Үтә яшерен» дигән сүзләрне һәркем белә, әмма асылда бу рөхсәтнең икенче формасы гына, ә беренчесе «Аеруча мөһим» мөһере сугылган мәгълүмат белән танышырга мөмкинлек бирә. Әмма безнең бүлек нинди генә документ белән эшләсә дә, завод эшенә ярдәм итү төп принцип булды һәм шулай булып кала да. Беренче бүлек җитештерүне тоткарлау һәм чикләү өчен түгел, ә аны нәтиҗәләрәк итү өчен эшли, – ди ныклы ышаныч белән Константин Владимирович.

ЛЕГЕНДАР БУЫН

1991 елда Константин Карповка 67 яшь тула һәм ул 1 нче бүлек җитәкчесе вазифасыннан китә, әмма предприятиедә кала. 1999 елга кадәр заводның хәрби сак отряды башлыгы булып эшли. Аның заводтагы стажы 57 ел тәшкил итә.

– Константин Владимирович – җитәкчеләрнең легендар буыны вәкиле ул, – дип сөйли аннан бүлекне кабул итеп алган Владимир Анютов. – Алар хакында заводта эшләде дип әйтү дөрес булмас, алар заводта яшәде. Алар, авиациягә үлеп гашыйк булып, кешеләрне яңа үрләргә рухландыра торган акыл-зиһен һәм энергия мохитен булдырды. Ә завод шундый зур нәрсә ул, яңа тәҗрибә тупла-

– Константин Владимирович – җитәкчеләрнең легендар буыны вәкиле ул, – дип сөйли аннан бүлекне кабул итеп алган Владимир Анютов. – Алар хакында заводта эшләделәр дип әйтү дөрес булмас, алар заводта яшәде. Ә бу исә – 50 нче цех эшчеләре җыылынган әнә шул 11 нче цех инде.

Казан авиация заводы орденнары.

ган, яңа белемнәр алган һәркем анда үз урынын таба. Без дә, Константин Владимирович кебек кешеләрдән үрнәк алып, завод дип яшәдек. Ике улым, киленем, оныгымның да КАЗда эшләве шуны раслый. Мин аларда бу урынга мәхәббәт тәрбияли алдым.

Бүген кайберәүләр аптырашта, янәсе, ничек итеп заводта 50 шәр ел эшләп була? Алар уртак максат-бурычлар белән янып йөрүнең, бергәләшеп эшләүнең нинди бәхет икәнен аңламый. Без барыбыз да төрле, ләкин заводта булдыклы кешеләрне һәрвакыт күрәләр һәм югары күтәрәләр. Үз эшенә тугры, бөтен күңелен биреп эшләүчеләр турында әйтүем.

ОРДЕНЛЫ ЗАВОД

– Ә сез Анютовка нәрсә биреп калдырганымны беләсезме? – дип канәгать елмая Константин Владимирович. – Мин аңа завод орденнарын тапшырдым! Алар 1 нче бүлек җитәкчесенең сейфында саклана.

Заводның дүрт ордены бар: Ленин ордены – яңа техниканы уңышлы җитештерә башлаган һәм эшне яхшы оештырган өчен, 1933 елда алынган. Кызыл Байрак ордены – хәрби самолётлар җитештерү буенча хөкүмәт йөкләмәләрен үрнәк рәвештә үтәгән өчен, 1945 елда бирелә. Икенче Ленин ордены завод эшчеләренә сигезенче бишьеллык планын уңышлы үтәгән һәм 1971 елда яңа техника җитештерүне җайга салган өчен бирелә. Октябрь революциясе ордены, Ил-62 самолётларын җитештерүне көйләп, аларны сериялап чыгарган өчен, 1977 елда тапшырыла.

Бүген орденнарны хәзерге 1 нче бүлек җитәкчесе Валерий Мачин саклый. Валерий Сергеевич фикеренчә, әгәр предприятие орденнар белән бүләкләнгән икән, аның һәр хезмәткәре үзенең бу бүләкләрдә өлеше бар дип саный ала.

БЕР ГИМННЫҢ ИКЕ ЮБИЛЕЕ

Татарстан гимны быел икеләтә юбилеен билгеләп үтә: композитор Рөстәм Яхин 1970 елда ук Рамазан Байтимеровның «Туган ягым» шигыренә язган көй 30 ел элек гимн итеп раслана. Һәм тагын 20 елдан соң гына «Туган ягым» шигыренең сүзләре музыкага рәсми кушыла һәм республика гимны текстына әйләнә. Менә шундый кызыклы тарих.

Бу тарихны исебезгә төшерүче – шагыйрьнең кызы Гөлшат Кушилкова. Лениногорскида музыка укытучысы булып эшләүче ханым редакциябезгә килде һәм бусагадан ук Татарстан гимнын сузып җибәрде, һәркайсыбызга таныш көй-сүзләрне безгә аягүрә басып тыңлыйсы гына калды.

Аннары исә Гөлшат Рамазан кызы әтисе турындагы хатирәләре белән уртаклашты.

Фотолар Александр Ефремовтан; Гөлшат Кушилкова архивыннан алынды.



1 Рамазан Байтимеров.

2 Исмәгыйль авылында.

3 Гөлшат Рамазанова Үлемсез полк составында. 2019 ел.

БАЛАЧАГЫ ТУРЫНДА

– Апрельдә этинең тууына йөз ел булачак. Әмма ул, кызганыч ки, 66 яшендә үк бакыйлыкка күчте, – дип хатирәләр йомгагын сүтә башлады Гөлшат Рамазан кызы. – Ул Башкортостанда, Исмәгыйль авылында туган. Гаиләдә бишенче бала булган. Аңа изге рамазан аенда туганга, шундый исем кушканнар. Авылда башлангыч мәктәп кенә булган, аннары күрше авылга йөреп укырга туры килгән...

Булачак шагыйрь математиканы яраткан һәм бик шук булган. Мәктәптә тәртип бозган өчен аны еш кына почмакка бастырганнар – совет мәктәпләрендә сугышка кадәрге чорда «хулиганнарга» шундый «кырыс җәза» бирелгән. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, белем эстәргә Үзбәкстанга чыгып киткән.

– Апасы янында Кәттәкурганда яшәгән, Сәмәркандка поезд түбәсендә бара торган булган, чөнки билетка акчасы җитмәгән, – дип дәвам итә Гөлшат Рамазан кызы. – Ташкентта укытучылар курсын тәмамлаган, һәм шул вакытта сугыш башланган.

СУГЫШ ТУРЫНДА

– 1941 елның көзендә аны инде Кызыл армиягә алганнар. Шәхси билетында «1941 ел. Ашхабад–Иран» дигән язу бар. Иранда ничек хезмәт иткәндер, белмим, эти сугыш турында сөйләргә яратмый иде. Әмма аннары Мәскәү янындагы 620 нче укчы полкка эләгүе, десантчылар мәктәбендә укуы хакында беләм. Парашюттан йөз тапкырлап сикергәнен искә ала иде – бер дә курыкмаган, күрәсең, шук балачагы, вагон түбәсендә үткән чая яшьлеге аны кыю, тәвәккәл иткәндер.

1943 елда инде ул 2 нче Балтыйк буе фронты составындагы радиотелеграфчылар төркеме командиры була. Венгрия, Чехословакияне азат итүдә катнаша... Әтием өенә 1945 елның ноябрендә генә әйләнеп кайта. Сугыш әле бик озак еллар дәвамында төшенә кереп җәфалады, төннәрен ыңгырашып чыга, кычкырып уяна иде...

күрсәтмәскә тырышса да, 39 яшендә беренче инфаркт тикмәгә генә булмагандыр инде.

Аннары фотога төшерү белән мавыкты, колхозлар буйлап йөрде, алдынгыларны сурәткә төшерде, мәкаләләр язды.

1970 елда, ТАССР ның 50 еллыгына, аның «Туган ягым» шигыре белән илһамланган Рөстәм Яхин музыка язгач һәм әлеге җыр патриотик конкурста җиңгәч, бик горурланды. Җырны күренекле артистлар башкаруында телевизордан күрсәткәндә, тавышын көчәйтеп куя иде...

Ә безнең өйдәге архивта этинең кулдан язган һәм картонны без белән тишеп тышлап куйган шигырьләр китабы хәзергә кадәр саклана.

ШИГЫРЬЛӘР ТУРЫНДА

– Математика белән мавыгу, шаяншук балачак, парашюттан сикерү, сугыш һәм кинәт... шигырьләр. Күпчелеге лирик, табигатькә, туган якка, тормышка мәхәббәт белән сугарылган шигъри юллар, – дип, фикерләре белән уртаклашуын дәвам итә Гөлшат Рамазан кызы. Һәм этисенең үзен Язучылар берлегенә алмауларына бик борчылуын исенә төшерә.

– Шигырьләре газеталарда басылган, ләкин берлеккә кабул итмәгәннәр... Хәзер генә ул кайгырмасаң да була: алмыйлар икән – бигайбә. Интернет, төрле грантлар аша иҗатың белән таныштыру мөмкинлеге бихисап. Ә ул чакта, Язучылар берлеге әгъзасы булмасаң, сине шагыйрьгә дә санамаганнар, күрәсең. Ул үзенең борчылуын

АЛМАГАЧ ТУРЫНДА

Рамазан Байтимеров үз шигыренең гимн сүзләренә әйләнгәнен белмичә бакыйлыкка күчә. Ә менә алмагачына бу мәгълүм. Һәм бу тагын бер гаҗәеп тарих.

– Вафатына бик аз вакыт кала, эти безнең кишәрлеккә (ул чакта бөтен кешегә дүртәр сутый җир бүлеп бирәләр иде) алмагач утыртты, – дип сүзен дәвам итә Гөлшат Рамазан кызы. – Ул утырткан алмагачлар күп иде, әмма бусы – өй янындагысы – нигәдер корыды. Тик аны кисеп ташларга беркемнең дә кулы күтәрелмәде – эти истәлеге бит. Һәм менә күпме еллар үткәч, ул кинәт шау чәчәккә күмелде! Без моны яхшыга юрадык. Нәкъ шул вакытта мин аның «Туган ягым» җыры сүзләрен псевдоним астында конкурска җибәргән



4

Шигърият кичәсендә.

5

Редакциядә эшләгән чор.

6

Татарстанның Дәүләт гимнын кабул итү. 2013 ел.

идем – Татарстан гимны текстын сайладылар ул чакта.

Һәм менә мин 2013 елның 21 февралендә Салих Сәйдәшев исемендәге Концертлар залында гимнның рәсми яңгырашы тантанасында утырам. Миңа бу төш кебек тоелса да, өн иде ул. Сладковский җитәкчелегендәге оркестр уйный, хор һәм солистлар шулкадәр тантаналы итеп, рухланып җырлый ки, минем күземнән яшь ага. Гимн башта татарча, аннары русча яңгырый. Кайбер сүзләре үзгәртелгән, шагыйрь Гәрәй Рәхим тарафыннан иҗади эшкәртелгән, тик бу барыбер минем этием – Рамазан Байтимеров сүзләре! Русчага исә бик талантлы шагыйрь Филипп Пираев тәрҗемә иткән.

Менә ни өчен чәчәк аткан икән безнең алмагачыбыз!

ҖЫРЛАРДА ОЧРАШУ ТУРЫНДА

– Кабат кайту мөмкин булмаса да
Яшьли узган ерак елларга.
Үлсәк тә без, очрашырбыз әле,
Очрашырбыз әле җырларда! – дип язган этием үзенең композитор Рөстәм Яхинга багышланган «Җырларда очрашу» шигырендә. Аның бу шигырен Филипп Пираев рус теленә дә тәрҗемә итте, – дип тәгәлләде үзенең хатирәләрен Гөлшат Рамазан кызы. – Шулай булып чыкта да. Алар икәү күп җыр язган. Алар арасында «Җиңү җыры», «Йөрәк җыры», «Романтика», «Әнкәй», «Каен суы», «Төнбоек», «Шәһәрләрнең гүзәле син» һәм башкалар әле дә халык күңелендә яши.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГИМНЫ

Рөстәм Яхин музыкасы
Рамазан Байтимеров сүзләре
Русчага Филипп Пираев тәрҗемәсендә

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живет в согласии наш народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!

КУРАЙЧЫГА СҮЗ ӘЙТМӘГЕЗ...

Руфия Фазылова

Ятим бала моңлы була, ди халкыбыз. Бүгенге көндә Казанның Тынычлык бистәсендә яшәүче Рафаэль Гайзетдинов, тулы ятимлектә үсмәсә дә, әнисез калуның ни икәнен бик яхшы белә. Малайга бер яшь чагында әнисе вафат була. Рафаэль әтисе, үги әнисе тәрбиясендә үсә. Нечкә күңелле малай әле укырга кергәнче үк таш сыбызгыда уйнарга өйрәнә. Аннан кулына гармун ала, соңрак исә – курай. Нәтиҗәдә, бүген ул республиканың иң атаклы (бердәнбер дисәм дә, арттыру булмас!) курай ясаучысы. Казанның Тынычлык бистәсендә үзенең остаханәсе бар.

ГАРМУНЧЫГА ХӨРМӘТ

Рафаэль абый Актаныш районының Иске Байсар авылында туып үсә. Сөн елгасы суында коенып, балачактан моңлы, ихлас бала була. Мәктәпкә укырга кергәнче үк, үзлегеннән тальян гармунда уйнарга өйрәнә. Күрше абыйсыннан гармун алып чыга, мунчага барып, сәгатьләр буе уйный. Аннары, рәхмәт әйтеп, гармунны кертеп бирә. Мәктәпкә укырга кергәч исә, баянда уйнарга өйрәнә.

– Мәктәптә укыганда физика укытучысы Галим абый Исламов тавыш дулкыннары ничек барлыкка килүе турында сөйләде, – ди Рафаэль абый. – И, шул теманы яратып тыңладым. Үзем ясаган калай сыбызгының

Фото: Александр Ефремов

ничек тавыш чыгарганын гел беләсем килә иде. Ә укытучым аңлатты. Галим абый баянда да уйный белә. Мин аның баян төймәләренә ничек басканына мөкиббән китеп озак карап тора идем. Баян – тальян гына түгел, аның тавышы нәфисрәк, затлырак чыга кебек тоелды.

Әнә шулай итеп укытучы абыйсы Рафаэльне баянда уйнарга өйрәтә. Әле укучысын гел мактап та тора: «Бармакларың ятышлы килеп тора, гармунчы булырсың!» – ди. Һәм чынлап та үсмер малай мәктәптә үткәрелә торган бәйрәмнәрдә баянда уйный башлый. Алай гына да түгел, аны өлкәннәр үзләре белән концертлар куярга йөртә:

– 1965 елда Иске Байсарда мәдәният йорты ачылды, – дип искә алды Рафаэль абый. – Миңа ул чагында 16 яшь иде. Мәдәният йорты каршында җыр-бию ансамбле оештырдылар, ә мин баянчы булдым. Төрле фестивальләрдә катнашып, үзебезне бөтен республикага таныттык. Ул вакытларда транспорт белән проблема зур, бигрәк тә кыш көннәрендә кар баскан юлларда йөрергә авыр иде. Укытучылар мине, трактор чанасына утыртып, толып белән төреп куя да, китәбез күрше авылга – концерт куярга. «Борыныңны өшетмә, толыптан башыңны чыгарма», – ди өлкәннәр. И, җылыда оеп барасың трактор арбасында. Ә кире кайтканда юл буе йоклыйсың. Рәхәт инде. Ул чагында авыл клублары агачтан төзелгән иде. Күбесе – манарасы киселгән мәчет бинасы. Алар төрлечә җиһазландырылган: түрдә тактадан сәхнә ясалган. Сәхнә өстендә киноэкран тора, ул рулонга төрелеп күтәрелгән. Клуб эче кеше белән тулы. Ишек төбеннән үк тәмәке исе аңкый. Халык гөр килә, чөнки клублар иң беренче чиратта аралашу урыны да иде.

Мәктәпне тәмамлаганда егет үзе өчен тәгаен хәл иткән була – музыкант булачак. Һәм туры Түбән Кама музыка училищесына укырга китә.



Хуҗаның остаханәсенә узабыз: нинди генә станоклар юк монда! Ул аларның күбесен үзе ясаган.

ҺӘР БАЛАГА – КУРАЙ!

Инде аңлашылганча, Рафаэль абый музыка дөньясында үз кеше. Ул төрле уен коралларында уйный белә, шул исәптән курайда да.

Хуҗаның остаханәсенә узабыз: нинди генә станоклар юк монда! Ул аларның күбесен үзе ясаган. Тәҗрибәләр үткәреп, моңысын сүтеп, тегесен җыеп, төрле зурлыктагы курай ясау җайланмаларын эшләгән.

– Музыкант булмаган осталардан өмет юк, – ди Рафаэль абый. – Алар курайның мөмкинлекләрен белми, тоемлау кирәк монда.

– Ә сез ничек курай ясый башладыгыз?- дим.

– Казанда курай 2010 нчы елларда популярлаша башлады. Мин ул чагында Казанның 20 нче музыка мәктәбендә укыттым. Миңа курай дәресләре алып барырга куштылар. Менә шул чагында әлеге уен коралына кытлык сиздем. Шуннан, нигә әле үземә курай ясамаска, дип уйладым.

– Курай ясау авырмы?

– Җиңел түгел, шактый четерекле эш. Курайның нигезендә алюминий торба бит. Шуның башына эбониттан ясалган җайланма куям, ул җылылыкны саклау өчен кирәк. Аннан аны акрил белән әйләндереп алам. Без ул өлешне мундштук дип атыйбыз. Менә шул мундштукны ясау өчен генә дә унбер төрле эш башкарырга кирәк.

Рафаэль абый ясаган курайларның күбесе алюминийдан. Алар агачны хәтерләтсен өчен, станокта полимер буяу белән кап-



лана. Агач курайдан аермалы буларак, алюминий ярылмый, ватылмый. Кыскасы, балаларга уйнарга өйрәнү өчен бер дигән.

Рафаэль абый өчен курай ясау шөгыль генә түгел, ә яшәү рәвеше дә. Ул көн саен бирелә – остаханәсендә. Кыш диме, җәй диме... Мисал өчен, бүген сатуга дигән йөзләгән курае бар, ә ул һаман яңаларын ясый. Тик тора алмый.

– Курайларны күпләп алучы булганда сөенәм, – диде оста. – Ә андый заказлар гел булмый. Әйе, берне-икене гел алып торалар.

Рафаэль абыйның иң зур хыялы – республика мәктәпләрендә укучы һәр башлангыч сыйныф укучысын курайлы итү. Ә нәрсә, әлеге уен коралында уйнарга өйрәнү авыр түгел. Шуның белән бергә курай тын алуны җайга сала, үпкә эшчәнлеге өчен бик файдалы.

– Сәламәтлеккә файдасы бер, икенче уңай ягы – музыкаль инструмент тоткан бала беркайчан начар булып үсми, чөнки ул тәрбияле, зыялы була, – диде остаз.

Рафаэль абый безне түргә чакырды. Баксаң, останың янә бер яңалыгы бар икән – эбониттан курай ясап караган. Кемнәндер ишетеп, күреп эшләгән әйбере түгел, үзе шулай теләгән.

– Эбонит физика дәресләреннән таныш, ул кабинетларда бар, - диде оста. – Шуның тавышын ишетеп карыйсым килде. Эбонит таякчыкларын заказга кайтардым да, эчен алып, шомарттым. Бер дигән уйный.

– Уйлап табу сәләтегез дә бар икән, – дим.

– Бардыр инде. Әткәй уйлап табучы иде безнең. Колхозда механик, инженер булып эшләде ул. Трактор, моторлар сүткәндә төрле җайланмалар уйлап таба иде. Күрәсең, миңа да бу сәләт күчкән.

Остаханә диварларына күз салам: түрдә Илһам Шакиров, Сара Садыйкова, Салих Сәйдәшев портретлары эленгән.

– Мондый күзәтүчеләр булганда ялгышырга ярамый, – дип елмайды Рафаэль абый. – Кечкенә чагымнан ук Илһам Шакиров җырларын җырлый идем. Хәтерлим, икенче сыйныфта укыганда «Сәлам сиңа, әнием» җырын башкардым. Бөтен мәктәп елады... Ул вакытта ук мине «моңлы бала» дип йөрттеләр.

«МИН АНДЫЙ ӘТИ БУЛМЫЙМ!»

Алда әйтеп узган идем – Рафаэль абыйны язмыш иркәләми. Үги әни белән үсүдән кала, эти игътибары да тәтеми аңа. Эштән салгалап кайткан ата кеше, гомумән, күп вакыт Рафаэльне күрми дә. Юктан да кул күтәрүләр... Ләкин әңгәмәдәшем бу турыда сөйләргә бик яратмый. Әтисе күптән мәрхүм инде, үлгән кеше турында начар сөйләмиләр. Аннары, җан ярасын куптару нигә кирәк? Үткәннәрне барыбер кире кайтара алмыйсың...

– Үги әни кыерсытмадымы соң? – дим сак кына.

– Үги әнине начар булды дип әйтә алмыйм. Дөресен генә әйткәндә, аның үги икәнлеген унөч яшькә җиткәч кенә белдем. Яңа әни-

нең минем яшендәге ияртеп килгән кызы бар иде. Аның белән тату булдык. Әле аннары да эти белән уртак тагын биш бала тапты. Шуның өчен үги әнинең минем белән утырырга җае да булмагандыр. Тәрбия күрмәгәнгә, кечкенә чакта чирле булдым: рахит белән дә авырдым, күзләрем дә начар иде. Көннәр буе кояш яктысы күрми сәкедә ята идем. Аллаһның рәхмәте белән, биш-алты яшьләремдә тернәкләндем. Үземә иптәшләр таптым... Авыр булды балачагым, бик авыр. Халык әйтә бит: «Атадан калган ярты ятим, анадан калган бөтен ятим», – ди. Бик дөрес сүзләр ул.

Күңеле нечкәреп, этисенә үпкәләп яткан көннәрдә Рафаэль үзенә сүз бирә – ул яхшы эти булачак! Балаларын какмаячак, сукмаячак, аларга дәрес әзерләргә булышачак, серләрен бүлешәчәк. Һәм сүзендә тора да – үрнәк эти, дәү эти ул. Хәләл җефете Әлфия апа белән дүрт кыз тәрбияләп үстергәннәр. Алты оныклары бар. Бергә гаилә коруларына җәйгә илле ел була икән.

– Танышканда миңа егерме ике, Әлфиягә егерме яшь иде, – дип, гаилә тарихын сөйләде Рафаэль абый. – Ул вакытта Түбән Кама музыка училищесын тәмамлаган идем. Юллама белән Кукмарага эшкә җибәрделәр. Танышып ике ел узгач, Әлфия белән гаилә кордык. Ун ел Кукмара музыка мәктәбендә эшләдем, аннары район мәдәният йорты җитәкчесе итеп куйдылар. Ләкин мәдәният йортында хуҗалык эшләре теңкәгә тиде. Мин бит сәнгать кешесе, җыр, моң, балалар белән эшләүне яратам. Шуның өчен дә бу эштән китү ягын карадым.

Әнә шулай унөч ел яши алар Кукмарада. Аннары Түбән Кама районының Кама Аланы бистәсенә күченәләр – Рафаэль абый музыка мәктәбенә урнаша. Яшәргә дүрт бүлмәле фатир бирәләр. Мөгаллим, район администрациясеннән аерым бина сорап, җыр-моңга сәләтле яшьләрне җыя, «Бормалы су» ансамблен төзи. Татар җырларына, биюләренә йөз тоткан ансамбль белән төрле бәйрәмнәрдә чыгыш ясый башлыйлар. Ләкин көннәрдән бер көнне, бөтен шушы көйләнгән тормышларын ташлап, балалар дип, ир белән хатын Казанга күченеп китәргә карар кыла.

– Олы кызыбыз Йолдыз, университетны тәмамлап, Казанда юрист булып эшли башлаган иде, – диде Рафаэль абый. – Икенче кызыбыз 2004 елны унберенчене, өченчебез Наилә тугызынчы сыйныфны тәмамлады. Лилия Казан дәүләт икътисад институтына, ә Наилә Казан юридик көллиятенә укырга кереп кайтты. Төпчегебез Айгөл мәктәптә укый иде әле. Йолдыз әйтә: «Эти, шулай ике кызыгызны чыгарып җибәрергә курыкмыйсызмы? Бигрәк яшьләр бит. Әйдәгез, Казанга күченеп килегез. Болай аерым яшәү ярамас», – ди. Әлфия белән шулай киңәштек тә, ишекне бикләп, Казанга юл тоттык... 20 нче музыка мәктәбенә эшкә урнаштым. Йолдызыбыз бик үткен, ул инде эшли иде. Гаилә чыгымнарын тартырга ул да ярдәм итте. (Йолдыз ханым бүген Казанның Совет районында судья булып эшли – авт.) Яшермим, Казанга ияләнергә авыр булды. Ике бүлмәле фатирга кайтасың да, бикләнеп утырасың.

Әнә шуның өчен дә кызлар эти-әниләренә йорт карый башлый. Авылда үскән кешеләр бит, җир кирәк. Рафаэль абый бу фикерне биш куллап хуплый. Әнә шулай итеп Тынычлык бистәсеннән зур гына йорт сатып алалар. Һәр кызның үз бүлмәсе бар. Һәр шимбә саен төп нигезгә дүрт кыз да гаиләләре белән килә. Мунчадан соң барысы бергә түгәрәк өстәл тирәли җыелып чәй эчәләр...

– Рафаэль малай табуымны теләде, – дип сүзгә кушылды Әлфия апа. – Шуның өчен дә кырыкка җиткәч, малай булмасмы дип, тагын бер бала алып кайттым. Анысы да кыз булды. Ә хәзер сөйләшәбез – әле ярый кызлар булганнар. Алар терәк тә, киңәшче дә. Мәктәптә берсеннән-берсе яхшырак укыдылар. Безгә бер проблема тудырмадылар. Инде алга таба да шулай гына була күрсен.

Алма алмагачыннан ерак төшми, ди халык. Матур гаилә алар. Рафаэль абый кызларында да сәнгатькә, туган телгә мәхәббәт тәрбияли алган. Кызларның барысы да музыка мәктәбен тәмамлаган. Инде оныклар музыка мәктәбендә укый. Иң мөһиме – оныклар татарча сөйләшә. (Икесе Казан шәһәренең 2 нче татар гимназиясендә белем ала.) Һәм аларны дәү этиләре курайда, баянда уйнарга өйрәткән. Рафаэль абый соңгы елларда Илһам Шакиров исемендәге 32 нче татар музыка мәктәбендә эшләгән. Ләкин сәламәтлеге белән бәйле китәргә туры килгән. Бүген аның төп юанычы – курай ясау.

Останың янә бер яңалыгы бар – эбониттан курай ясап караган.

ХЫЯЛДАГЫЧА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ

Моннан ун ел элек «РэйнБлэйд» компаниясе үз алдына Россиядәге ягулык салу станцияләре (ЯСС) базарын тамырдан үзгәртерлек максатлар куя. Сайланган курс үзен тулысынча аклый. Компания үзендә үзәкләштерелгән тәэмин итү агрегаторын, IT-компанияне һәм комплекслы маркетинг агентлыгын берләштергән ЯСС челтәрләренең уникаль партнерына әйләнә. РФ базарында тиңдәше булмаган мондый синергетик чаралар комплексы нәтиҗәле клиентлар тәҗрибәсе туплауны гына түгел, бәлки трендка шәп туры килә торган, кайвакыт бөтенләй көтелмәгән чишелешләрне гамәлгә ашыруны да тәэмин итә.

ЮЛДА КАҺВӘ КИРӘКМЕ?

Автоһәвәскәр, бигрәк тә профессиональ машина йөртүче өчен автоягулык салу станциясен сайлаганда иң мөһиме – ягулыкның бәясе һәм сыйфаты. Әмма сайлау мөмкинлеге булганда безнең һәркайсыбызның бензин исе түгел, бәлки тәмле каһвә һәм яңа пешеп чыккан ризыкның хуш исе аңкып торган автостанция хезмәтеннән файдаланасы килә. Шунда ук һавасын чыгарган көпчәкне тутыру, автомобиль өчен фирма товарлары, шулай ук ниндидер ме-

Фотолар «РэйнБлэйд» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

дицина кирәк-ярагы һәм гадәттән тыш хәл килеп туганда ярдәм итү өчен кирәкле препаратларны сатып алу мөмкинлеге дә булса, тагын да яхшырак, әлбәттә...

Бүгенге көндә ЯСС челтәрләре клиентлары таләпчәнрәк була бара. Көндәшлек зур булган базарда башкалардан яхшы якка аерылып торырга кирәк. Моның өчен ягулыкны ваклап сату операторларының барысы да миллионлаган клиент йөрәгенә яңа юл табарга тырыша, бу аларның эшендә өстенлекле юнәлешкә әйләнә.

«РэйнБлэйд» компаниясенең тиңдәшсез комплекслы хезмәт күрсәтү тәҗрибәсе Россиядә беренче тапкыр «Татнефть» ЯСС челтәрендә тулы куәтендә кулланыла башлый. Тәүге проект Мәскәү төбәгендә эшләп китә, ә бер елдан соң инде Архангельскидан Кемеровога кадәр булган барлык станцияләрдә гамәлгә кертелә.

«РэйнБлэйд» компаниясенең IT-белгечләре, «Татнефть» партнерлары арасында беренче булып, электрон документлар әйләнешен (EDI) кертә. Әйтик, «Татнефть» ГАҖ ягулык салу станцияләренә товарлар китерү белән бәйле барлык коммерция һәм логистика документлары тулысынча цифрлаштырыла.

2022 ел азагында «РэйнБлэйд» компаниясенең тагын бер IT-эшләнмәсен – челтәрнең барлык тәэминатчылары өчен камиллләштерелгән автомат заказлар системасын интеграцияләү тәгәлләнә. Ул ЯСС персоналы хезмәтен шактый җиңеләйтеп һәм шуның белән клиентларга хезмәт күрсәтүне яхшыртып кына калмыйча, кибет һәм кафелардагы сәүдәне арттыру мөмкинлеген дә бирә. «Татнефть» ГАҖ белән уртак проектны дәвам итү кысаларында 2023 елда «Автозаказ»ны бөтен челтәрдә дә куллана башлау планлаштырыла.

ЯСС буенча белгечләр яхшы белә: станциядә ягулыктан соң иң кирәкле продуктларның икенчесе – каһвә, һәм бу өлкәдә «РэйнБлэйд», «Татнефть»нең комплексны партнеры буларак, берничек тә читтә кала алмый иде. «РэйнБлэйд»ның IT-чишелешләре станцияләрдәге каһвә аппаратларын бердәм челтәргә берләштерү мөмкинлеген бирә, шул рәвешле «Татнефть» компаниясенең каһвә бизнесы белән идарә итүдә үз интеллектуаль системасы булдырыла. Каһвә пешерү өчен җиһазлар дистанцион идарә ителә, бу бердәм рецептураны саклау һәм хәтта иң еракта урнашкан станцияләрдә дә эчемлекнең югары сыйфатын тәэмин итү мөмкинлеген бирә. Берничә йөз каһвә машинасының өзлексез эшен «РэйнБлэйд» диспетчерлык үзәгенең тәүлек буена ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәте тәэмин итә. «Татнефть» ГАҖ ЯСС ихтыяҗлары өчен махсус эшләнгән IoT-чишелешләрнең тиңдәшсез комплексы каһвә әзерләү зоналарының барлык параметрларын онлайн-режимда күзәтү һәм аларга дөрес хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту мөмкинлеген бирә. Аппаратның ватылуы турында сигнал алгач, мониторинглау үзәге операторы ЯСС хезмәткәрләре белән элемтәгә керә һәм, чит сервис компаниясенең кыйбатлы белгечләрен җәлеп итмичә генә, аларга проблеманы мөстәкыйль хәл итәргә булыша. Моның нәтиҗәсендә каһвә машинасы ватылгандагы проблемаларның яртысы диярлек ерактан торып хәл ителә, ә сатудагы өзеклекләр 80 процентка кими.

«РэйнБлэйд» белгечләре уйлап тапкан башка җайланмалар каһвә машиналарының сөт системасын чистарту регламентларын, зур шешәләрдә – су, диспенсерларда стаканнар булуын, көнкүреш калдыклары өчен контейнерларның вакытында бушатылуын контрольдә тота. Аерым электрон блок суыту җиһазлары эшен күзәтә һәм, ашамлыкларны саклау режимында ниндидер тайпылышлар килеп чыккан очракта, бу турыда диспетчерлык үзәгенә һәм ЯСС администрациясенә хәбәр итә.



Хәзерге вакытта яңа проект: ЯСС каршында үз брендлары – Green Light кафеларын булдыру гамәлгә кертелә. Биредә сәламәт туклану концепциясе хөкем сөрә. Клиентлар рәхәтләнеп туклана, шулай ук татар халык ашларыннан авыз итә алачак.

ТОТАШ ЦИФРЛАШТЫРУ

Татарстан Республикасында урнашкан «Татнефть» ягулык салу станцияләреннән берсендә «РэйнБлэйд» белгечләре тулы бер IoT-экосистема булдырган – мониторинглау үзәгенә каһвә сату зоналарын һәм суыту җиһазларын гына түгел, башка системаларны да тоташтырган (хәтта станциянең бәдрәф бүлмәләрендәге диспенсерларны да). «Татнефть» ЯСС челтәре инфраструктурасының мониторинглау үзәген – станцияләр эшчәнлегенең ягулык сатуга бәйле булмаган барлык аспектлары белән идарә итә торган программа-аппарат комплексын төзү «Татнефть» автостанцияләрендәге ягулыкка кагылышы булмаган бизнесны цифрлаштыруның мантыйкка ярашлы дәвамына әйләнергә тиеш.

БРЕНД КЫЙММӘТЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНГӘН МӘДӘНИ КОД

«Татнефть» ЯСС челтәре һәм «РэйнБлэйд» компаниясе партнерлыгының маркетинг асылы күптән инде сатуларны яхшыртуга кагылышлы традицион бурычларны гына хәл итүдән ерак китте. Бик файдалы ике еллык хезмәттәшлек нәтиҗәсендә партнерлар Татарстан Республикасы мәдәни кодын популярлаштыру буенча бик күп уңышлы уртак проектларны тормышка ашырды. Мәсәлән, татар Кыш бабае байтак маркетинг интеграциясе героена әйләнде. Бөтен Россия буенча клиентлар Кыш бабай белән мобиль уеннарда, рекламаларда һәм хәтта Яңа елга багышланган стаканнарда «очрашты». Танылган татар рәссамнарының картиналары, шулай ук Татарстанның кабатланмас истәлекле урыннарына багышланган сувенирлар башка тиңдәшсез прокоммуникацияләр геройларына әйләнде. Хәтта маскот – «Татнефть»нең миллионлаган клиентлары яратып өлгергән бөтиперсонаж да республикабыз символы Ак Барс образында ясалган.

ВАКЛАП САТУ ТРЕНДЛАРЫ: КОМПЛЕКСЛЫЛЫК ҺӘМ ПАРТНЕРЛЫК

Ягулык-энергетика тармагы белгечләренең фикере бердәм – алдагы елларда илдәге эре ягулык салу челтәрләре белән ягулыкка кагылышы булмаган бизнесның нәтиҗәлелеген арттыру бурычларын комплекслы хәл итәргә сәләтле технология компанияләре арасында партнерлык үсәчәк. Әлеге хезмәттәшлек төрле формаларда гамәлгә ашырылачак. Компания белгечләре фикеренчә, иң нәтиҗәле юл – ягулык компаниясе ресурсларын һәм комплексы партнерның креатив идарә итү командасын берләштерә торган уртак предприятиеләр төзү. «Татнефть» ЯСС челтәре һәм «РэйнБлэйд» компаниясенең уңышлы партнерлыгы мондый фаразларның хаклыгын дәлилли торган мисал булып тора.

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:
тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+

«ИНЖЕНЕРЛАР РЕСПУБЛИКАСЫ»НЫҢ 7 КАНУНЫ

Районнарга техник белгечләрне ничек җәлеп итәргә? Сәнәгать белән бәйле һөнәрләрне яшьләр арасында ничек популярлаштырырга? Бу сорауларга җавапны илебез министрлыклары, предприятиеләре, югары уку йортлары, мәктәпләре бергәләп эзли. Фән һәм технологияләр өлкәсендә алда баручы Татарстан үз җавапларын тәкъдим итә.

«Безгә бу проект кирәкме? Ата-аналар кызыксынырмы? Балаларга авыр булмасмы?» – район мәктәпләре базасында инженер сыйныфлары ачу буенча Казандагы коллегаларының инициативасына Татарстандагы бер уку йорты коллективы шулай шикләнеп түгел, ә өметләнеп...

Фотолар Казан шәһәренең Лицей – инженерлык үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА

ИЛСУР ҺАДИУЛЛИН,
Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры:

– Татарстанга авиация һәм машина төзелеше җитештерүләренә, нефть-газ химиясе сәнәгате, IT, төзелеш тармагы өчен югары квалификацияле кадрлар кирәк. Димәк, химия, биология, физика, информатика буенча яхшы әзерлекле абитуриентлар таләп ителә. «Инженерлар республикасы» инженер-техник эшчәнлеккә сәләтле нәкъ менә шундый укучыларны ачыклый һәм әзерли. Проектны инновацион дип атарга була: республикада модульле укытуны, проект эшчәнлеген һәм коммуникатив күнекмәләрне технологик профильле мәктәп белеменең ярдәм концепциясенә берләштерү практикасы юк иде әле. Укытуда мондый алым тарала барган саен, Татарстанның кадрлар потенциалы һәм көндәшлеккә сәләте көчлерәк булачак.



цепциянең безнең үсеш турындагы күзаллауларыбызга яхшы туры килүе аңлашылды. Инде ярты елдан соң ук яшь «инженер»ларыбызның беренче уңышлары күренде, педагоглар һәм ата-аналарның уңай фикерләрен ишеттек. Мин һәрвакыт Казаннан еракрак урнашкан мәктәбебезнең районның башка уку йортларыннан нәрсә белән дә аерылып торуын тели идем. Без инде күппрофильле лицей булып торабыз, әмма нәкъ менә «Инженерлар республикасы» белем бирү процессы нигезенә салынган лингвистик һәм техник юнәлешләр тандемы укучыларыбызга илебездәге инженерлык эшенә кушылып китәргә мөмкинлек бирәчәк, – ди **Кукмараның А.М.Булатов исем. Күппрофильле лицее директоры Любовь Камалова**.

1 НЧЕ КАНУН. «ЛИНГВО» + «ТЕХНО» = ШӘП ПРОФЕССИОНАЛ

Бу юл, беренче карашка, бик гади нәрсәдән – лингвистик һәм техник юнәлешләрне берләштерүдән башлана.

– 2015 елда Казанда лицеебызны ачканда, без бик гади фикергә нигезләндек: киләчәк белгече, инженерлык белемен күздә тоткан хард-күнекмәләрдән тыш, софт-белемнәргә дә ия булырга, ягъни берничә телдә сөйләшә алырга, элемтә кора һәм халык алдында чыгыш ясый белергә, дөньяда үз урынын таба белергә тиеш, – ди **Лицей – инженерлык үзәге директоры Венера Хәйретдинова.** – Һәм без үз «лингво+техно» концепциясен уйлап таптык. Көннең беренче яртысында балалар ФГОС буенча белем ала, икенчесендә аларны лингвистик театр, робот техникасы, программалаштыру, 3D-модельләштерү көтә. Эшли башлап, ике ел узуга, мондый уку-укыту форматына ихтыяҗның Казан чикләреннән шактый ары чыгып китүен аңладык. Районнарда укыту өчен, педагогларыбызның сәфәрләрен дә оештыра алабыз, дигән карарга килдек. Шулай итеп, 2017 елда «Инженерлар республикасы» проекты барлыкка килде.

Әлеге ниятне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та хуплый. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, А.Н.Туполев исем. Казан милли тикшеренү техник университеты (КМТТУ-КАИ), Яшьләрнең инновацияле иҗаты үзәге (ЦМИТ-КАИ), Speak English инглиз теле мәктәбе белән хезмәттәшлек итеп, Казан лицее белгечләре шулай ук техник белем бирү теләге белән янган, үз мәктәпләрендә «лингво» һәм «техно» берлеген кертергә әзер булган педагогларны эзләп юлга чыга.

2 НЧЕ КАНУН. АВЫРЛЫКЛАРДАН КУРЫКМА

– Миңа Стивен Хокинг үрнәге илһам бирә, уңышка ирешү юлында бернәрсә дә комачаулый алмаганын раслаган шәхес ул. Мин әле киләчәктә нәрсә эшләячәгемне белмим, чөнки тормышыбызны алдан фаразлап булмый. Ләкин һөнәремне электроника тармагын үстерү белән бәйләрмендер, дип уйлыйм. Миңа бу кызык, – ди **Гадел Гарипов, Биектаудагы 1 нче мәктәпнең 7 нче, инженерлык, сыйныфы укучысы.**

Биектау районы мәктәпләренә «Инженерлар республикасы» 2019 елда килеп керә. Әлеге проект эшли башлагач, белемгә омтылышның кинәт үсеп китүе шундук күзгә ташлана. Хәзер проект гамәлгә ашырылган сыйныфларда 141 укучы шөгыльләнә, бу – республикадагы барлык яшь «инженерлар»ның дүрттән бер өлешен диярлек тәшкил итә.

– Беренче елны без бишенче сыйныф укучыларына инглиз телендәге фәннәрне укытуга гаять зур игътибар бирдек. Сүз «Әйләнә-тирә дөнья» дәресләре, инглиз теле туган телләре булган педагоглар дәресләре, күпсанлы инглиз терминнары турында бара. Яныма, балага бик авыр, ул бу кадәр йөкне тарта алмый дип, әти-әниләр йөри башлар инде дип котым очып көттем, – ди **Биектау бистәсендәге 1 нче урта мәктәп директоры Елена Гыйльманова**. – Тик бервакыт ачык сыйныф ишеге яныннан үткәндә, яшь «инженер»ларның рус теленнән инглиз теленә, аннары татар теленә күчә-күчә, нәрсәдер хакында фикер алышуларын ишеттем! Проектта катнашкан башка районнардагы күп кенә педагоглар инженерлык сыйныфларында укучы балаларның үзгәрүен билгеләп үтә, һәм мин дә моның белән килешәм. Бу балаларда кызыксынучанлык, яңалыкка омтылу, кыенлыклар алдында каушап калмау кебек сыйфатлар барлыкка килә. Без, мәктәп укытучылары да, нәкъ шундый. Ә «Инженерлар республикасы» энергиябезнең иң яхшы векторына әйләнде.

– Тәнәфесләрдә балаларны сыйныф бүлмәсеннән чыгарып булмый. Алар һәрвакыт нәрсәдер программалаштыра, төзи, кора. Монда Казан инженерлык лицее педагогларының өлеше зур. Әйтик, бездә инженерлык фәннәренең бер өлешен Алексей Капитонов алып бара. Ул катлаулы нәрсәләр турында шулхәтле гади һәм кызыклы итеп сөйли ки, балалар барысын да бик тиз эләктереп ала, әле тагын да күбрәк сөйләвен сорый, – ди **Биектаудагы 1 нче мәктәпнең математика укытучысы Зөһрә Владимирова.**

3 НЧЕ КАНУН.
НӘРСӘДӘН ТҮГЕЛ, НИЧЕК БАШЛАВЫҢ МӨҺИМ

Мәктәпне уңышлы тәмамлаган укучыны ничек танырга? Бу бик җиңел: андый укучы үзе хыялланган югары уку йортына керә ала. Казан инженерлык лицее андый «сыйфат планкасы»н күптән яулады инде: анда белем алганнар үзләре теләгән уку йортына керү генә түгел, хәтта илнең абруйлы вузлары арасында сайлана да ала. Хәзер исә «Инженерлар республикасы» эшкә керешә. Проектның бер максаты – Татарстан районнарында яшәүче балалар да, университетларга һәм институтларга керер өчен, республиканың зур шәһәрләрендә яшәүче малайлар-кызлар кебек үк әзерлек шартларына ия булсын.

– Балтачта андый сыйныф ачылганын белгәч, әти-әниемнән мине Норма мәктәбеннән шунда күчерүләрен сорый башладым. Алар ризалашты, – ди **Булат Шәйхетдинов**. Хәзер ул Иннополис лицееның 8 нче сыйныфында укый, монда былтыр кергән. Булатның яраткан дәресе – робот техникасы. Булат аны инженерлык сыйныфында нульдән башлап диярлек өйрәнә. Хәзер яшүсмер егет робот техникасы олимпиадаларында даими катнаша, үз киберпроекты белән шөгыльләнә. Сәнәгать ихтыяҗлары өчен киселгән урман массивы урынында автоматлаштырылган агач утырту ысулы турындагы идеясен Булат бик өметле дип саный. Булат Иннополис университетына укырга керергә ниятли.

– Хәзер Иннополис лицеенда безнең районнан 12 бала укый. Ә икесе – Казан элемтә техникумында. Болар барысы да Венера Хәйретдинова һәм кураторыбыз, проектны башлап җибәрүнең беренче елында Казан лицееннан һәр пәнҗешәмбе килеп йөргән, уку планнарын төзергә, оештыру мәсьәләләрен хәл итәргә булышкан һәм гомумән безгә, бу эштә тәҗрибәсезләргә, бик булышлык күрсәткән Руфинә Дәүләтбаева тырышлыгы белән мөмкин булды, – дип **сөйли Балтач районының Норма мәктәбе директоры Ләйсән Гатауллина**. – Мин үзем математика укытучысы. Яшь чагымда мәктәптә шундый программа буенча укый алган булсам, минем өчен ул тормышка чын юлламага әйләнер иде.

4 НЧЕ КАНУН. ИҢ ЯХШЫЛАРДА БЕЛЕМ АЛЫГЫЗ

Тешсез бака кабырчыгы, перловица, энҗе моллюскы – **Кукмарадагы А.М.Булатов исем. Күппрофильле лицейның 3 нче сыйныф укучысы Миша Мочалов** киләчәктә үз аквафермасында үстерергә планлаштырган моллюсклар исемнәре ул.

– Моллюсклар суны яшел-зәңгәр суүсемнәрдән чистарту өчен кирәк. Ферма роботлаштырылган булачак. Бу технологиягә ихтыяҗ булыр дип уйлыйм, – ди Михаил. Үз проекты белән ул С.П. Королев исем. төбәкара конференциядә чыгыш ясаган, әлеге чараны, Симонов конференциясе кебек үк, Казан инженерлык лицее Татарстан һәм башка төбәк укучылары өчен оештыра. Мондый тәҗрибә балаларга яңа проектлар уйлап табарга гына түгел, аны зур аудиториягә җиткерергә дә булыша.

– Җан өрү һич мөмкин булмагандай тоелган механизмнарны хәрәкәткә китерү – үзенә күрә бер тылсым, могҗиза ул. Без машиналарны йөрергә, хәрәкәтләнергә мәҗбүр итәбез, файдалы гамәлләр башкарырга өйрәтәбез, элек булмаган җайланмалар ясыйбыз. Һәркемдә дә андый мөмкинлек юк, ә менә инженерларда бар. Ата-аналарның мондый үсешне хуплавы бик шәп, – ди **Кукмара лицееннан «Инженерлар республикасы» кураторы Анастасия Степанова.** – Мин бу проектка гашыйк, ул һичшиксез кирәк. Казан инженерлык лицее бүгенге трендларны күп еллар алдан күрә алган, мин аның җитәкчелегенең һәм коллективының профессиональлегенә чын-чынлап сокланам.

– Бу – Татарстанда «Инженерлар республикасы» өчен педагоглардан куратор билгеләнгән бердәнбер мәктәп. Анастасия әти-әниләр белән аралаша, аларга дәресләр, балаларның нәтиҗәләре турында тәфсилләп сөйли. Бу исә бик рухландырып җибәрә. Менә шундый уртак тырышлык белән югары сыйфатлы, күп яктан тиңе булмаган белем район мәктәпләренә тарала. Әлеге проектта катнашуым белән горурланам, – ди **Лицей – инженерлык үзәге директорының уку-укыту эшләре буенча урынбасары, «Инженерлар республикасы»ның Кукмара районындагы кураторы Лилия Хәмитова**.

5 НЧЕ КАНУН.
ҮЗ СӘЛӘТЕҢНЕ ЭЗЛӘ

Илебездә «Кировские» дип аталган беренче ир-атлар кул сәгатен 1943 елда Икенче Мәскәү сәгать заводы чыгара. Тик бу хәл Мәскәүдә түгел, ә Чистайда чынга аша, сәгать заводын, башка оборона предприятиеләре белән бергә, шунда эвакуацияләгән булалар. Хәзер монда җитештерүнең тулы циклы уникаль схемасын саклап калган Чистай сәгать заводы эшли. Чулман буенда урнашкан шәһәрдә андый югары технологияле предприятиеләр шактый. Бу – хисаплагычлар җитештерә торган «Бетар» да, «Дакар» раллиенда «КАМАЗ – Мастер» командасы өчен ясалма иярчен элемтәсен тәэмин иткән «Вектор» компаниясе дә.

– КАИның бездәге филиалында эшләп, мин алты ел кабул итү комиссиясендә утырдым. Районнарда абитуриентлар җыю кыен, ә талантлы, белемле, максатчан егет-кызларны табу тагын да катлаулырак. Мин андый абитуриентларны үзебез әзерли башлау турында хыялландым. Лицейга җитәкче булып килгәндә, инженерлык классларын ачу беренчел әһәмияттәге эшләрнең берсе булды, – ди **Чистайның 2 нче лицее директоры Руслан Зелинский**. – «Инженерлар республикасы» хыялларыма җавап булды, бик вакытында барлыкка килгән искиткеч башлангыч бу. Әлегә бездә бу программа нигезендә беренче сыйныф укучылары гына белем ала, ләкин өметләрем зурдан. Алла боерса, берничә елдан 11 сыйныфны тәмамлап чыкканнар тулысынча КАИның Чистай филиалына укырга керәчәк.

Үз белгечләрен тәрбияләп үстерү мәсьәләсе республиканың күп районнары өчен көн үзәгендә.

– Без балаларның Балтачтан Казан лицейларына укырга китүен туктатырга теләдек. Проект турында ишетүгә үк, аның белән кызыксына башладык һәм инженерлык класслары ачылган беренче район булдык. Бүген исә әлеге балаларның JuniorsSkills, WorldSkills чемпионатларында, республикакүләм мәктәп театрлары, инглиз телле театрлар конкурсларында Казан малай-кызларына лаеклы көндәшлек тудыруын күрәбез, – ди **Алия Шагаева**. – Димәк, укыту-методик әзерлек дөрес алып барылган. Венера Хәйретдинова һәм аның урынбасары Руфинә Дәүләтбаева методист булып туганнардыр. Хәзер, Яшел Үзәнның Пушкин исем. 9 нчы лицее директоры буларак, мин монда, үз сәнәгате белән дан тоткан шәһәрдә, инженерлык юнәлешен үстерәм. Без 28 укучылык сыйныф ачып җибәрдек, әмма гаризалар саны 90 иде. Алга атлыйбыз, ә яраткан инженерлык лицеебыз безгә ярдәм итә!

6 НЧЫ КАНУН. ЯҢА СЫНАУЛАРГА ӘЗЕР БУЛ

– Үз инженерларыбызны үстерү – уртак бурычыбыз, ә иртә башланган профориентация – аны хәл итү өчен ачкыч. Без 2 нче лицейны ачарга әзерләнгәндә, Чистай предприятиеләре җитәкчеләре әнә шул хакта сүз кузгатты. Без «Инженерлар республикасы» проекты, балаларга шул исәптән югары уку йортларыннан да укытучылар чакырту мөмкинлеге турында белә идек һәм, лицей әзер булгач, Венера Кәшфи кызына хезмәттәшлек тәкъдиме белән мөрәҗәгать иттек, – ди **Чистай районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары – мәгариф идарәсе җитәкчесе Ольга Купцова.**

Дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр тәүге зур адым була. Мәгариф идарәсе ярдәме белән лицей бюджет акчасына 1 миллион сумлык дәреслекләр сатып ала. Күп кенә башка мәктәпләр дә нәкъ шулай ук, проектта катнашып, үсеш өчен яңа ресурсларга ия була.

– Эшкә керешкәндә кирәкле матди базабыз юк иде. Без бу дәресләрнең нинди җиһазлар, кертемнәр таләп итүен аңлый идек. Башта үзебезнең Биектау районы ярдәм итте: ике «инженер» мәктәбенең икесенә дә акча бүлеп бирде, һәм без беренче лего җыелмаларын һәм 3D-каләмнәр сатып алдык, – ди Елена Камалова. – Аннары «Байтик» лагере белән бергә без «Яңа код» белем бирү сменасы өчен 4,5 миллион сумлык грант һәм заманча программалар урнаштырылган яңа ноутбуклар оттык. Вак-төяк кенә кебек, әмма район мәктәпләре өчен мондый нәрсәләр – чын хәзинә.

2018 елның 1 сентябрендә – «Инженерлар республикасы» проекты старт ала.

2018–2019 елларда – Балтач гимназиясе базасында ике инженер сыйныфы ачыла: 30 укучыга исәпләнгән 1 «И» һәм 5 «И».

2019 елның феврале – Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов **«Инженерлар республикасы» республика белем бирү проектына** методик ярдәм күрсәтүче Ресурс үзәге буларак эшләүче Лицей – инженер үзәге инициативасын хуплый.

2019 елдан – проектта катнашалар:

Татарстанның Балтач районы
Татарстанның Лаеш районы
Татарстанның Биектау районы
Татарстанның Балык Бистәсе районы
Татарстанның Кукмара районы
Чистай шәһәре
Яшел Үзән шәһәре
Түбән Кама шәһәре

2023 ел – 39 сыйныф ачыла. Укучылар саны 599 кешене тәшкил итә. Киләчәктә Татарстанның ерак районнарын «Инженерлар республикасы»на тоташтыру максатында дистанцион укыту форматы гамәлгә кертелә.

Проект балаларга нәрсә бирә:

- Укучыларның Н.И. Лобачевский исемендәге Бөтенроссия (халыкара катнашу да бар) фәнни конференциясендә катнашу һәм призлы урыннар яулау (Казан).
- «М.П.Симонов исемендәге Кышкы укулар» Халыкара фәнни-гамәли конференциясендә катнашу һәм призлы урыннар алу (Казан).
- С.П. Королёв исемендәге Төбәкара проект конференциясендә катнашу һәм призлы урыннар яулау (Казан).
- «Минем кече Ватаным» яшь уйлап табучыларның Республика олимпиадасында катнашу һәм призлы урыннар алу (Казан).
- SCHOOL PERFORMANCES чит телләрдә мәктәп театр коллективларының Республика фестиваль-конкурсында катнашу һәм җиңүгә ирешү.

7 НЧЕ КАНУН.
ДУСТАНӘ БУЛ!

Яшь «инженерлар» белән бергә яңа нәрсәләргә педагоглар да өйрәнә. Проект Балтач, Кукмара, Биектау районнарында уңышлы эшләп киткәч, Казан лицее компетенцияләрнең бер өлешен урыннардагы мәктәпләргә тапшырырга карар кыла. Әйтик, Кукмара мәктәбе кураторы Анастасия Степанова 1–4 сыйныф укучыларында робот техникасын укыта башлый, ә Биектауның 1 нче мәктәбе педагоглары үз белемнәрен арттырырга керешә. Хәзер биредә эшләүче 54 укытучыдан 17 се югары категориягә ия.

– Педагогларның кызыксынуы, мавыгып китүе бик мөһим. Балтачта беренче инженерлык сыйныфы 2018 елда ачылды. Яшь укытучылар – Александр Кузин һәм Марсель Шәйхетдинов килде. Алар биредә берничә көн торып китәләр иде, ул арада балалар белән чаңгыда йөрделәр, укучылар һәм аларның әти-әниләре белән походлар оештырдылар, – дип сөйли **Балтач районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе җитәкчесе Ренат Мөхәрләмов**. – Алар биредә чын «инженерлар» командасын булдырды. Мин егетләргә һәм бу эшне профессиональ рәвештә күтәреп алып киткән, үстергән укытучыларыбызга бик рәхмәтле. Алар тырышлыгы белән балаларыбыз профильле ярышларда һәм конкурсларда төбәк дәрәҗәсендә катнашырлык югарылыкка күтәрелде.

– Гадәттә, зур мәктәпләргә эләккән яшь педагогларның хезмәтләренең нәтиҗәсен күрмәгәнгә, үз һөнәрләреннән күңеле кайта һәм алар укытучылыкны ташлый. Миңа бәхет елмайды. Лицейга килгәндә, аспирантурада укый идем әле. Венера Кәшфи кызы шунда ук миңа Балтачтагы сыйныфларны ышанып тапшырды. Өлкән хезмәттәшләрем миңа бик ярдәм итте. Мин күп укыта башладым, эшем үземә бик ошады. Райондагы сыйныфлар зур түгел, балалар – кызыксынучан, энергияле, Казаннан килгән укытучылар алар өчен абруйлы, – дип сөйли **лицейның өстәмә белем бирү педагогы һәм КМТТУ-КАИның машина белеме һәм инженерлык графикасы кафедрасы хезмәткәре Александр Кузин**. – Мин беренче сыйныф укучылары белән шөгыльләнә башладым, аларны дүртенче сыйныфка кадәр укыттым. Аннары бер еллык тәнәфес булды. Хәзер кабат аларны укытам. Хәзер бу беренче сыйныф – республикадагы иң яхшы инженер сыйныфларының берсе. Үз хезмәтеңнең нәтиҗәләрен күрү шундый рәхәт! Процесс барышында син үзеңне балалар белән ашыкмыйча гына елга буйлап йөзеп баргандай итеп тоясың. Ә инде бу балалар белән беraз вакыттан соң очрашкач, аларның белемнәре үзе бер кораб икәнен күрәсең. Һәм бу кораб кай арада шулкадәр еракка йөзеп киткән!

ГӨЛНАРА ГАЛИЕВА, Казан шәһәре Совет районының 187 нче күппрофильле лицее директоры:

– «Инженерлар республикасы» стартында мин Лицей – инженерлык үзәге командасында эшләдем һәм миңе Балык Бистәсе районына куратор итеп билгеләделәр. Инженер сыйныфларының анда да ачылуы бик шәп булды: балалар проектларын теләсә кайсы өлкәдә – балыкчылыкта, авыл хуҗалыгында гамәлгә ашыра ала. 2020 елда «Ритм» 187 нче күппрофильле лицее җитәкчесе булып эшли башлагач, мин бу тәҗрибәне үз эшемдә кулландым. 2021 елда без биредә беренче инженер сыйныфлары ачтык. Хәзер аларның саны алтау булды, әмма укырга теләүчеләр саны арта бара, шуңа күрә бу юнәлеш киңәячәк. Без инженерлык лицее салган сукмактан атлыйбыз һәм юлда яңа нәрсәләр дә ача барабыз. Бу уку елыннан без Алексей Лопатин җитәкләгән «Яңа инженерлык белеме» компаниясе белән хезмәттәшлек итәбез. Вуз материалы мәктәп белән туры килми кебек, әмма безнең программалар теләсә кайсы яшьтәге белем һәм сәләтләрне исәпкә алып эшләнгән. Алар балаларга аңлаешлы. Инженерлык инициативасының ничек көчәя баруын күрү күңелле күренеш. «Инженерлар республикасы»н оештыручыларны, анда катнашучыларны биш еллыклары белән котлыйм! Балалар һәм аларның ата-аналары өчен кирәкле идеяне хуплаганнары өчен шәһәребез һәм республикабызга рәхмәт!

РУФИНӘ ДӘҮЛӘТБАЕВА, Казан шәһәре Совет районының «Лицей – инженерлык үзәге» МАББУ директоры урынбасары:

– Без «Инженерлар республикасы»ның бишьеллыгын – беренче юбилеебызны билгеләп үтәбез. Зур проектлар масштабында биш ел әллә ни түгел кебек. Әмма бергәләп күпме эш башкарганбыз! Минем өчен иң дулкынландыргыч мизгелләр шул: райондагы коллегаларыбыз һәм ата-аналарның киләчәк турында сорау һәм тәкъдимнәр тулы уңай фикерләренең күплеге. Бүген алар «Инженерлар республикасы» белән балалардан да ким мавыкмый. Әлбәттә, укучыларның казанышлары! Кайдадыр программа иртәрәк, кайдадыр соңрак башланды, әмма һәркайда «Инженерлар республикасы»нда белем алучыларның уңышларын күрәбез. Бу – Королев һәм Симонов исемендәге фәнни конференцияләрдә проектларны уңышлы яклау, бу – мәктәп театр коллективларының инглиз телендә SCHOOL PERFOMANCES фестивале кебек иҗади конкурсларда җиңүләре, бу – узган уку елы азагында Балтачта башлангыч мәктәпнең беренче белем бирү циклын тәмамлаган инженер сыйныфлары укучыларының инглиз теленнән халыкара имтиханны искиткеч нәтиҗәләргә тапшыруы. Хәзер бары тик алга һәм югарыга гына!

ВЕНЕРА ХӘЙРЕТДИНОВА, Казан шәһәре Совет районы «Лицей – инженерлык үзәге» МАББУ директоры:

– Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ул вакытта ТР мәгариф министры Энгель Фәттахов, республиканың хәзерге мәгариф министры Илсур Һадиуллин ярдәменнән башка проектыбыз бүгенге куәтенә ирешә алмас иде. «Инженерлар республикасы»н төзүдә һәм үстерүдә теге яки бу дәрәҗәдәге катнашучыларның инициативасы һәм энергиясе ярдәмендә биш ел эчендә укучылар саны 30дан 600 гә кадәр артты. Мин педагог һәм тел өйрәтүче кураторларга, КМТТУ-КАИ укытучыларына, җил-яңгыр, буран булуга карамастан, атна саен районга дәрес үткәрергә баручы район кураторларына рәхмәтлемен. Район, мәгариф идарәләре җитәкчеләренә, безне хуплаган мәктәп директорларына рәхмәт. «Инженерлар республикасы» балаларга кирәк. Әйдәгез, бу проектны алга таба да үстерик!

АЛЕКСЕЙ ЛОПАТИН, КМТТУ-КАИның реактив двигательләр һәм энергетика җайланмалары кафедрасы мөдире, «Инженерлар республикасы» проектының идеологы һәм аңа нигез салучыларның берсе:

– Профильләшү – заманабызга хас күренеш. Интернет ярдәмендә технологияләр күз ачып йомганчы үсә һәм балаларга киләчәккә тиз җайлашу өчен тиешле старт бирергә кирәк. «Инженерлар республикасы»ның кыйммәте андый белем бирүдә генә дә түгел. Биредә укытучылар – балаларның проект эшчәнлеге җитәкчеләре, балалар исә үз чиратында мөстәкыйль эш белән шөгыльләнә, фән нигезләрен үзләштерә, презентацияләрне һәм үзен күрсәтергә өйрәнә. Бу проект уңышының 50%ы бит. Инженерлык лицееның зур казанышы шунда: ул профильле белем бирү өлкәсендә берничә инициативаның методик һәм методологик башлангычы булып тора. «Яңа инженерлык белеме» ҖЧҖ бу тәҗрибәне исәпкә ала: без Казанның дүрт лицеенда сыйныфлар ачтык. Балалар мастер-программалаштыру, инженерлык эше һәм пилотсыз очу аппаратлары өйрәнәләр. Инженерлык нигезләрен үзләштерү әзлекле, өзеклекләрсез булсын өчен, без беренче сыйныфта «Майнкрафт», «Роблокс» кулланабыз. Ә бит болар бүген иң популяр уеннар.

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

shop.tatmedia.ru

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Балага **нинди** исем кушарга

Хөсәен Фәезханов **нинди** мирас калдырган

Китап киштәсендә **нинди** китаплар бар

Кече Кайбыч **ничек** яши

«ИСЕМ УЛ – ХАЛЫК ХӘТЕРЕ»

«Татарстан» журналы быел – Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында традицияләребез, йолаларыбыз турында язуын дәвам итә. Басмабызның бу санында исем кушу йоласы, татар исемнәренең килеп чыгышы, аларның әһәмияте турында сөйләргә абруйлы белгечләребез булышты.

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

Гүзәлия Хаҗиева,
филология фәннәре докторы

ЫШАНУЛАР

– Татар халкы гомер-гомергә балага исем бирүгә җитди караган, аның мәгънәсенә, исем кушканда төрле йола-гадәтләргә аеруча зур игътибар биргән. Хәзерге көндә дә бу мәсьәлә үзенең әһәмиятен югалтмаган.

Исем кушу йоласына аеруча игътибар бирүнең үз сере бар. Исемнәр төрле бәла-казалардан, авыру-сырхаулардан котылырга ярдәм итә, дип саналган. Шулай ук куркыту һәм культ мәгънәсен белдергән исемнәр ата-ананың, өлкән буынның теләкләрен чагылдырган. Исем – җанның бер өлеше, дигән фикер яшәгән. Шуңа бәйле рәвештә, татар халкында исем кушуның төрледән-төрле ырымнары яшәп килә. Татар телендә әлеге ырымнарны исем алыштыру, исем авыштыру, исем бозу дип атыйлар. Баланың кинәт кенә авыруы дөрес сайланмаган яисә «бозылган» исем белән аңлатыла.

Исем алыштыру халык медицинасында да киң кулланылган. Әгәр бала бик нык авырса яисә балага миң чыкса, исемен алыштырганнар. Мәсәлән, Казан арты төбәгендә, әгәр бала авырып китсә, тары боткасы пешергәннәр һәм аны мичкә куйганнар. Морҗадан кашык төшереп: «Исемен алыштырам, Миңлегөл булсын. Кашык төшер-

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

дем, саулыгын бирсен», – дип әфсен укыганнар. Соңыннан тары боткасын кошларга биргәннәр. Билгеле булганча, морҗа начар рухларның өйгә керү юлы булып саналган. Шуңа күрә кешенең морҗага эндәшүе начар көчләргә мөрәҗәгать итү булып аңлатылган.

Исемгә «миң» сүзен кушуда аерым йола яшәгән. Бу йоланы халык арасында «миң боздыру» дип атыйлар. Билгеле булганча, миң төрки халыкларда бәхет символын, бәхетле язмышны белдерә. Миң боздыру йоласын үткәргәндә, Казан арты татарларында морҗадан тары боткасына кашык төшергәннәр. Нократ татарларында баланың яңа исемен морҗадан кычкырганнар. Кендек әбисенә яңа кашык бүләк иткәннәр. Бу йоланы кар эреп беткәнче яисә җәй җиткәнче үткәргәннәр. Миң сүзе кергән исемнәр биргәннәр: Миңсылу, Миңлебай һәм башкалар.

ЗАМАНГА ИЯРҮ

1788 елда Екатерина патшабикә Указы нигезендә Оренбург Диния нәзарәте ачыла. Әлеге оешма ачылуга, исем кушу эше муллаларга тапшырыла, чөнки яңа туган баланы рәсми теркәү аларга йөкләнә. Шул вакыттан алып татар, башкорт, казах, кыргыз милләтләрендә максатчан рәвештә гарәп-фарсыдан кергән исемнәрне куштыру башлана. Аннары әлеге халыкларда гарәп исемнәрен кушу гадәте барлыкка килә. Бу хәл XIX гасыр азагы – XX гасыр башына кадәр дәвам итә. Муллалар балаларга гарәп, фарсы исемнәрен куша, ә ата-ана, аларның мәгънәсен бөтенләй аңламаса да, каршы килми. Кайвакыт муллага нинди дә булса исем ошый икән, ул аны бик күп балага куша.

1917 елгы революциядән соң кыскартылма, билгеле бер шәхескә бәйле исемнәр үтеп керә башлый. «Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 22 июнь санында эшче татар гаиләсендә туган бер кызга, иптәш Троцкийга багышлап, Троцкино дип исем кушу бәйрәме үткәрелү турында хәбәр ителә.

XX гасырның 30 нчы елларыннан балага исем кушу яңача башкарыла башлый. Әлеге йоланы «Октябриналар» дип атыйлар, һәм алар митинг, җыелыш, котлау формасында үткәрелә. 1930 елда «Азат хатын» журналында ата-аналарга киңәш рубрикасында түбәндәге исемнәр тәкъдим ителә: Рафил, Марат, Фред, Ирек, Азат, Ренад, Корыч, Эдвард, Альфред, Алмас, Илдус, Арслан, Марс, Баян, Карл, Марсель, Тимер, Радик, Батыр, Ук, Лерон, Ильгиз, Роберт, Сталь, Денам, Ялкын, Зирәк; Роза, Клара, Флера, Гүзәл, Йолдыз, Рева, Рема, Гөлкәй, Кояш, Алсу, Ләлә, Ландыш, Марта, Бүләк, Луиза, Аида, Лера, Ариа, Иркә. Киңәш ителгән исемнәр арасында кыскартылма исемнәр дә бар: Дамир – «Да здравствует мир», Вил – «Владимир Ильич Ленин», Рев – «Революция», Ренат – «Революция, наука и труд», Ким – «Коммунистический интернационал молодежи», Марлен – «Маркс-Ленин» һәм башкалар.

Яңа исемнәрне үз балаларына күбрәк татар интеллигенциясе куша.

МИЛЛИЛЕККӘ ТАБА

XX гасырның 90 нчы елларында, милли күтәрелеш чорында, ата-аналар исемне кемгә дә булса багышлап куша башлый. Мәсәлән, татар исемнәре арасында ата-аналар Минтимер исемен беренче президентыбыз Минтимер Шәймиев исеме хөрмәтенә бирә. Әлеге шаукым 90 нчы елларда активлашып киткән иде. Татарлар арасында Илһам, Хәйдәр, Разил, хәтта татарга күпмедер дәрәҗәдә ят булган Роберт исемнәре татар халкының күренекле җырчылары Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичевка, шагыйрьләр Разил Вәлиев белән Роберт Миңнуллинга һәм башкаларга багышлап кушыла. Әлеге исемнәр балага милли замандашларыбызга – халкыбызның күренекле затларына хөрмәт йөзеннән бирелә, аларның популярлыгы шуның белән бәйле.

Татар антропонимика системасында Әмир, Әмирхан, Сәет, Солтан, Рәис, Мөдәррис кебек исемнәр дә популяр. Мондый исемнәр татар антропонимика системасы үсешенең бөтен чорларында да кулланыла. Һәм бүген дә актуальлеген югалтмый.

БОРЫНГЫДАН КИЛӘ

Төрле титуллардан ясалган исемнәр иң борынгы катламга карый. Борынгы Орхон-Енисей язмаларында ук инде әлеге исемнәр теркәлгән. Борынгы төркиләрдә бала тугач та аңа кендек исеме бирелсә, батырлыклар эшләгәч, иҗтимагый тормышта төрле титуллар казангач, эр яки ир исеме бирелгән. Шуңа күрә ташъязмалардан борынгы төркиләрнең берничә исеме булганлыгы һәм исем йөртүченең язмышы, шәхес буларак формалашуы турында бик күп мәгълүматны ачыкларга мөмкин.

Ир-егетләргә титул, чин сүзе кергән исем бирү – ата-ананың бала тормышта үз урынын тапсын, иҗтимагый үрләр яуласын, матди ирек казансын дигән теләкләренә нигезләнә. Шулай итеп, татар исем системасында титулга бәйләнешсез теләк исемнәр дә күп: Солтанбай, Солтангали, Солтангази, Ханзафар, Ханморат, Ханзаман, Мирзагали, Мирзавәли, Мирзанур, Морзабәк, Морзабулат, Морзагаян, Шәехбулат, Шәехтимер, Шәехгали, Әмирхан, Әмирҗан, Әмиргали, Мирсафа, Мирвәли, Мирхатип, Сәетхан, Сәетгали, Сәетрәхим, Шаһбаз, Шаһгәрәй, Шаһнур, Тархан, Тарханбәк, Тархангол һәм башкалар.

Кеше исемнәре, аларның мәгънәләре һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Ни өчен андый исем кушканнар, ул исемнең мәгънәсе нидән гыйбарәт, аның язмышка тәэсире нинди – бу һәм башка шундыйрак сораулар, уйланулар кешелекне инде борынгы чорлардан ук кызыксындырган, борчыган. Исем – халык хәтере, халык мирасы, халык тамгасы ул. Нәсел җепләрен бәйли торган тирән мәгънәгә ия сүз дә ул.

ИСЕМ КУШУ – гаиләдәге зур вакыйга. Бу йола, сабый тугач та, атна-ун көн эчендә башкарылырга тиеш. Әлеге күренеш «бәби туе» белән ныгытыла.
Балага исем гаилә тәкъдиме белән мәхәллә имамы тарафыннан кушыла. Исем кушу мәҗлесендә ата-ана, әби-бабай, гаилә әгъзалары катнашу зарур. Бу изге гамәл Аллаһ Тәгалә, милләт, баланың үзе каршында зур җаваплылык дигәнне аңлата. Шуңа күрә дә исем илаһи, милли һәм аһәңле булырга тиеш. Исемнең күп вакытта җисеменә туры килүен истә тотарга кирәк. Чөнки исем ул яшәү туграсы, гомер тамгасы.
Балага исем кушу йоласы мәхәллә имамы таныклык тапшыру белән тәмамлана. Исламда имам кушкан исем генә кануни санала.

Илдус Әмирхан. «Татар фәлсәфәсе һәм милли мәгариф»
(Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2003 ел.)

Җәлил хәзрәт Фазлыев,
ТРның Баш казые

«ИСЕМ – ТУГАН ТЕЛНЕҢ ИҢ ЯКЫН, ИҢ ГАЗИЗ, ИҢ КАДЕРЛЕ СҮЗЕ!»

– Балага исем кушуга бик җитди килергә кирәк, чөнки исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә һәм ул аның гомерлек юлдашына әверелә. Кеше үз исеменә шулкадәр күнегә ки, ул аңа туган теленең иң якын, иң газиз, иң кадерле сүзе булып тоела. Әби-бабаларыбыз элек-электән исем кушуга бик җитди караган, исемнең җисеменә туры килүенә ышанган.

Кызганычка, бүген электән килгән бик күп матур гадәт югалып бара кебек, күп гаилә исем кушуга җитди карамый. Күбебез кечкенә баланы теләсә кем уйнап карый ала торган курчак дип кабул итәбез. Әти-әниләр генә түгел, әби-бабайлар да бәби алып кайтуны кибеттән «кукла Барби» сатып алу дип күрә. Аннан менә шул «Барби» курчагына исем сайлау башлана: Эльвина, Мальвина, Дюймовочка… Әйтерсең, ул баланы уйнап туйгач ташлыйсы. Әйтерсең, ул баланың шул исем белән картаясы, әби, бабай буласы юк.

Гөлнара Фәләхова махсус «Сөембикә» журналы өчен ясаган рәсем.

Күркәм исем белән эндәшү балага дога кебек үк уңай тәэсир итә. Ә начар мәгънәле һәм ярамаган исем балага начар йогынты ясый, аның психикасы бозылуга, ямьсез холыклы булуына, авыруларга ансат бирешүенә сәбәп була. Моның шулай икәнлеген бүген фән дә раслады. Галимнәр су кристалларын рәсемгә төшергән. Яхшы сүз әйткәч, дога укыгач, су кристаллары бик матур чәчәк рәвешенә керә һәм ул су кешеләрне дәвалау, тынычландыру үзлегенә ия була.

Исем кушуның төп йоласы – ата-ана мәхәллә имамын чакыра. Хәзрәт исә баланың уң ягына азан әйтеп, уң колагына, сул ягында камәт әйтеп, сул колагына «Исемең фәлән булсын» дип, өч мәртәбә әйтә, балага тәүфыйк-һидаят теләп дога кыла. Бу сөннәт гамәл санала.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Яшәү – азан белән намаз арасы», – дигән. Азан әйтү – ата-анага гомернең кыска булуын искәртү дә. Гомеребезнең бер минуты да заяга үтмәсен, бигрәк тә бала тәрбияләр өчен бирелгән вакыт кадерле.

Кайбер гаиләләрдә исемне әти яки дәү әти дә куша. Әгәр ир-ат азан әйтә белә, иманлы икән, әлбәттә, монда зыян юк. Тик мин бу эшне имамнар эшләсен дигән фикердә торам: аларның бу эштә тәҗрибәсе бар, бөтен шартын беләләр. Имам үзе белән исем кушу турындагы таныклык алып килә. Шуның белән бергә баланың әти-әнисенә мәчетнең бүләген дә тапшыра. Кайткач исә, имам мәхәллә китабына яңа исемне теркәп куя.

Никахны өйдә укырга киңәш итәм. Гомумән, мәчеттә исем куштыру, никах укытуны өнәп бетермим. Әбибабаларыбыз балага исем кушу, никах укытуны гомергә өйдә үткәргән. Әле никах укыганда аңлашыла: кәләш яшәгән йорт зур булмаска мөмкин, шуның өчен дә бөтен туганнарны сыйдырырга җай юк, ди. Ә бит балага исем кушканда кеше күп җыелмый һәм ул кирәкми дә. Иң якыннары булса, шул җитә.

Габдерәхим Утыз Имәни: «Кыяматтә искә алырлар, исемеңне уртага салып», – дип язган. Чынлап та, Коръәндә әйтелә – кабат кубарылган мәхшәр мәйданында да исемебез белән чакырылачакбыз. Димәк, исем мәңгегә бирелә. Шуның өчен дә балага матур исем сайлау фарыз, бу – әти-әнинең бурычы.



Рабит Батулла,
ТРның халык язучысы

ОЯЛУ...

– Татар зыялыларының 30 нчы еллардан алып бүгенгә чаклы балаларына кушкан исемнәре татарның таркалуы, ягъни деградациясе турында сөйли. Бигрәк тә укытучылар, замана шаукымына ияреп, балаларына чит-ят, мәгънәсез исемнәр кушкан. 1917 елгы түнтәрелештән соң совет мәктәбендә алты айлык курслар укып чыккан укытучылар булган алар. Укытучыны хәреф танырга, укырга-язарга өйрәткәннәр, тик тирән белем бирә алмаганнар. Димәк, ул укытучылар (бөтенесе дә түгел, әлбәттә) балаларга зыялы тәрбия бирергә әзерлекле булмаган, чөнки үзләре дә төпле белем алмаган. (Дөрес, минем укытучыларым бик белемле булды. Бу фикерне еш әйтәм: мәктәптә университет белеме алдык, дим.)

Надан укытучылар гына балаларына шундый ахмак исем кушкан дигәч, кайбер мөгаллимнәр миңа үпкәли. Ләкин акыллы укытучы үпкәләмәс, чөнки асылда ул шулай.

Гомерем буе үз исемемнән оялдым. Бу хакта хәтта эти белән сүзгә дә килгәнем булды. Рус исеме дә кушмаганнар, Европа исеме бит, Роберт! Эти белән әни икесе дә укытучы иде. Әлеге дә баягы алты айлык курсларда танышкан алар. Шуның өчен мин аларны гаепләмим.

Мин Актанышта мәктәптә эшләгән кеше. Ул якта Европа исемнәрен саный китсәң... Мисал өчен, миндә Марсельеза, Робсон исемле малай-кызлар укып чыкты. Трактор, Карбюратор, әллә нинди исемнәр бар иде.

Балаңа чит исемнәр куштыру ул – үз милләтеңнән оялу, үз исемеңнән оялу, кимсенү билгесе. Ә безнең исемнәр оялырлык түгел, әйтик: Алпар, Арыслан, Байхан, Барлас, Булат, Гәүһәр, Гөлйөзем, Гөлчирә, Гөлчәһрә, Җангир, Җәүһәрия, Җанбикә, Йөзлебикә, Кубрат, Мансур, Мират, Мирас, Нурлан, Саттар, Таймас, Таштимер, Ташсуар, Котлыбай, Тәбриз, Туктар, Туран, Тургай, Туфан һәм башкалар. Чит ил исемнәрен кушуга иң беренче каршы чыккан кеше Мирсәй Әмир булган. 1930 нчы елда ул шул турыда хикәя яза: комсомол егет белән комсомолка өйләнешә дә, аларның игезәк балалары туа. Сабыйларга исем эзли торгач, бик заманчаны уйлап табалар. Игезәк сыңары оланга – Геморрой, кызга Гонорея исеме куштырып кайталар. Бу – ачы сатира. Тәнкыйтьче Фатих Мөсәгыйть бу хикәяне эт итеп сүгә. Шуннан Мирсәй Әмир геройларны Фәрит белән Фәридәгә алмаштыра. Шуның белән әсәрнең көче бетә, сатира ишелә дә төшә! Мирсәй Әмир бит юкка гына геройларына шундый исем бирмәгән – аның нияте җүнсез исемнәрдән халыкны кисәтү булган.

Әйе, адәм ышанмаслык исемнәр кушу татарларда егерме бишенче елларда ук башланган һәм бүген дә дәвам итә. Димәк, татарларның ата-баба исемнәреннән ваз кичә башлауларына йөз ел. Иң кызганычы, ул алга таба да дәвам итәчәк. Чөнки тарихыбызны, мәдәниятебезне начар беләбез.

ТӘКЪВА ГАЛИМ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТЧЕ ХӨСӘЕН ФӘЕЗХАНОВ

Илдус Заһидуллин

Сүз кадерен белеп, мактауны үлчәп генә кулланган Шиһабетдин Мәрҗани үзенең шәкерте – Санкт-Петербург университетының Көнчыгыш факультеты лекторы, галим һәм мәгърифәтче Хөсәен Фәезханов турында: «Саф күңелле, күркәм холыклы, тоткан юлына тугры фикерле, бик акылы камил, мәртәбәле, киң мәгълүматлы, дөрес карашлы, илтифатлы, ачык әңгәмәдәш, язуы бик нәфис, оста оратор иде», – дип язган. Хөсәен Фәезханов Мәрҗанинең күңелен ничек яулый алган соң?

Булачак галим Сембер губернасы Кормыш өязенең Сабаҗай авылында 1823 елда (кайбер мәгълүматлар буенча 1828 елда) крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Туган авылы мәктәбеннән соң – Казан өязе Бәрәскә авылы мәдрәсәсендә, аннары Казанда мулла Байморад бине әл-Мөхәррәмдә, мөдәррис Габделкәрим бине Габдерәхимдә һәм 1850 елдан Шиһабетдин Мәрҗанидә белем ала. Мәрҗани мәдрәсәсендә укыганда шәкертләр арасында «Зәки» (гадел, тәкъва) кушаматы белән танылa.

Хөсәен ислам дине гыйлемнәрен, гарәп, фарсы телләрен тирәнтен үзләштерүдән тыш, Казанда үзлегеннән рус телен өйрәнә. 1848 елда университет галимнәре Александр Казыймбәк һәм Илья Березин белән таныша, алар белән хезмәттәшлек итә башлый. Мәрҗани мәгълүматлары буенча, мәдрәсә шәкерте Казыймбәккә Коръәнгә махсус күрсәткеч төзүдә ярдәм итә. Иң мөһиме – университет галимнәре белән аралашу яшь кешегә алдагы тормыш юлын анык билгеләргә ярдәм итә. Мәрҗани шәкертенә киләчәген яхшырак көйләрлек эшләр (бай мәхәллә мулласы урынын күздә тота) булуы турында әйтә. Хөсәен Фәезхановның Санкт-Петербургка китүенә каршы була. Егет исә, сүзен сүз итеп, башкалага китә һәм, остазы язганча, «мәшһүр була».

БАШКАЛА УНИВЕРСИТЕТЫ УКЫТУЧЫСЫ

1849 елда профессор Александр Казыймбәк Санкт-Петербургка китә, соңрак, 1855 елда, Көнчыгышны өйрәнү кафедралары барысы да Казаннан башкала университетына күченеп бетә. Шул рәвешле Фәезханов Казанда аралашкан галимнәр башкалада эшли башлый. Шуңа күрә Хөсәеннең соңгы акчасына якынча 1854 елның башында Санкт-Петербургка күченүенә килгәндә, аның үзен белгән һәм алдагы тормыш юлында ярдәм кулы сузачак галимнәр янына китүен әйтергә кирәк. Крестьян гаиләсендә туган, Россиядә мөселман динен тотучы «инородец» саналган татар кешесенә университетта эшкә урнашырга, аның гыйлемле булуын таныган әлеге галимнәр булыша.

Бу елларда Санкт-Петербургта Түбән Новгород һәм Сембердән килгән, шулай ук Рязань губернасының Касыйм өязеннән күченеп урнашкан татарлар төркеменең бердәм булып яшәгәнен дә искәртү урынлы булыр.

Шәһәргә күченгән елны Фәезханов шәхси коллекциясендәге 26 кульъязмасын сата, ел саен диярлек Азия музее директоры академик Борис Дорн кушуы буенча ялланып кульъязмалар күчереп яза, 1865 елны академиядәге «мөселман китапларының» гыйльми каталогын төзергә җәлеп ителә, шул рәвешле тормышын көйләп җибәрергә тырыша.

1855–1856 уку елында башкалада, Казаннан күчерелгән студентлар белән бергә, Көнчыгыш

Фотолар автордан алынды

факультеты эшли башлый. Әмма факультет деканы Александр Казыймбәкнең Хөсәенне мөселман язуы (каллиграфия) мөгаллиме итеп штатка алу планы барып чыкмый. 1856 елның мартында язган яңа гаризасына да халык мәгарифе министры тискәре җавап бирә. Көнчыгыш факультеты студентлары 1857 елның сентябрендә ректорга Фәезхановка татар һәм төрек телләре өйрәнү буенча практик дәресләр алып барырга рөхсәт бирүне сорап күмәк гариза биргәч кенә, мәсьәлә өлешчә хәл ителә. Ректор дәресләрне бушка алып бару шарты белән рөхсәт бирә: 1858 елның февраленнән Фәезханов атнага 4 тапкыр 1, 2 һәм 4 курсларда русчадан татарчага тәрҗемә итү һәм сөйләм телен камилләштерү буенча практик дәресләр бирә. Хезмәттәшләре Фәезхановның мөгаллимлек эшенә бик җаваплы каравы һәм студентларны үз фәне белән шөгыльләнергә мәҗбүр итүен искә ала. Шулай бушка ел ярым эшләгәч, факультет җитәкчелеге Фәезхановка 1860 елның мартында укытканы өчен 300 сум түләттерүгә ирешә.

Укыту барышына бәйле рәвештә ул 1862 елда «Краткая учебная грамматика татарского языка» уку әсбабын нәшер итә. 1864 елда аның камилләштерелгән вариантын әзерли.

1861 елның гыйнварында каллиграфия фәнен укыткан Ибниямин Әминов вафатыннан соң вакантлыга әйләнгән урынга Фәезханов билгеләнә. Шул ук елны университет тәкъдиме белән Фәезхановка гомерлек шәрәфле гражданин дәрәҗәсе бирелә – ул крестьян сословиесеннән чыгарыла һәм җан башыннан түләнә торган салымнан азат ителә.

1863 елның көзеннән, ниһаять, Фәезхановны университетның татар теле лекторы итеп эшкә алалар. Исеме факультет тормышында ачык күренә: ул диссертация яклауда катнаша, Госманлы дәүләтендә фәнни командировкада була һ.б.

МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ПРОЕКТЛАРЫ

Хөсәен Фәезхановның Санкт-Петербургта мәгърифәтчелек юнәлешендә берничә проект эшләве мәгълүм. Шуларны берсе – 1857-1859 елларда башлап та ахырына җиткерелми калган «Чулпан» исемле газета чыгару проекты. Бу хакта дәлил - халык мәгарифе министрына атап язылган гариза - архивта саклана. Гариза тәрҗемәче П.А. Пашино һәм Фәезханов исеменнән язылган, әмма беренчесенең генә имзасы куелган. Газета программасыннан күренгәнчә, анда дүрт бүлек булачак дип планлаштырылган: 1) хөкүмәт карарлары, 2) чит ил хәбәрләре, 3) фән яңалыклары 4) әдәбият. Югарыда әйтелгәнчә, проект тормышка ашмый кала.

Фәезхановның 1860 нчы еллар башында мәктәп реформасына багышланган проекты кульъязмасында шундый юллар бар: «Безнең халкыбызның киләчәге һәм ныклыгы берничә шартка нигезләнгән. Берсе – мал, берсе – дин һәм берсе – гыйлем. Әгәр бик фәкыйрь булсак, башка дин халкына хезмәттә торып, алар астында калачакбыз. [...] Динебез камил сафлык белән таралмаган булса, без руслар, чуашлар һәм мукшылар кебек үк, руслар белән катнашып калган булыр идек. [...] Надан булсак, тагын укымышлы халыклар тәэсире астында калачакбыз. Тел дә – мөстәкыйльлегебезгә бер сәбәп».

Бу проектта сүз яңа татар интеллектуаль элитасын әзерләүне максат итеп куйган уку йорты ачу турында бара. Автор фикеренчә, әлеге югары мәдрәсәдә гимназиядә укытыла торган фәннәрнең күпчелеге укытылырга тиеш. Шулай ук гарәп, фарсы һәм төрки телләр һәм ислам дине гыйлемнәре камил рәвештә өйрәтелсен. Тыйб (медицина) фәненнән алган белемнәр фельдшер хәзерләүнекенә тәңгәл булсын.

Мәдрәсәдә ике бүлек – шәригать гыйлеме һәм дөньяви белемнәр бүлеге эшләргә тиеш. Шәригать гыйлеме бүлегенең укыту программасы Европа телләреннән, артык зарурияте булмаган гимназия, ә рус теленнән гимназиянең югары сыйныфлары программасыннан азат булсын. Дөньяви белемнәр бүлегендә гарәп һәм фарсы телләре, тыйб, дини гыйлемнәрнең махсус фәннәре бирелмәсен.

Мәдрәсә биш сыйныфлы итеп күзаллана. Һәрберсендә икешәр еллык программа белән укытылып, соңгы ике сыйныфы шәригать белемнәре һәм тыйб буенча махсус сыйныфларга аерыла.

Дөньяви белемнәр бүлегенең өченче сыйныфын тәмамлаучылар – урта уку йортларының югары сыйныфларына, ә дүртенчесеннән университет һәм башка югары уку йортларының махсус (хәзерлек) классларына керә алыр, дип фаразлана.

Фәезханов мәдрәсәдә шәригать гыйлемнәрен, шәрык телләрен һәм кайбер гимназия фәннәрен (хисап һәм геометриянең аерым тармаклары), ислам тарихы һәм мантыйкны (логика) – татар телендә, башка фәннәрне рус телендә укытырга тәкъдим итә.

Уку йорты ачылган вакытта һәр бүлегенә алтмышар шәкерт җыю планлаштырыла.

Автор соңрак, төрле сәбәпләр белән, проектка берникадәр үзгәрешләр кертә, ахыр чиктә ул тормышка ашмый кала. Безнең өчен Фәезхановның бу кульъязмасы татар иҗтимагый фикеренең яңа баскычы буларак кадерле.

ОСТАЗ БЕЛӘН БЕЛӘН ШӘКЕРТ ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

Хөсәен Фәезханов Александр Казыймбәк, академиклар Борис Дорн һәм Владимир Вельяминов-Зернов йогынтысында европача гыйльми эзләнү методикасын уңышлы үзләштерә. Шушы шартларда шәкерт белән аның остазы Мәрҗани мөнәсәбәтләре яңа яссылыкка күчә. Алар даими рәвештә хатлар аша хәл-әхвәл белешеп, бер-берсенең фәнни эшчәнлекләре белән кызыксынып, үзара фикерләшеп яши. Фәезхановның чыганаклар табу буенча башкала китапханәләрендә, Азия музеенда мөмкин-

Шиһабетдин Мәрҗани. 1860–1870 нче еллар.

Александр Казыймбәк.

Владимир Вельяминов-Зернов.

Хөсәен Фәезханов. 1860 нчы елларның беренче яртысы.

лекләре, һичшиксез, зур булган: ул Мәрҗанине кызыксындырган тарихи текст һәм китаплардан кирәкле урыннарын күчереп җибәрә. Урта гасыр татар тарихы буенча хезмәтләр язучы ике галим арасында җылы һәм эчкерсез профессиональ мөнәсәбәтләр шулай ныгып, үсеп бара. Шиһабетдин хәзрәт, шәкерте Хөсәеннең вафатыннан соң, махсус хат язып, аның архивының бер өлешен Казанга алдыруга ирешә. Мәрҗани шушы хәзинәне үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле мәшһүр хезмәтендә файдалана. Анда Хөсәен Фәезхановның «Казан ханлыгы», «Касимовский ханлыгы» кульязмалары бераз үзгәртелеп һәм тулыландырылып урнаштырыла, шулай ук «Борынгы болгар ташлары» кульязма текстындагы мәгълүмат һәм күзәтүләр дә бирелә. Галимнәр бу күренешне остаз һәм шәкерт арасындагы ихлас хезмәттәшлекнең чагылышы буларак бәяли.

Аларның татарларның килеп чыгышы турында фикерләре дә кызыклы. Фәезхановча чувашлар нәсел җебен төркиләшкән мәҗүси фин халыкларыннан ала, татарлар – Идел буе Болгар дәүләтендә татар-монголлар басып алганчы ук кыпчаклашкан, күрше фин кабиләләрен төркиләштереп үзләре арасында «эреткән» мөселман динендәге болгарларның варислары, ягъни галим татар халкы оешуында төрле этник компонентлар катнашкан, дип саный. Бу хакта ул хатларында остазы Шиһабетдин Мәрҗанигә дә яза. Димәк, бүгенге татарларның килеп чыгышын болгарларга һәм өлешчә алар арасында ассимиляцияләнгән күрше җирле халыкларга бәйләп карау ике галимнең уртак фикере дип әйтергә нигез бар.

КЫРЫМ ХАНЛЫГЫНЫҢ ДИПЛОМАТИК КӘГАЗЬЛӘРЕН НӘШЕР ИТҮ

Хөсәен Фәезханов гарәп, фарсы, төрек, чуваш һәм рус телләрен яхшы белә, шулай ук мари, казах телләрен өйрәнә, борынгы үзбәк телендә китаплар укый. Фәннәр академиясе мондый югары әзерлекле текстологны 1858 елның язында Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү баш архивына Кырым ханлыгына бәйле чыганакларны ачыкларга һәм күчермәләрен эшләргә җибәрә.

1858 елның сентябренә кадәр, 4 ай чамасы архивта эзләнеп, галим ханлыкның Россия һәм Польша белән халыкара мөнәсәбәтләренә кагылышлы документларын барлый. Барлыгы 100 табак күләмендә кульязма текст күчереп ала. Моңарчы аларның саны 378 дип исәпләнсә, Фәезханов тагын 103 яңа документ таба. Шулай ук архив хезмәткәрләренә башка фондларда саклanучы гарәп имласындагы документларны барларга булыша.

Текстолог алып кайткан күчермәләр белән танышкач, академиклар Фәезхановның эш сөючән, тормышын фәнгә багышланган югары квалификацияле галим икәнен таныйлар. Аның бу фәнни батырлыгы киләчәк тормышында нык ярдәм итәчәк әле. Санкт-Петербург Фәннәр академиясенең Борис Дорн, Арист Куник һәм Владимир Вельяминов-Зернов составындагы тарих-филология бүлеге 1858 елның 15 октябрендә бу кыйммәтле документларны нәшер итү турында карар кабул итә.

Китапны әзерләү Вельяминов-Зерновка йөкләнә, Фәезханов академикка ярдәмче итеп билгеләнә. Архив документлары күчермәләрен бастыруга әзерләүдә Хөсәен Фәезханов хәлиткеч роль уйный, үзен тирән белемле урта гасырлар белгече итеп таныта: Вельяминов-Зернов аның татар теле сөйләмнәрен яхшы белүе шаһиты була, бик еш текстологның фикерләренә таянып эш йөртә. Шушы фәнни хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе булып 1864 елда Кырым дәүләтенең 1520–1742 елларда Польша һәм Россия хөкүмәтләренә атап язган 379 дипломатик кәгазе тупланган 950 битлек фундаменталь «Материалы по истории Крымского ханства» китабы нәшер ителә. Фәезханов шулай ук китап азагында исемнәр, географик һәм аерым терминнар атамалары күрсәткечен дә әзерләп урнаштыра.

КАБЕР ТАШЛАРЫН ӨЙРӘНҮДӘГЕ АЧЫШЛАР

Академик Владимир Вельяминов-Зернов белән хезмәттәшлек тагын бер юнәлештә дәвам итә. 1860 елның җәендә Фәннәр академиясе Фәезхановны татарлардан мәгълүмат җыярга һәм, ханлык чоры мөселман кабер ташларын өйрәнеп, күчермәләр алырга дип Касыйм шәһәренә командировкага җибәрә. Галим шәһәр зиратында 29 урта гасыр татар кабер ташы язуы күчермәсен ала һәм Касыйм ханлыгы турында фәнни хезмәт яза башлый.

Фәннәр академиясе 1860 елның 17 октябрендә археографка алып кайткан күчермәләре өчен рәхмәт белдерә, ә Вельяминов-Зерновка, бу кәгазьләрдән файдаланып, Касыйм ханлыгы турында фәнни китап язуны йөкли.

1863 елда Вельяминов-Зернов үзе дә, Касыймга барып, өстәмә чыганаклар туплый. 1863, 1864, 1865 елларда өлешләп нәшер ителгән «Исследование о касимовских царях и царевичах» китабы хезмәттәшлекнең матур нәтиҗәсе булып тора. Фәезханов алып кайткан эпитафик текстлар хезмәтнең 3 нче өлешендә урнаштырыла.

Галим Казах даласына барганда яисә кайтканда гадәттә, Казанда берәр атна торып, борынгы кабер ташларын өйрәнү максатында тирә-як татар авылларына бара. 1862 елны Тау ягына ясалган кыска вакытлы сәфәре вакытында Фәезханов Сембер губернасының Тархан исемле татар авылы һәм Тәтеш өязенең Урюм исемле мукшы авылы янында болгар чоры кабер ташларына юлыга. Өйрәнү нәтиҗәләрен археограф Фәннәр академиясенең Көнчыгыш бүлегендә 1862 елның 15 декабрендә доклад

Хөсәен Фәезхановның кабере. Сафаҗай авылы.

итеп сөйли. 1863 елны исә «Известия Русского археологического общества» басмасында бу турыда «Өч болгар кабер ташы язмалары» исемле мәкаләсен бастыра. Язма күләме буенча кечкенә булса да, эчтәлеге буенча сенсация тудыра. Моңарчы галимнәр Болгар чоры кабер ташларында гарәп имласы белән язылган даталарны дөрес укый алмаган булсалар, Фәезханов бу хәреф-сүзләргә «ачкыч» таба. Кабер ташларында саннар язылган сүзләрне чуваш теле ярдәмендә укырга кирәклеген дәлилли.

КАЗАХЧА-РУСЧА СҮЗЛЕК ЭШЛӘҮ ТАРИХЫ

Хөсәен Фәезханов 1855 елның 10 гыйнварында башкалада яшәүче, чыгышы белән Касыйм өязеннән булган Бибифатыйма Яхъя кызы Бикиева белән никахлаша. Бу никахтан гаиләдә туган Бибигайшә, Бибизәйнәп һәм Әминә исемле өч кыз бала исән-сау үсеп җитә.

Еллар дәвамында гаять зур киеренке шартларда гыйльми эшчәнлек белән шөгыльләнү, Санкт-Петербургның дымлы һавасы, бигрәк тә беренче елларда яшәгән фатирының кыш көннәрендә юеш булуы ахыр чиктә Хөсәеннең сәламәтлеген какшата. 1863 елда Шиһабетдин Мәрҗанигә язган бер хатында Фәезханов, үз-үзенә ышанмау һәм күңелне биләп алган шик-шөбһәләр, гомуми рухи төшенкелек һәртөрле чирдән дә авыррак, дип зарлана һәм үзен тынычландырып торучы хәләл җефетенә рәхмәтләр әйтә. Бу караңгы уйлар ул вакытта дәвалап булмый дип саналган туберкулез авыруыннан килеп чыккан булса кирәк. Фәезханов 1859 елда кан йөткерә башлый. 1861 елның ахырында табиблар Хөсәенгә Казах даласында кымыз эчеп дәваланырга киңәш итә.

1862 елны факультет җитәкчелеге Фәезхановның дәвалануга баруын 4 айлык фәнни командировка итеп раслата, юлга 100 сум акча да юнәтә. Галимгә казахларның авыз иҗаты үрнәкләрен җыю, бу төрки телне өйрәнү һәм казахча-русча сүзлек эшләү бурычы куела. Беренче барганда галим 2 мең сүз һәм экиятләр язып алып кайта. Шушындый кымыз белән дәвалану белән янәшә фәнни сәяхәтләрне галим тагын 1863, 1864, 1865 елларда ясый.

Фәезханов бу сүзлекне тәмамлый алмый. Шулай да аның хезмәте бушка китми. Казах теле буенча ул җыйган материалларны төрки телләр галиме Лазарь Будагов ике томлы «Сравнительный словарь турецко-татарского словаря» (1869, 1871 еллар) хезмәтендә файдалана.

Лектор 1865 елда даими рәвештә дәрескә йөри алмаганга, студентлардан имтиханны өендә кабул итә. Ә яз көне, Казах даласына барып җитмичә, Уфа губернасының бер авылында тукталып, шунда кымыз эчә.

Хәле вакытлыча яхшырып ала. Әмма 1865–1866 елның кышын авырып уздыра, укытырга йөрми диярлек. Факультет җитәкчелеге, галимнең тормышын җиңеләйтү өчен, 1866 елда аның кымыз эчәргә баруын сүзлекне тәмамлау өчен фәнни командировка итеп раслата: 1 апрельдән 1 сентябрьгә кадәр хезмәт хакын саклап, кулына 300 сум акча биреп юлга озата.

Фәезханов 7 апрельдә Санкт-Петербургтан юлга чыга, 6 майда туган авылында килеп җитә, авыруы көчәеп, Сабаҗайда тукталырга мәҗбүр була. Озакка сузылган каты авырудан соң, 1866 елның 28 августында вафат була. Җәсәде авыл зиратында дәфен кылынган.

китап к

ХАЛИСӘ ШИРМӘННЕҢ КИТАП КИШТӘСЕ

Язучы, шагыйрә, сценарийлар авторы, КФУ мөгаллиме һәм студентларның «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсе кураторы Халисә Ширмән татар классиклары Габдрахман Әпсәләмов, Адлер Тимергалин, Мөхәммәт Мәһдиев, Әмирхан Еники, Нәби Дәүлине үз белем-тәрбиясенә зур өлеш кертүчеләргә саный. Жюль Верны исә ул татарчага тәрҗемәсендә укыган! Нәкъ менә шулар аңа үзенең милли йөзен саклап калу мөмкинлеген биргән дә инде.

БАЛА ЧАКТА ҺӘМ ЯШЬЛЕКТӘ МИҢА ЗУР ЙОГЫНТЫ ЯСАГАН КИТАПЛАР

– Александр Дюма китаплары һәм испан новеллалары. Бүгенгедәй хәтерлим, туган авылым – Лениногорск районы Зәй-Каратайдагы китапханә киштәсендә Дюманың көрән төстәге 12 томы бик матур тезелеп тора иде. Берәр томны алам да өйгә йөгерәм... Уникенче томга чират җиткәч, бик хафаландым. Хәзер нишлим инде мин?! Нәтиҗәдә уникенче томны китергәч, кире беренче томны алып киттем. Һәм шулай итеп берничә тапкыр кабатланды... Мин үз тормышымны Дюмадан башка, Парижның король сарайларыннан һәм принцессаларыннан башка күз алдыма да китерә алмый идем инде... Китаплардагы әлеге тылсымны үземнең тормышыма күчерәм – балачагымда дусларым белән иң яраткан уеныбыз принцессалар һәм рыцарьлар булып уйнау иде. Аннары испан новеллаларына чират җитте. Мин авторларның исемнәрен дә хәтерләмим (татар авылында яшәүче кызчык өчен алар әйтеп бетергесез авыр тоела иде), әмма ул чакта бу әсәрләр мине искиткеч романтик антураж – мәхәббәт, диңгез, пиратлар һәм баш әйләнерлек мажаралары белән әсир итте...

ЯРАТКАН КИТАБЫМ

– Минем яраткан китабым – Колин Маккалоуның «Поющие в терновнике». Нәрсә белән җәлеп итәме? Эпос булуы белән. Гомер буена сузылган сөю тарихы белән. Тыелган темалары белән. Һәм католиклар чиркәве руханиларының тормышын күрсәтүе белән. Мин бу китапны укымадым – мин анда яшәдем. Һәм хәзергә кадәр минем җанымның бер өлеше Мегги образында яши.

КҮПТӘН ТҮГЕЛ УКЫЛГАН КИТАПЛАРДАН ИҢ ТӘЭСИРЛЕСЕ

– Әгәр моннан 5-6 ел элек «күптән түгел»гә саналса, татар интеллигенциясенең Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романына мөнәсәбәте гаҗәпләндерде. Язучының исә үзенә тонналап актарылган нәҗестән югалып калмавы, ныклыгы, чын мәгънәсендә зыялы булуы сокландырды. Мин шулай булдыра алырмынмы икән? Юктыр, мөгаен... Авторны милли идеягә хыянәт итүдә дә, тарихи фактларны бозып күрсәтүдә дә (әйтерсең лә документаль әсәр бу!), һәм хәтта ирләр эшенең рәтен белмәүдә дә (мәсәлән, землянка төзелешен сурәтләгәнгә) гаепләделәр. Кызык та, кызганыч та. Мин исә Гүзәл Яхинаны искиткеч романы белән котладым. Миңа бигрәк тә әсәрнең язу өслүбе (аеруча татар халкы көнкүрешенең рус теленә тәрҗемә ителми торган терминнарын куллану), Советлар Союзы аякка баскан чорда – репрессияләр вакытында һәм якты тормыш өчен көрәш чорында яшәүчеләрнең искиткеч төгәл образларын тудыру осталыгы ошады.

Фото: Александр Ефремов

иштәсе



КИҢӘШ ИТӘМ...

– Милли әдәбият әсәрләренә күбрәк игътибар бирергә киңәш итәм. Еш кына алар күләгәдә кала, ә бит татар язучылары арасында талантлы һәм уңышлы каләм әһелләре байтак. Мәсәлән, Марат Кәбиров, Зөлфәт Хәким, Галимҗан Гыйльманов, Марат Әмирханов, Ркаил Зәйдулла. Бу инде атаклы, танылган язучылар. Бәхеткә, ТР Язучылар берлеге СССР таркалгач онытыла төшкән милли әдәбиятны тәрҗемә итү практикасын яңартты, шунлыктан якын киләчәктә хәзерге заман татар язучыларының рус телендә чыккан китаплары рус телле укучыларның китапханәләрендә дә, йөрәкләрендә дә үз урынын табар, дип өметләнәбез. Ә инде чит ил язучыларына килгәндә, монда мин беркайчан да актуальлеген җуймаячак классиканы бик сөенеп тәкъдим итә алам: Джек Лондон, Джером Сэлинджер, Рэй Брэдбери әсәрләре беркемне дә битараф калдырмый.

КИҢӘШ ИТМИМ...

– Ниндидер бер аерым жанр белән генә мавыгырга һәм бигрәк тә шуның белән генә чикләнергә киңәш итмим. Әледән-әле хикәяләүнең башка формаларына да күчү файдалы – шул рәвешле без укуга мәхәббәтне саклап кала алачакбыз.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

– Минем өстәлемдә якын арада укырга кирәк дип сатып алынган китаплар өелеп ята... Мәгариф системасы вәкилләренең барысына да хас булганча, нәфис әдәбият укыр өчен вакыт җитмәүгә зарланам. Бу бик аяныч. Һәм бу дөрес түгел! Шунлыктан барыбер вазгыятьне контрольдә тотарга тырышам, өстәвенә, язучы буларак, миңа каләмдәшләремнеңниләр язуын белеп тору мөһим бит.

Менә күптән түгел Зиннур Хөсниярның «Хур кызлары» романын һәм Галимҗан Гыйльмановның «Албастылар» романының икенче кисәген ниһаять укып чыга алдым. Бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике әсәр, әмма икесе дә укучы күңеленең иң нечкә кылларына чиртерлек итеп язылган.

МИНЕМ ӨЧЕН КИТАП УЛ...

– Виртуаль дөнья, аңа кереп чуму сине дә, тормышыңны да үзгәртергә мөмкин. Китапны укыганда, син меңнәрчә гомер кичерә аласың, әмма бу башка форматта – әлеге параллель дөньяда син король дә, принцесса да буласың, нәни малай яки кызга әйләнеп, кабат балачакка әйләнеп кайтасың, тәүге сөю рәхәтен татыйсың яки хыянәт ачысын кичерәсең – һәм боларның барысын да үзең сайлап аласың. Әмма аеруча тәэсирләнүчән һәм мавыгучан укучыларны кисәтәсем дә килә. Язучы уйлап тапкан дөньяга кереп чумганда, чынбарлыкны виртуальлектән төгәл аеру мөһим, югыйсә үзеңнең чын тормышыңнан күңелең кайтырга мөмкин бит. Хәзер мин инде китап укуга башкача карыйм – укыганда, мин өйрәнәм. Язарга, сюжет һәм интрига төзергә, образлар тудырырга өйрәнәм. Мин китапны «молекулаларга» таркатам да, аннары кабат җыям. Минем өчен авторлар – укытучы. Тик мин, китап – тормыштагы гамәлләр белән идарә итү ул, ниндидер инструкция, дигән фикердән ерак торам. Юк, китап – беренче чиратта чынбарлыкта үз гамәлләреңне сайлау мөмкинлеге булуны аңлау ул. Шул ук вакытта укучы (бигрәк тә яшь кеше) шуны да хәтерендә тотарга тиеш – кайбер китаплар пропагандачылар кулында явыз коралга да әйләнергә мөмкин бит. Китап – дару кебек ул: агуга әйләнмәсен өчен, төгәл дозада кабул итү зарур.

КӘГАЗЬМЕ, ЭЛЕКТРОНМЫ?

– Катлаулы сорау... Минем буын китап битләрен кыштырдатуга күнеккән булгәле, әмма электрон китапны да чит итмим. Минем өчен аерма зур түгел – формасына караганда, эчтәлеге мөһимрәк.

PRESSA

ГАЛӘМ ЭЧЕНДӘГЕ ГАЛӘМНӘР, ЯКИ БЕЗ КАЙЧАН ЧЫНБАРЛЫК БЕЛӘН УЙДЫРМАНЫ БУТАДЫК?

Луиза Янсуар

«Кибердөнья» һәм «виртуаль дөнья» төшенчәләре безне күптән гаҗәпләндерми, хәтта беркадәр искергән, очсызлана төшкән кебек тә тоела. Фантастика сүзен дә инде шактыйдан чынбарлык алыштырды. Ә менә язучылар исә һаман шуларның чигендә торган яки кушып булмастайны куша алган әсәрләр иҗат итә тора. Безгә күңелсез булмасын өчен, билгеле.

Фото: goodfon.ru, litres.ru, livelib.ru, labirint.ru, сайтларыннан алынды.



КЕМ ҺӘМ НИ УЙНЫЙ?

Саманта Швеблин, «Кентуки»

Тәрҗемә: Наталья Богомолова

Әлеге роман турында сүз башлаганда, еш кына шаяртырга яраталар: «Америкадагы Кентукки штаты белән бутамагыз, яме». Аргентина язучысы Саманта Швеблинның бу рус теленә тәрҗемәдәге икенче китабы һәм популярлык буенча – иң беренче пландагысы. Югыйсә, ул инде моңа кадәр басылып чыккан повесте – «Дистанция спасения» белән Халыкара Букер премиясенең шорт-битенә эләккән иде. Ә менә «Кентуки» аеруча популярлык казанды, әйтерсең, бу роман нәкъ менә үз вакытын көтеп алып, безнең гасаби күңелләребезне кузгатыр өчен махсус дөнья күргән.

Сюжет линиясе гади генә, ә менә психологик катламнар һәм тәэсир итү көче – сизелерлек югары. Дөресен генә әйткәндә, бу китапны уку җиңелләрдән түгел. Шактый уңайсызлык, урыны-урыны белән хәтта ачу һәм чиркану кичерәсең, әмма аерыла алмыйсың...

Шулай итеп, без Саманта Швеблин уйлап чыгарга уйдырма да, әмма үтә таныш чынбарлык та булган дөньяга кереп чумабыз. Һәм кентукиның асылда ни булуын аңлап алабыз. Бу «модный» уенчык-девайс, баксаң, электрон йорт хайваны икән. Ирексездән, тамагочилар һәм алар «җан тәслим кылганнан соң» түгелгән күз яшьләре,

Әнә шул чакта ул аларны беренче мәртәбә күрде. Бер рәткә 15 ләп, ә бәлки 20 ләп тартма тезелгән. Һәрберсендә бер язу – «Кентуки». Шунда ук аңлыйсың – бу гади генә уенчык түгел. Сатып алучылар яхшырак күрсен һәм кызыксын өчен, кайбер модельләрне, тартмадан чыгарып, бастырып куйганнар. Кул сузып кына үрелеп ала алмыйсың, әмма карашны җәлеп итә. Алина кулына бер тартманы алып, әйләндереп карады – ап-ак, куз явын алырдай, өр-яңа модель айпад һәм айфон тартмаларыннан бер дә ким түгел.

Һәр кентуки 279 доллар тора, ә бу бик кыйммәт. Матурлыкка ис китәрлек берни юк, әмма ниндидер, кыйммәтле әйберләрдә генә була торган затлылык, ыспайлык... Менә анысы бар. Нишләп шулай карашны үзенә кадаклап куялардыр, монысын Алина аңлый алмый азапланды.

Нәрсә соң болар чынлыкта? Төрле тартмаларда төрле җәнлек төшерелгән, бертөрлеләрне, эзләп караса да, тапмады. Барысы да бар – куян да сукыр тычкан да, карга да, панда да, аждаһа да, ябалак та.

Алина, күңеленнән генә санап, биш җәнлекне сайлады. Аннары шул бишесеннән – икене. Кайчан да булса ул бу уенчыкны һичшиксез сатып алачак. Яшь-яшь сатучы егет, аның кулында кентуки тартмасын күреп, чын-чынлап куанды, балкып ук китте:

– Минем абыемның бар инде, үзем менә сатып алыр өчен акча җыям. Белсәгез икән, бу – фантастика!..

ай-вайлар искә килеп төшә. Әмма тамагочидан аермалы буларак, кентуки шактый хәтәр нәрсә, карап торышка гына – тәти һәм матур. Бу күркәм җәнлекләрнең күзләре урынына камера беркетелгән, һәм ул «күзләр» өйдәге бөтен нәрсәне теркәп, фиксацияләп бара. Өстәвенә, һәр кентукиның – үз холкы һәм темпераменты. Хуҗаларга техник яктан куллану буенча инструкция бирелсә дә, психологик яктан һәркайсы кентуки белән мөнәсәбәтләрне кора алырга әзер булмаска да мөмкин.

Ә хәзер иң мөһим һәм катгый сорау – ник соң бу кулга ияләштереп булмый торган сәер уенчыкка барысы да шулкадәр мөкиббән? Менә шушы урында башлана да инде психологик катламнарга күмелү һәм үзебез дә үзебезгә ачарга теләмәгән серләрне ачу...

...Ә сезнең кентуки «күзләре» белән яздырып һәм теркәп барган мәгълүматның чынлыкта кая элеккәнен беләсегез киләме? Димәк, безнең белән кемнәрнең нинди уеннар уйнаганын да беләчәксез, дигән сүз.

СЮЖЕТ ЛИНИЯСЕ ГАДИ ГЕНӘ, Ә МЕНӘ ПСИХОЛОГИК КАТЛАМНАР ҺӘМ ТӘЭСИР ИТҮ КӨЧЕ – СИЗЕЛЕРЛЕК ЮГАРЫ. ДӨРЕСЕН ГЕНӘ ӘЙТКӘНДӘ, БУ КИТАПНЫ УКУ ҖИҢЕЛЛӘРДӘН ТҮГЕЛ. ШАКТЫЙ УҢАЙСЫЗЛЫК, УРЫНЫ-УРЫНЫ БЕЛӘН ХӘТТА АЧУ ҺӘМ ЧИРКАНУ КИЧЕРӘСЕҢ, ӘММА АЕРЫЛА АЛМЫЙСЫҢ...

ХӘЗЕР ҺӘМ ШУШЫНДА

Илья Техликиди, «Антонов коллайдер»

«Другая реальность» сериясендә басылып чыккан бу роман Замятин белән Пелевин, Глуховский белән Рубанов традицияләрен дәвам итә, нигездә, алар тудырган дөньяларны янә бер мәртәбә кабатлап тудыру булып та тора шикелле. Һәм, әйтергә кирәк, ул турыдан-туры интертекстуальлеккә, цитацияләргә корылган. Автор хәтта бу цитацияләр белән горурлана, аларны уйнатудан үзенә бер тәм таба кебек тоела кайчакта. Анык кына атап та булмый – нәрсә бу, антиутопияме, әллә фәнни фантастикамы? Кибердөньяларга сәяхәтләр һәм «Матрица» галәмнәрен яңартулар инде күптән модадан чыгып бара булып тоелса да, юк икән, киресенчә, алар үзгә бер яңа укылыш алырга җыена...

«Антонов коллайдер» – яшь язучының тәүге романы. Һәм ул инде, басылып

чыкканнан соң, шактый күп карашлар, поляр фикерләр тудырырга, бәхәсләргә сәбәпче булырга да өлгерде.

Әйтергә кирәк, Илья Техликиди үз укучысын чакырган дөньялар виртуаль киңлектә инде гөрләп яши. «Глагол» әдәби мәктәбе тыңлаучысы, креатив продюсер һәм музыкант булудан тыш, ул әле виртуаль дөньялар тудыручы да. Роман мотивлары буенча «In The Air. Фейки, которые убивают» веб-уены чыгарылды. Үзенең социаль челтәрләрдәге аккаунтында Техликиди бик теләп роман каһарманнарын биреп бара, аларның романнан тыш тормышларын һәм параллель дөньяларын чагылдыра. Бу инде үзенә күрә – галәм эчендәге галәмнәр, дисәк тә буладыр.

Ярый, нәрсә турында бара соң сүз? Урыны һәм вакыты буенча вакыйгалар Россиядә бара. Бу – 2050 нче еллар. Кешеләр белән күптән бакыйлыкка күчсә дә, мәңгетере Ясалма Интеллект – Бөек Юлбашчы идарә итә. Бу дәүләт системасында төрле катлам вәкилләре бар, ә иң түбәндә торучы һәм очын-очка ялгап көн күрүчеләрдән берсе – data-курьерлар. Ясалма интеллект никадәр генә Алланы алмаштырмасын, кешедән дә ышанычлырак мәгълүмат йөртү чарасы барыбер уйлап табылмаган.

Һәм менә Антон күзенә беркетелгән линза аша мәгълүмат таратыр өчен һәр иртәне өеннән метрога чыгып китә. Биредә һәр секунд язып куелган, соңарырга, мәгълүматны югалтырга ярамый. Көндәлек бирем – 8 сәгать эчендә 12 пакет мәгълүматны тиешле адреска илтеп җиткерү һәм йөкләтеп калдыру. Маршруттагы һәр адрес – метро боҗрасындагы станция. Эш көне тәмамлангач, Антон һәр кичне, 15 криптоюань алып, Мәскәү читендәге тар, кысан һәм тынчу фатирына кайтып егыла.

Әмма иң кызыгы – аның юлында очраган геройлар белән алардан бөркелеп торган тормыш фәлсәфәләре. Ялган һәм кемдер тарафыннан тагылган хакыйкатьләр. Хәтта яшәү картиналары да. «Ә нәрсә, шулай түгелмени?!» – диясе килә берөзлексез.

Техликиди беркатлы, самими романтика белән ачы сарказм, цинизмны укмаштыра һәм «Антонов коллайдер», шул рәвешле, жанрлар гына түгел, ә пафослар ягыннан да чиктән чиккә ташлана. Әмма бу яшь автор тарафыннан, аңлашыла ки, махсус эшләнә, хәтта аерым новеллалар шәлкеме дә – ишарәләр, аллюзияләр тулы.

Ә азакта... билгеле инде, көтелмәгән финал. Ә ник әле ул юралган һәм көтелгән булырга тиеш, ди?

Укыр өчен 5 сәбәп:

1. Актуаль киберпанк-дистопия. Бу тыгыз динамикалы, мавыктыргыч сюжетка корылган әсәр, автор җәмгыятьне контрольдә тотар өчен кулланыла торган яңа технологияләр турында уйланырга чакыра.

2. Төп каһарман, data-курьер, Мәскәү метросы боҗрасы буйлап локациядән локациягә күчеп мәгълүмат тарата, асылда бу үзенә күрә онлайн-уенны хәтерләтә – һәр квестның ни булып бетәсе билгесез.

3. Интерактив виртуаль сәяхәт. Укучылар роман галәмендәге веб-уенның турыдан-туры катнашучылары.

4. Автор заманында Уильям Гибсон, бертуган Вачовскилар, Владимир Сорокин, Виктор Пелевин, Дмитрий Глуховский күтәргән футурологик линияләрне яңача үстерә һәм дәвам итә.

5. Киберпанк кынамы, әллә социаль көрәшме? Романдагы вакыйгалар бик якын киләчәктә бара, әмма котны алырдай рәвештә чынбарлык булып тоела. Һәм авторның фаразлары чынлап та тормышка ашармы, шуны беләсе килә.



КЕЧЕ КАЙБЫЧ, НИ ХӘЛЕҢ БАР?



Фото: Александр Ефремов

КЕЧЕ КАЙБЫЧ

Бу якларны белмәүчеләр Кече Кайбычны район үзәге дип уйларга мөмкин. Ә район үзәге Олы Кайбыч санала, аңлашыла ки, анысы күпкә зуррак. Ике Кайбычны нибары дүрт чакрым юл аерып тора. Кече Кайбыч ничек яши? Аны олы абыйсы «йотмыйммы»? Бу якларга сәяхәт кылып кайттык.

Руфия Фазылова

«ЯШИБЕЗ!»

Кече Кайбыч зур авыл түгел: 131 йортта 379 кеше яши. Архив документларыннан күренгәнчә, 1919 елда биредә 1200 кеше булган. Ачлык, Бөек Ватан сугышы, соңрак исә 1990 нчы еллардагы үзгәртеп кору җилләре авылдагы халык санын өч тапкырга киметкән. Әйе, Кече Кайбыч бүген югалып баручы авыллар рәтендә түгел үзе. Бер дигән башлангыч мәктәбе, балалар бакчасы, ФАП, мәдәният йорты, китапханә – кыскасы, көндәлек тормыш өчен кирәкле барысы да бар.

Авыл белән танышуны мәдәният йортыннан башладык. 1986 елда салынган зур гына бина ул. 2016 елда аңа капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Биредә эшләүчеләрнең тырышлыгыдыр – мәдәният йорты бүген дә өр-яңа кебек!

Бинаның бер ягына китапханә урнашкан. Китапханәче Рузалия Гыйматдинова белән аралашып алдык – утыз өч ел әлеге хезмәттә икән. «Китапханәгә кышын өлкәннәр күп йөри, җәен исә кунакка кайткан балалар да килә», – диде ул.

Гөлсинә апа Гыймранова көн саен диярлек башмак бәйли. Бу якларда аны, матур итеп, «пәпеш» дип йөртәләр.

Китапханәче белән авыл апалары турында сөйләшеп алдык. Кече Кайбычта бәйләүче, чигүче хатын-кызлар бик күп икән. Әнә шундыйларның берсе – Гөлсинә Гыймранова – Кече Кайбычта туып үскән.

– 1942 елда туган мин, – диде Гөлсинә апа. – Әти фин сугышыннан яраланып кайтканга күрә, Бөек Ватан сугышына алмаганнар. Биш бала үстек, өчебез мәрхүм инде. Җиде класс тәмамладым, башлангычны үзебезнең авылда укыдым, аннары Бәрлебаш мәктәбенә йөрдек. Бер сыйныфта утыз алты бала идек. Авылның зур, гөрләп торган вакытлары ул. Монда сыер, сарык фермалары бар иде. Колхоз күпләп каз, үрдәк тә асрады. Аннары безнең якларда халык кирпеч сукты. Миннән өч яшькә өлкән апа белән без дә ул эшне күп башкардык. Су буеннан балчыгын тартып ташыдык. Хәтерлим, әзер кирпечләрне әти өеп бара. Бернигә кадәр җыелгач сатасың...

Гөлсинә апа хәләл җефете Бәхетгәрәй белән дүрт кыз үстергән. Кызганыч, балаларының әтисе кыска гомерле булган – утыз ел элек бакыйлыкка күчкән. Кызларының берсе – Фиданиясе – әнисе янында, икесе Кайбычта, берсе Казанда яши икән. Инде үзләре дәү әни булган.

Кул эшләре дигән идем. Гөлсинә апа көн саен диярлек башмак бәйли. Бу якларда аны, матур итеп, «пәпеш» дип йөртәләр. Яңа елга кадәр мобилизацияләнгән егетләргә тугыз пар шундый башмак җибәргән.

– Яшь чагында бик күп чиктем, челтәрләр дә бәйләдем, – диде әбекәй. – Ул чорда бөтен яшь кыз шуның белән шөгыльләнде. Хәзер инде чикмим, бәйлим генә. Җепләрне сатып алабыз.

– Аның кадәр башмакны кая куясыз? – дим.

– Бүләккә таратам. Кызлар, оныклар, туганнар күп. Фидания дә бәйләргә ярата, тик утыра белмибез. Аллага шөкер, күзләрем әйбәт күрә, газета-журналларны да күзлексез укыйм.

ЙӨЗЕК КАШЛАРЫ!

Авылларга баргач, еш кына матур гаиләләр белән очрашабыз. Әлбәттә, аңлыйм, авыл җирлеге башлыклары безне иң үрнәк гаиләләр белән таныштыра. Ләкин алар бар бит! Ничек инде күрсәтмисең?! Ябалак авылы җирлеге башлыгы Мөслимә Гыйззәтуллина да безне Кече Кайбычның йөзек кашлары – Зиннуровларга алып барды. Алар турында бөтен район белә икән!

Рәшит абый белән Гөлшат апа өч ул тәрбияләп үстергән. Малайларның өчесе дә югары белем алып авылда калган. Төпчекләре Фәнил үзләре янында булса, калган икесе аерым йорт салып чыгып, гаиләләре белән яшиләр. Олы уллары Фәрит крестьян-фермер хуҗалыгы ачкан, энеләре Фәннур белән Фәнилне дә бу өлкәгә җәлеп иткән.

– Балаларны авылда калырга озак үгетләдегезме? – дидем ярым шаярып Рәшит абыйга.

– Бөтенләй үгетләмәдек, үзләре калды. Әле киресенчә, Фәнил авылга кайтам дигәч: «Улым, шәһәрдә калу ягын карамыйсыңмы?» – дидек. Ә ул Кайбыч урта мәктәбенә физкультура, ТИН дәресләре укытырга кайтты. Мәктәптәгеләргә: «Төпчек малай әти-әни янында калырга тиеш», – дигән. Шуның өчен дә өйләнгәч тә чыгып китмәде. Тату гына бергә яшәп ятабыз, барысыннан да бик канәгать.

Рәшит абый белән аралашканда гел күзәтәм: Гөлшат апа кечкенә оныгын кулыннан төшерми. Фәнилнең икенче кызы икән, бер яшь тә җиде ай тулган.

– Әнисе эшкә чыкты, – диде Гөлшат апа. – Баланы бакчага бирик дигәннәр иде, кызгандым. Кечкенә бит әле. Рәшит белән икебезгә бер бала, ничек тә карыйбыз. Безнең монда шифаханә кебек: кемнең баласы авырса да калдырып китәләр.

Гөлшат апа утыз елдан артык Кайбыч бәби тудыру йортында акушер булып эшләгән. Шуның өчен бала тәрбияләүнең барлык нечкәлекләрен белә. Хәзер инде лаеклы ялда. (Кайбычта бәби тудыру йорты юк та инде.)

– Ул чакларда бигрәк аны-моны уйламыйча эшләгәнбез икән, – диде Гөлшат апа. – Хәзер генә ул хастаханәләрдә кан плазмаларда кайта, нинди группа кирәк булса, шунысы бар. Ә элек, кан группасын билгеләп, турыдан-туры сала идек. Хәзер шулар төшләргә керә: кайчакта табиб та янда булмый, барысын да үзебез эшләдек. Соң, шунда берәр фаҗига килеп чыкса? Шөкер, андый очраклар булмады, Аллаһ саклагандыр инде...

Фәрит, КДПУны тәмамлагач та, районда үз эшен булдырган – экскаватор белән сулар кертеп, юллар карап йөргән. Бер ел элек исә КФХ ачкан – иген, печән үстерәләр. Пай җирләрен арендага алып эшлиләр. Барлык техниканы да сатып алганнар. Дөрес, яңа түгел, ләкин әлеге этапта эшләр өчен барысы да бар. Дәүләттән грант та, бүтән ярдәм дә алмаганнар. Сезон вакытында эшкә берничә кешене чакыралар. Әлеге дә баягы, алары да туганнар икән.

Рәшит абый үзе дә югары белемле ветеринар. 1977 елны Казан дәүләт ветеринария институтын тәмамлаган. Шуннан соң әтиәнисе янына – Кече Кайбычка кайтып, фермага зоотехник булып урнашкан. Дүрт елдан исә ферма мөдире итеп куйганнар. Нәтиҗәдә, утыз сигез ел әлеге вазыйфаны башкарган. Лаеклы ялга чыккач исә эшеннән киткән. (Биш елдан соң инде Кече Кайбычта фермалар да беткән.)

– Улларыбыз кечкенәдән эшләп үсте, – диде эти кеше. – Шуның өчен дә авылда калырга уйлаганнардыр дим. Өйдә гомергә күп итеп мал-туар тоттык. Әле ферма мөдире булганда, малайларны үзем белән эшкә дә алып бара идем. Төрле чак була бит, йә сыер савучы авырып китә, йә бүтән сәбәп. Ә болай кешегә ялынып тормадым. Малайлар биш яшеннән кул арасына керде инде. Хәзер этиләре оныкларны шулай тәрбияли – печән җыярга да баралар, маллар карарга

Кече Кайбычның йөзек кашлары – Зиннуровлар.

2015 елда «Бәләкәч» республика программасы нигезендә өр-яңа заманча бина корып куйганнар.

да ярдәм итәләр. Иң яхшы тәрбия – хезмәт тәрбиясе.

Гөлшат апа чәй табынына чакырды: ни генә юк монда! Кортлы май, катык, төрле итләр... Һәм барысы да үзләренең хуҗалыгыннан. Рәшит абый бүген дә җиде сыер асрый, үгезләре дә бар. Ел әйләнәсе сөт, ит ризыкларыннан өзелмиләр икән.

Табынга утыргач, Гөлшат апа хәләл җефетенең серен чиште – Рәшит абый Кече Кайбычка биш яшендә генә кайта. Тәрбиягә алынган бала ул. Гөлшат апа кайнана, кайната янына килгән. Егерме җиде ел кайнанасы белән яшәгән.

– Үз әти-әнием бер-бер артлы вафат булган, – диде Рәшит абый. – Әти апрель аенда операция вакытында үлгән, ә әнине шул елны яшен суккан. Әти-әнидән алты бала калганбыз. Мин иң кечкенәсе, ул вакытта өч яшь булган. Мәктәпкәчә яштәге апа белән икебезне Яшел Үзәннең Норлат балалар йортына, ә калган туганнарны Балтач интернат-мәктәбенә җибәргәннәр. Ике елдан соң мине Кече Кайбычтагы әти-әнием уллыкка алган. Үзләренең фамилияләрен биргәннәр.

– Ә апагызны балалар йортында калдырганнармы?

– Ни өчендер аны алмаганнар шул. «Сине бер күрүдә яраттык, үзебезгә охшаган идең», – дия иделәр. Әти-әнигә мин бик рәхмәтле. Какмадылар, сукмадылар гына түгел, рәхәттә үстерделәр. Укыттылар. Мин инде аларны үги әти, үги әни дип һич әйтә алмыйм.

Кайбер гаиләләрдән китәсе килми, чөнки анда гаҗәеп бер җылылык була. Рәшит абый белән Гөлшат апа бик рәхәт кешеләр: шуның өчен дә балалары да яннарыннан ерак китмәгәннәр. Рәшит абыйның бертуганнары да (үскәч, барысы да табышкан алар) бирегә еш кунак. Әле ялгыз яшәүче абыйсын да үзләренә яшәргә алып кайтканнар...

Ихластан бу гаиләгә озын гомер, иминлек телим. Бәхетегез кителмәсен!

Ике класска унбер укучы бар: бирегә икенче һәм дүртенче сыйныфлар гына. Аларга ике укытучы белем бирә.

БАКЧА БЕЛӘН МӘКТӘП – ЯНӘШӘ

Кече Кайбычта мәктәп гел башлангыч кына була. Аның тарихы 1934 елдан башлана. Шул елны күрше Кошман авылы конторасы бинасын ташып, мәктәп итеп өяләр. Ә парталарны Норлаттан ташыйлар. Сугыш вакытында да бирегә укулар туктатылмый.

1960 елны мәктәпне уңайлырак итеп яңадан сүтеп җыялар. Шушы иске бинада дистә еллар йөздән артык укучы белем ала. 1990 елның 1 сентябренә яңа мәктәп бинасы төзелә. Ул бүген буш тора. Ә янәшәсендә 2015 елда «Бәләкәч» республика программасы нигезендә өр-яңа заманча бина корып куйганнар. Аның бер ягында башлангыч мәктәп, икенчесендә балалар бакчасы урнашкан. «Сандугач» дип язылган әлеге бина ерактан ук күзгә ташлана.

Башлангыч мәктәп Олы Кайбыч урта мәктәбенә карый икән. Шуңа күрә монда аерым директор юк. Ике класска унбер укучы бар: бередә икенче һәм дүртенче сыйныфлар гына. Аларга ике укытучы белем бирә. Балалар аерым кабинетларда укый, ә менә тәнәфесләрдә гел бергә икән.

– Узган ел балалар күбрәк иде, чөнки беренче, өченче, дүртенче сыйныфлар бар иде, – диде мөгаллимә Алсу Лотфуллина. – Дүртенчене тәмамлап, дүрт балабыз Олы Кайбычка китте. Ә беренчегә керүче булмады.

Балалар белән аралашып алдык: үткеннәр. Җырлап, сөйләп, биеп тә күрсәттеләр. Арада бишкә генә укучылар да, чиреккә өчле чыга торганнары да бар икән.

– Безнең бердәнбер проблема – балаларның татарчалары начар, – диде мөгаллимнәрнең икенчесе Гүзәлия Низаметдинова. – Ничә еллар балалар укытып, бүгенге кебек хәлне күргән юк иде. Аптыраш.

– Ә алар өйдә татарча сөйләшәме соң? – дим.

– Әйе, татарча. Үзебезнең Кече Кайбыч авылы балалары бит. Бездә татарлар гына яши. Әти-әниләргә дә әйтәбез инде, мәктәптә дә татарча укытабыз. Ләкин сөйләм телләре камил түгел, татарча белән русчаны кушып сөйлиләр...

Укучылар һәм укытучылар белән саубуллашып, балалар бакчасы ягына чыктык. Төрле төсләргә буялган коридорлар, биек түшәмнәр. Авылларда да шундый үзәкләр төзелү зур куаныч!

– Балалар бакчасы ачылганчы безнең балалар Олы Кайбычка йөри иде, – дип сөйләде бакча мөдире Альбина Сибгатуллина. – Ата-аналарның күбесе район үзәгенә йөреп эшли бит. Кайбер балалар әби, бабай, әниләре белән өйдә дә утырды. Ләкин район үзәгендәге бакчага гел зур чират була иде. Шуның өчен Кече Кайбычта бакча ачылу бу проблеманы хәл итте.

Мөдир бакча белән таныштырып йөри: зур актлар залы, йокы, ашау, киенү-чишенү бүлмәләре аерым. Җиһазландырылган аш бүлмәсе, медицина бүлмәсе – барысы да заманча. Хәтта залга аерым музей почмагы да ясап куйганнар. Балалар бакчасы егерме биш урынга исәпләнгән. Яшь ярымнан җиде яшькәчә балалар тәрбияләнә биредә. Бүгенге көндә унсигез бала икән. Шуның берсе күрше якка – мәктәпкә күчәчәк. Сентябрь аена егермедән артык бала булыр дип көтәләр.

– Тәрбиячеләребез тәҗрибәле, бик тату эшлибез, – диде Альбина Сибгатуллина. – Балаларны татар телендә тәрбиялибез, бәйрәмнәр дә татарча уза. Әти-әниләр бик канәгать. Шулай матур гына эшләргә язсын.

...Авыл кешеләренең күбесе эшкә район үзәгенә йөри. Шәһәр белән чагыштырганда, дүрт чакрым ара нәрсә инде ул. Йөзләгән ел тарихы булган әлеге үзенчәлекле авыл киләчәктә дә яшәр, яшәрер, район үзәге аны «йотмас» дигән өметтә калам. Бәхетләренә, Зиннуровлар кебек тагын берничә яшь гаилә барлыкка килмәсме... Т

Балалар бакчасында аерым музей почмагы да ясап куйганнар.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Кече Кайбычның тарихы 1515–1516 еллардан башлана. Легендага караганда, бу якларга Хайбуч атлы бер ир килеп төпләнгән. Аның өч улы туган. Иң олысын ул Олы Кайбыч җирләренә, уртанчысын Буа районының Кайбыч авылы урынына җибәргән, ә кечесен биредә – Кече Кайбычта калдырган. Авыл исемнәре шуның белән бәйле булырга тиеш.

Кече Кайбыч элек бик зур авыл булган. Күрше-тирә авыллар чукындырылганда да, Кече Кайбычка керә алмаганнар.

(Кече Кайбыч китапханәсендә тупланган истәлекләрдән).

ТАРИХКА КАЙТЫП КИЛҮ (16+)

ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда XX гасырның икенче яртысына караган рәсем һәм скульптура әсәрләреннән торган совет сәнгате күргәзмәсе тәкъдим ителә. Бу әсәрләр ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее фонды тупланмаларында саклана.

«Безнең адрес Советлар Союзы!» дип аталган күргәзмә унбер тематик залдан тора. Әлеге залларның һәркайсы совет кешесе тормышының бер ягын чагылдыра. Күргәзмә атаклы совет фильмнарыннан өземтәләр белән дә тулыландырылган. Экспозицияне өй темасына багышланган инсталляция ачып җибәрә. Анда һәр тамашачы үзен совет чорындагы кебек хис итеп, шул заманның сулышын тоя ала.

26 февральгә кадәр

ТР ДССМның «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы, Казан, Кремль ур., 12

афиша

КЕМ ҖИҢӘР? (16+)

Ике герой арасында барган драматик конфликт, психологик һәм шәхси каршылык... Теләсә кем белән булырга мөмкин гап-гади вакыйга. Һәркемнең үз дөреслеге, максаты, фикер сөреше. Дөньяга карашлар бәхәсендә, үз-үзеңне ярату уенында һәм тормыш абсурдына каршы торуда һәркем җиңеп чыгарга, тантана итәргә тели.

Автор белән Цензорның, сәнгать белән циркулярның, фантазия ирекe белән рөхсәт ителгән кысаларның кисешүе нәрсәгә китерер? Кисәтү утлары кабызырмы яки башны көлгә яшерү дөресрәк булырмы – япон драматургы Коки Митаниның «Көлке академиясе» пьесасы буенча Камал театры сәхнәсендә А.Җәббаров сәхнәләштергән «Көл» спектаклендә сүз шул хакта барачак.

21 февраль, 19:00

Г.Камал исем. Татар дәүләт Академия театры.

Казан, Татарстан ур., 1

Фотолар әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан алынды

ХӘРЕФЛӘР НИК ҮПКӘЛӘГӘН?.. (0+)

Кариев театры нәни тамашачыларын тылсымлы дөньяга – Хәрефләр иленә чакыра. Ә кайда соң ул ил? Әлбәттә, «Әлифба»да!

Тик менә торган саен азрак кулланганга үпкәләп, хәрефләр «Әлифба»ны ташлап качып киткән. Димәк, кичекмәстән эзли чыгарга кирәк!

Халыкара Туган тел көне уңаеннан Кариев театрында «Әлифба: Хәрефләр дөньясында» спектакле премьерасы булачак. Интерактив лингвистик спектакльдә татар хәрефләренә башланган сүзләрне табарга, милли ризыклар, бәйрәмнәрне искә төшерергә, табышмаклар чишәргә һәм, әлбәттә инде, рәхәтләнеп кул чабарга кирәк булачак!

22 февраль, 13:00

Г.Кариев исем. Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры. Казан, Петербург ур, 55Б

ТӨРКИ КАҺАНЛЫКЛАР ҖӘҮҺӘРЕ (0+)

«Чиста көмеш – затлы мехлар» күргәзмәсендә 142 уникаль экспонат тәкъдим ителә. Алар арасында Дәүләт Эрмитажы тупланмасындагы экспонатлар да бар. Чара Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу кысаларында уза.

Күргәзмәнең берничә экспонаты төрки каһанлыклар вакытына караган «мех өчен көмеш» сәүдәсенең башлангыч этапларын күрсәтә. Монда шулай ук урта гасыр торевтикасы һәм зәркән сәнгате җәүһәрләрен, Дәүләт Эрмитажы тупланмаларында сакланган савытларны һәм Мәрҗани фонды коллекциясеннән урта гасыр көмеш сәнгать эшләнмәләрен күрергә мөмкин.

Мәрҗани фонды безнең гасырның беренче ике дистә елы дәвамында максатчан рәвештә җыю эшчәнлеге алып бара. Нәтиҗәдә тулы бер коллекция формалаша. Күргәзмәгә килгән кунаклар урта гасыр торевтикасы һәм зәркән сәнгатенең берничә шедеврын күрә ала. Берничә экспонат югары мәдәни-тарихи кыйммәткә ия, алар урта гасыр Евразиясенең декоратив-гамәли сәнгате һәйкәле булып санала. Күргәзмә экспонатлары ислам дөньясы сәнгать традицияләренең үзара бәйләнешен күрсәтә.

2023 елның 2 апреленә кадәр

Татар халкы һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы музее

ГЫЙЛЕМ НУРЫ (6+)

«Үзгәрешләр чоры мәдрәсәсе» күргәзмәсе Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 140 еллыгына багышлап оештырылган. «Мөхәммәдия» – инкыйлабка кадәрге Россиядә иң эре мөселман уку йортларыннан берсе. Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында татар мәдәнияте, фәне, сәнгате һәм сәясәтенең күренекле эшлеклеләре бар.

Күргәзмәдә Галимҗан Баруди кулъязмалары, шәкертләрнең истәлекләре, диплом үрнәкләре, дәреслекләр, биредә белем алучыларның һәм мөгаллимнәрнең фотосурәтләре, «Дин вә әдәб» басмалары урын алган. Әлеге предметлар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә хөкем сөргән рухны, белемгә, яңалыкка омтылышны, иҗади активлыкны чагылдыра. Музей раритетлары Руслан Ибраһимов тарафыннан күргәзмә өчен махсус ясалган рәсемнәр белән тулыландырылган. Аларда мәдрәсә шәкертләренең тормыш-көнкүреше сурәтләнгән.

2023 елның 30 маена кадәр

Казан, Кремль, Кол Шәриф мәчете, Ислам мәдәнияте музее

ЧУЛПАН ЙОЛДЫЗ КАЛКА... (6+)

Тинчуринлылар сәхнәгә куйган премьера – «Чулпан» мелодрамасында бер мәхәббәт тарихы сурәтләнә. Спектакль иртәме-соңмы барыбызга да килә торган беренче ихлас хисләр турында. Күпләр өчен ул алдагы мөнәсәбәтләрнең асылына әйләнә, ә кемдер өчен упкынга әверелә.

26 февраль, 17:00

К.Тинчурин исем.

Татар дәүләт драма һәм комедия театры

Казан, Горький ур., 13

АЙ КӘЕФЕ: МИЗГЕЛЛӘР

ХАЛЫК ТОРМЫШЫ – ХАЛЫК ФОТОСТУДИЯСЕ ОБЪЕКТИВЫ АША

Фотографлар арасында массакүләм мәгълүмат чаралары өчен төрле вакыйгалар мизгелләрен туктатып калырга сәләтле профессиональ фотографлар да, һәвәскәрләре дә бар. Фотоаппарат объективы бу вакыйгаларда гади халык кайнаган тормыш мизгелләрен мәңгеләштерә. Безнең ыгы-зыгылы тормышыбызның әлеге мизгелләре җылы һәм җанлы сурәтләрдә кала. Басмабыз битләрендә алты дистә ел дәвамында рәссам, педагог, фоторәссам, зәркәнче һәм икона язучы Виталий Ковалевский оештырган «Казан» халык фотостудиясендә шөгыльләнүче һәвәскәр фотографлар теркәгән мизгелләр чагылыш таба. Үз эшен яратып, зәвык белән башкарган Виталий Ольгердович инде бакыйлыкка күчсә дә, ул үзе һәм аның укучылары туктаткан мизгелләр фотосурәтләрдә яши.



Беразга гына булса да тормыш мәшәкатьләреннән арынып, фотоларга күз салыгыз – сез анда тирә-ягыбызның иң матур күренешләренә хәйран калырсыз.

Людмила Зотова фотосы

60 нчы еллар

Виталий Ковалевский фотосы

Солтан Исхаков фотосы

70 нче еллар

Сергей Горлачёв фотосы

Солтан Исхаков фотосы

80 нче еллар

Елена Логинова фотосы



Надежда Власова фотосы

Игорь Пшеничников фотосы

90 нчы еллар



Солтан Исхаков фотосы



Светлана Елагина фотосы

Елена Крылова фотосы

2000нче еллар

Артем Гыйбадуллин фотосы

PRESSA

Кышның сихри мизгелләре...



Мария Баймяшкина фотосы